ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№04 (375)
АПРЕЛЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

ШӘҺӘР ЧИТЕНДӘГЕ ГАЛӘМ

Космик кораблар галәм киңлекләрен гизгәндә, без шәһәр читендәге үз галактикабыз – табигатькә, саф һавага, иркенлеккә омтылабыз, авыл якларына юл тотабыз...

Бу галактикада яшәүчеләр башкалардан чит планета затларына хас сыйфатлары белән аерылып тора: гадәттән тыш хезмәт сөючәнлек, берөзлексез җир казу, утырту, утау, яшәгән урыннарын гел үзгәртеп-яңартып тору һәм шәһәр өчен ят булган башка сыйфатлар. Бу планета халкы шәхси йортларын, аның тирәсендәге бакча-кишәрлекләрне чистартып-ялтыратып, балкып торган йолдыз итәргә сәләтле.

Шәһәр галактикасында яшәүче халык та, кызыгып, кала читендәге галактикага китәргә тырыша. Бигрәк тә яз көне, сезон башланып, помидор һәм чәчәк үсентеләре, кошлар сайравы, мангалда әзерләнгән ризык исләре башларны әйләндерә башлагач... Һәм кемдер җәй буена шунда югала, кемдер бөтенләйгә яшәргә дә кала. Чөнки монда әләккән һәркем флора һәм фаунадан, саф һавалы табигатьтән алыначак файданы аңлый башлый.

Сезнең эшсөяр редакциягез.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррире: Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илдус Заһидуллин, Николай Крушинин, Ульяна Макарова, Дамир Үтәмешев, Алмаз Хәмзин, Әхмәт Шакиров, Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Татарстанның атказанган юристы, Татарстан велосипедчылар берлегең оештыручы Илдус Янышев. Гөлнара Сагыева фотосы.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–0880
Басарга кул куелды: 10.04.2023
Басмадан чыкты: 14.04.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 102 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик татарстанда

ЮПИТЕР КҮРШЕСЕ СӨЕМБИКӘ

Сөембикә – Казан ханлыгының мәшһүр ханбикәсе генә түгел, күк җисеме дә әле. Татар ханбикәсе исеме белән аталган кече планета (астероид) Марс белән Юпитер орбиталары арасында урнашкан. Әлбәттә, аны гади күз белән күреп булмый, чөнки Җирдән әлеге кече планетага кадәр ара – якынча 300 миллион километр. Планетаны 2000 нче еллар башында Төньяк-Кавказ астрономия станциясендә эшләгән Казан галимнәре ача. Сүз уңаеннан, галәмдә Казан астероиды да бар, ә Айда һәм Марста Казан астрономнары хөрмәтенә аталган 16 күк объекты исәпләнә. Ә иң мөһим ачышларның берсе 2017 елда була: КФУ астрономнары Кояштан 210 яктылык елы ераклыгында урнашкан HD208897 йолдызы янында экзопланета ачалар.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. «КАИ-1», Җиргә җавап бирегез
Орбитада шаярырга буламы?

8. Йолдызларга юл. Татарстан эзе
Кайсы предприятиеләр космос файдасына эшли

10. Галәм геройлары
Республикада ракета техникасын төзүчеләр нәрсә белән шөгыльләнгән

12. Елга сәяхәтләре...
Киләчәктә нәрсә көтә

игелекле эшләр

18. Ыгы-зыгысыз тормыш
Шәһәрдән читтә яшәүнең өстенлекләре

26. Эт тормышымы?
Киресенчә!

28. Песиле өй
Хыялны чынга ашыру өчен ничә песи кирәк

30. Шәһәрлеләр ни өчен авылны сайлый
Мавыгулар белән яшәү

38. Яшәү рәвеше
Яшь калуның сере – спорт

40. Максатчанлык кая илтә
Шамил Ногманов киңәшләре

42. Дөнья тирәли сәяхәт
Илдус Янышев ни өчен велосипедын бернәрсәгә дә алыштырмый

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

мәңгелек кыйммәтләр

54. Әбидә кунакта
Паласны ничек тукыйлар

56. Агач йортлы Казан
Архитектор Айдаров ядкәрләрне ни рәвешле саклап калган

68. Бөек Җиңүне каршылап
102 яшьлек Зиннәтулла Заһидуллин

71. Тарих сәхифәләре
Дөреслек тарафдары Галимҗан Шәрәф

74. Китап киштәсендә ниләр бар
Хәтер бокрасы

82. Татарстан авыллары
Татар Танае: ел саен су баса...

88. Рамазан ае
Беренче ифтар

Фото: pxhere.com

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР



9.03

Фәрит Бикчәнтәев, Камал театрының баш режиссёры, – 2023 елда тапшырылачак «Тантана» премиясе уңаеннан уздырылган матбугат конференциясендә:

– Милли театрларда милли мәсьәлә бик катлаулы. Әгәр без, ни дисәк тә, театрны институт дип санайбыз икән, ул телне һәм мәдәниятне саклый торган институт булырга тиеш... Тел проблемасы гомумән беренче урында тора. Чувашлар, мордвалар, марилар үз телләрендә сәхнәдә уйнау мөмкинлеген югалта баралар. Бу бик җитди проблема, кайтавазы көтелгән бәла.

10.03

Гекдениз Карадениз, «Рубин» футбол клубы легендасы, – «Бизнес-онлайн» газетасы белән әңгәмәсендә:

– Һәр клуб, үз футболчыларыбыз белән шөгыльләнергә вакыт җитте, дигән фикергә киләчәк. Легионерларның икенче юлы да нәкъ менә шулай китәргә мөмкин булуларын аңлыйк. Шуңа күрә бүген «Рубин» кебек яхшы алмаш – яшьләр системасын төзергә кирәк. Үсеш шуннан башланачак. Әгәр иң көчле җыелма командаларга ия Франция, Германия, Англия кебек илләрне карасак, анда рус балаларыннан да талантлыраклар туарга мөмкинмени?

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

7.03

Васил Шәйхразыев, ТР вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе, – Казанда, «Московия: рождение двуглавого орла» китабы презентациясендә:

– Татарлар тарихы Россия, рус кардәшләребез тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә татар конгрессы эшләре буенча йөргәндә, безгә кайчак «сезнең татар диаспорасы» диләр. Бу очракта без, катгый итеп, һичнинди икеләнүләрсез: «Гафу итегез, без диаспора түгел. Без – Россиядә төп халык», – дибез.

Фотолар: tatar-inform, ТР Рәисе матбугат хезмәте

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан укучылары орбитада **ничек** шаярганнар

Безнең республикада космос «эзләрен» **кайда** табарга була

Татарстанлылар галәмне үзләштерүгә **нинди** өлеш кертәләр

Елга флоты **кайчан** торгызылыр

КАИ-1, ҖИРГӘ ҖАВАП БИРЕГЕЗ

Узган елның 9 августында галәмгә очырылган беренче Татарстан иярченен мәктәп укучылары һәм студентлар уйлап тапкан. Хыял аларга йолдызларга барып җитәргә, хәтта орбитада бераз шаярып алырга да ярдәм иткән.

10А сыйныф укучылары, сулдан уңга: Азамат Кәримов, Әмирхан Шакиров, Руслан Насыйбуллин.

Фотолар «Нилакт ДОСААФ» ҖҮҖнән, КМТТУ-КАИның Инженерлык интернат-лицееннан алынды.

Ульяна Макарова

Һәр хыялга канат куючы була. Безнең очракта ул сәләтле балалар өчен КМТТУ-КАИ базасында эшләүче интернат-мәктәп директоры Динар Габидуллин.

– Малайлар белән ракета җибәрү хыялы әллә кайчан бар иде инде. Моның фантастика икәнлеген дә аңлый идем, – дип сөйли директор. – Икенче яктан, бик шәп белгечләр әзерләү турында сөйләшәбез икән, аларны югары технологияләр кулланып укытырга кирәк. Бу яктан караганда, космостан да югарырак казанышлар була алмый. Бөтен фәннәр аңа хезмәт итә...

Нәкъ менә шул вакытта Владимир Бортникның Инновацияләрне үстерү фонды ил күләмендә «Планета буенча дежур» проектын башлап җибәрә. Максат – яшүсмерләр арасында космик тикшеренүләр һәм эшләнмәләренең популярлыгын арттыру, аларны кызыксындыру.

Кыскасы, Татарстанның беренче CubeSat (белем бирүче космик экспериментлар өчен мәктәп-студент иярченнәренең махсус төре) җибәрү идеясенә чынга ашу мөмкинлеге туа: лицей фонд грантын ота.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ИЯРЧЕН

Тиңдәше бүген галәм киңлекләрен гизүче иярченнең прототибы лицейда саклана. Өч кило ярым авырлыктагы кечкенә генә аппарат. Аның бортында кояш батареяларын һәм камераларын күрергә мөмкин. Аларның барысын да мәктәп укучылары үз куллары белән җыйган.

Башта, әлбәттә, укытучылар да, яшүсмерләр дә бу ниятнең нәрсә булып чыгачагын төгәл белми. Җитмәсә, иярченнең старт көне дә берничә тапкыр күчерелә. Кайвакыт эшнең кичектерелүеннән дә начар нәрсә юк. Моңа конструкторлар һәм галәм аппаратын җыючыларның дулкынлануын да өстәсәк... Ә бит космос хаталарны кичерми...

– Безнең бурыч – балаларны чын «тимерләр» ясарга өйрәтү иде, – ди проект ментерларының берсе, КМТТУ-КАИ магистранты Шамил Вәлиуллин. – Иярченнең прототибын алар үзләре ясады. Ә инде «сугышчан аппаратны» җыйганда төп эшне өлкәннәр башкарды.

Кабатлап шуны әйтик: CubeSat – белем бирүче космик экспериментларга юнәлдерелгән мәктәп-студент иярченнәренең махсус төре. Әзер конструктор бар, аны балалар инструкция буенча үзләре җыя. Прототипны да алар программалаштыра. Космик аппаратның үзе өчен дә компонентларны алар сайлый, кирәк әйберләрне ябыштыра. Әлбәттә, барысы да өлкәннәрнең катгый контроле астында



11А сыйныф укучылары Кәрим Гыйльметдинов һәм Кирилл Богданов.

башкарыла. Төп эшләр тәмамлангач, сынауларга чират җитә. Аппаратларны гермошкафка урнаштыралар, суыту җиһазларын кулланалар, термостабилизацияләнгән мохиткә батыралар. Болар барысы да аппаратның температура үзгәрешләре еш булган һавасыз киңлектә үзен ничек тотачагын аңлау өчен эшләнә.

– Һәркем үзе өчен ниндидер файда алырлык коллектив тупларга тырыштык, – ди Шамил Вәлиуллин. – Дәресләр алып бара башлагач, һәр кешенең эш тизлеген аңларга, кызыксындырырга, аңа туры килә торган ачкычны табарга кирәк. Һәм әкренләп куелган бурычны үтәү балалар өчен кызыклырак була бара. Хәзерге буын күбрәк IT белән кызыксына. «Тимер» белән эшләү һәм аны программа белән тәэмин итү кебек мавыгулар аларда хәзер сирәк очрый. Лицейда теория һәм практика бик дөрес берләштерелә, биредә укучылар заманча контроллерларны үзләре программалаштыралар. Шуңа күрә яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр дә.

ЛИЦЕЙ ГИМНЫ. ОРБИТАДАН ТРАНСЛЯЦИЯ

Укучылар ясаган фәнни иярчен нәрсәдән гыйбарәт соң?

Укучылар түбәндәгеләрне тәкъдим итә: корпус буенча 6 камера урнаштырырга, иярченнең тирә-ягын рәсемгә төшерергә һәм аннан панорамалы сурәт ясарга тырышырга. Бу җиңел эш түгел: 6 камера-

ны Кояш батареяларыннан туендырырга кирәк, алар сурәтне Җиргә тапшырырга һәм планетадан сигнал кабул итәргә өйрәнергә тиеш. Мәктәптә өлкәннәргә – югары уку йорты укытучыларына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Без иярченне җибәрү мөмкинлеген оттык, әмма анда сезнең эксперимент өчен дә өстәмә урын бар, безгә булышыгыз, диләр.

– Башта иярчен өчен нәрсәдер эшләү идеясе белән безгә инженерлык интернатлицее мөрәҗәгать итте, һәм без моны чынга алмадык. Мәктәп укучылары һәм космик технологияләр – алар бер-берсеннән бик ерак тоелды, – дип искә ала КМТТУ-КАИның радиофотоника һәм микродулкынлы технологияләр кафедрасы профессоры, техник фәннәр докторы Артем Кузнецов. – Ә аннары техник биремне карадык, гайре табигый бернәрсә дә юклыгын аңладык. Әлбәттә, без мәктәп укучыларын проектлау эшенә актив җәлеп иттек. Анда чыннан да бик акыллы балалар укый. Без үлчәмнәр бирдек, аның ничек эшләнергә тиешлеген күрсәттек, алга таба үзегез уйлагыз, дидек.

Нәтиҗәдә югары уку йорты галимнәре наноиярченгә фәнни файда китерә торган функция дә өсти – оптик-сүс брэгг рәшәткәләрендә температура датчиклары урнаштыра. Алар бик компактлы. Эксперимент уңышлы чыккан очракта аларны конструкциянең композит элементына ябыштырырга мөмкин. Шуңа күрә күпмедер вакыттан соң безнең галимнәрнең бу эшләнмәсен космик аппаратларның интеллектуаль панеленә кертеп булачак. Безнең илдә мондый эшләнмәнең әле галәм киңлекләренә чыгарылганы юк.

Космик аппаратның белем бирү функциясенә килгәндә исә, укучылар әле дә иярченнең тирә-ягында барган һәрнәрсәне теркәп баралар, сурәтен алалар, очу юнәлешен билгелиләр һәм хәтта шаярырга да яраталар. Соңгысы, әлбәттә, бары тик өлкәннәрнең рөхсәте белән генә.

Ничекме? Аппаратта тапшыру җайланмасы бар. Балалар алдан ук үз лицейларының гимнын яздырганнар һәм 1 сентябрьдә, аны кушып, бөтен планетага яңгыратканнар дияргә була...

Гадәттә, мондый иярченнәрнең орбитада яшәве бер елга якын дәвам итә. Шуннан соң ул космос чүп-чарына әверелә һәм атмосферада янып бетә. Әмма космик аппаратны ясау буенча икенче шундый ук конкурста катнашу өчен, техник университет инде бүген үк барлык документларны әзерли, әлбәттә, мәктәп укучылары-лицейчылар катнашында. Әлеге проектта эшләячәк яңа команда инде формалаша. Барысы да яхшы булса, эш декабрьдә башланачак.



ЙОЛДЫЗЛАРГА ИЛТКӘН ЮЛ. ТАТАРСТАН ЭЗЕ

Кая карама – космос. Сүзебез Татарстанда теге яки бу дәрәҗәдә галәм белән бәйләнгән урыннар турында бара. Шуларны бергәләп барлыйкмы? Әйдәгез киттек!..

Казанның «Элекон» заводында эшләнгән **ЭЛЕКТР ТОТАШТЫРГЫЧЛАРЫ** «Луна», «Марс», «Венера» **ПЛАНЕТААРА СТАНЦИЯЛӘРЕНДӘ**, Җирнең ясалма иярченнәрендә, «Салют», «Мир» һәм Халыкара космик станцияләрнең орбиталь станцияләре конструкцияләрендә **КУЛЛАНЫЛГАН**. Аларсыз «Союзлар» һәм ракета ташучылар оча алмый.

Яшел Үзәннең Серго исемендәге заводында (POZIS) җитештерелгән **ПИРОПАТРОННАР ТӨШҮЧЕ АППАРАТТАГЫ КАТАПУЛЬТА СИСТЕМАСЫНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕ БУЛЫП ТОРА...**

Чистайның «Восток» заводында җитештерелгән **«АМФИБИЯ» СӘГАТЕ** 1975 елда «Союз-17» космик корабле һәм «Салют-4» станциясенең бортинженеры **ГЕОРГИЙ ГРЕЧКО** экипировкасына кергән. Очыш 29 тәүлек дәвам иткән.

Алабуганың «Эссен Продакшн» компаниясе дистә елдан артык Халыкара космик станция космонавтларын соус һәм джемнар белән тәэмин итә. **БҮГЕН СОУСНЫҢ БИШ ТӨРЕ, ДЖЕМНАРНЫҢ ӨЧ ТӨРЕ ҺӘМ ИКЕ ТОППИНГ КОСМОСКА ОЗАТЫЛА.** Кетчуп, горчица, аджика, керән, җиләк-җимеш джемнары...

Фото: tatar-inform.ru, protatarstan.ru, vostokinc.com, zainsk-inform.ru



Дөньяда беренче тапкыр «Космос-186» һәм «Космос-188» космик корабларын автомат рәвештә тоташтыру 1967 елның 30 октябрендә Казанның «Электроприбор» заводында ясалган гиростабилизатор ярдәмендә башкарылган. **ГАЛӘМГӘ КҮТӘРЕЛГӘН КОРАБЛАР 80 НЧЕ ЕЛЛАР АХЫРЫНА КАДӘР БЕР-БЕРСЕ БЕЛӘН ДӘ, КОСМИК СТАНЦИЯЛӘР БЕЛӘН ДӘ ӘЛЕГЕ ҖАЙЛАНМА ЯРДӘМЕНДӘ ТОТАШКАН.**

1975–1977 елларда Үзәк конструкторлык бюросында һәм Казан оптика-механика заводында беренче стратосфера, орбиталь һәм планетаара оптика-электрон комплекслары һәм галәм киңлекләрен өйрәнү өчен приборлар ясалган. **САЛЮТ-6 СТАНЦИЯСЕНДӘ КАЗАНДА ЯСАЛГАН СУБМИЛЛИМЕТРЛЫ БСТ-1 ТЕЛЕСКОБЫ УРНАШТЫРЫЛГАН.** Үзәк конструкторлык бюросында уйлап табылган һәм КОМЗда җитештерелгән «Пион-К» оптик приборлар комплексы 80 нче еллар уртасында «Салют-7» орбиталь комплексы составында эшләгән.

ТР ДОСААФ Үзәк аэроклубының Минзәлә филиалында **БУЛАЧАК КОСМОНАВТЛАР** – Юрий Гагарин исемендәге Космонавтлар әзерләү үзәге курсантлары **МАХСУС ПАРАШЮТ ӘЗЕРЛЕГЕ ҮТӘ.**

В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясендә **АЙГА КҮТӘРЕЛҮ МИССИЯЛӘРЕН ДӨНЬЯДА БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ НАВИГАЦИЯ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ СИСТЕМАСЫ ЭШЛӘНГӘН.** Обсерватория Марс иярченнәренә космик аппаратларның очышларын координаталар белән тәэмин итү буенча ФОБОС халыкара проектында катнашкан (1986–1987 елларда).



ИЛДӘ БЕРЕНЧЕ РАКЕТА ДВИГАТЕЛЬЛӘРЕ КАФЕДРАСЫ 1945 ЕЛНЫҢ 1 МАЕНДА КАЗАН АВИАЦИЯ ИНСТИТУТЫНДА АЧЫЛГАН. Аны оештыруда совет ракета-космос системаларының баш конструкторы Валентин Глушко һәм гамәли космонавтикага нигез салучы Сергей Королев катнашкан. Һава-реактив двигательләре һәм ракета двигательләре кафедрасы базасында бүгенге реактив двигательләр һәм энергетик корылмалар кафедрасы ачылган.

1961 елның 9 мартында, Юрий Гагаринның галәмгә очышына бер ай кала, Татарстан Республикасының Зәй районы Иске Тәкмәк авылы янында **«ВОСТОК 3СК №1» КОСМИК КОРАБЫ ҖИРГӘ ТӨШЕП УТЫРА. АНЫҢ БОРТЫНДА «ЧЕРНУШКА» ИСЕМЛЕ ЭТЕ,** космонавт «Иван Иваныч» макеты, 40 тычкан, диңгез дуңгызлары һәм бакалар булган. Кораб Җир тирәли бер мәртәбә әйләнгән.

КОСМОС ЧОРЫ. КАҺАРМАННАР

Галәмне буйсындырган каһарманнар арасында якташларыбыз да шактый. Алар космик корабларны һәм ракета двигательләрен уйлап тапкан, космик аппаратларны проектлаштырган һәм аларны сынауда катнашкан, галәм киңлекләрен үзләштергән һәм тарих өчен космик мизгелләрне фотога төшергән. Татарстанның галәм геройлары кемнәр алар?

АНАТОЛИЙ ВОРОНОВ, космонавт

Бөгелмә районында мәктәп укытучысы була, аннары – авиаполк штурманы, атом-төш бомбаларын сынауда катнашучы. Космонавтлар отрядында – 1963 елдан. Л-1 корабында очу өчен сайлап алынган командага эләгә. Миссия гаять мөһим – Айда СССРның өстенлеген тәэмин итү. 1969 елның 3 июлендә космонавтлар ай программасы өчен махсус әзерләнгән гаять куәтле ракетаны сынау очышында катнашалар. Воронов соңрак искә төшерә: «Кинәт бөтен дөнья кабынып китте, без түбәнгә төшеп, качарга өлгердек, һәм шул вакытта бәрмә дулкын пыялаларны чәлпәрәмә китерде. Егылып төшкәннән соң ракета старт мәйданчыгында ук шартлады». Әлеге уңышсыз очыштан соң ике атна үтүгә, Американың «Аполлон-1» модуле йомшак кына итеп айга төшеп утыра. СССР җитәкчелеге Айга пилотлы очышлар программасын яба, экипажлар таркатыла. Аннары Воронов дөньяда беренче «Салют» орбиталь станциясендә очышка әзерләнә, әмма 1971 елда «Союз-11» экипажы һәлак булганнан соң, бу программа да туктатыла. Воронов «Союз» модификацияләренең берсендә яңа очышка әзерләнә башлый, әмма бу да барып чыкмый: 79 нчы елда аңарда онкологик авыру табалар, ул космонавтлар отрядыннан чыгарыла.

СЕРГЕЙ РЫЖИКОВ, космонавт



Бөгелмәдә туган кеше үзенең беренче тапкыр галәмгә 2016 елның октябрендә «Союз МС-02» транспорт корабы экипажының командиры һәм Халыкара космик станция экипажының бортинженеры сыйфатында оча. Очыш 173 тәүлек 3 сәгать 15 минут 21 секунд дәвам итә. Икенче мәртәбә космоска ул 2020 елның 14 октябрендә «Союз МС-17» космик корабы экипажы командиры, МКС-63 программасы буенча Халыкара космик станция экипажы бортинженеры һәм МКС-64 төп космик экспедицияләрнең командиры сыйфатында күтәрелә. 2021 елның 17 апрелендә МКС-64 экспедициясе экипажы җиргә уңышлы әйләнеп кайта.



МӘХМҮТ РӘФЫЙКОВ, кинооператор-документалист

Совет ракеталары очышын «эштә файдалану өчен» төшерә. Оператор тарафыннан беренче космонавт Юрий Гагаринның тарихи очышыннан соң ук төшерелгән фотолары бөтен дөньяны урый. Андриан Николаев, Павел Попович, Валентина Терешкова, башка совет космонавтларының әзерләнүләрен, стартларын, җиргә төшүләрен сурәткә төшереп кала. Рәфыйков галәмгә очу турында документаль фильмнар төшерүчеләрнең берсе, шул ук вакытта аның күп кенә кадрларында әле дә «Катгый яшерен» грифы тора. 2011 елда Мәхмүт Рәфыйков Гагаринның галәмгә күтәрелүенең 50 еллыгы хөрмәтенә «Россия кинематографына керткән гаять зур өлеше өчен» «Ника» Милли кинопремиясенә лаек була.

Фотолар: tatar-inform.ru, Россия Президентының матбугат хезмәте, ru.wikipedia.org, kai.ru, «Татарстан» журналы архивы

ВАЛЕНТИН ГЛУШКО,
СССРДА СЫЕК ЯГУЛЫКЛЫ РАКЕТА ДВИГАТЕЛЬЛӘРЕ ТӨЗЕЛЕШЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

Казанда космик системаларның булачак баш конструкторы һәм күп тапкыр кулланыла торган «Энергия – Буран» ракета-космос комплексының генераль конструкторы 1940 елның көзендә килә. Бирегә НКВДның «шарашкасын» күчерәләр, Глушкога шунда эшләргә рөхсәт ителә (ул СССР НКВД каршындагы Махсус киңәшмә тарафыннан РСФСР Җинаять кодексының 58-7 һәм 58-11 статьялары буенча сигез елга төрмәгә хөкем ителгән була). Казанның 16 нчы авиазаводында Глушко КБ-2 җитәкчесе итеп билгеләнә. Анда самолётлар өчен сыек ягулыклы РД-1 ярдәмче реактив двигателе уйлап табыла. Әлеге уңыш өчен, 1944 елның августында хөкем карары юкка чыгарылып, Валентин Глушко белән 16 нчы Махсус конструкторлык бюросының аеруча яхшы эш күрсәткән 34 белгече вакытыннан алда тоткынлыктан азат ителә. КБ-2 реактив двигательләр буенча тәҗрибә-конструкторлык бюросы итеп үзгәртелә, анда Глушко баш конструктор булып кала. Ә 1945 елның маенда ул Казан авиация институтында Советлар Союзында беренче ракета двигательләре кафедрасын ача һәм җитәкли башлый.

СЕРГЕЙ КОРОЛЁВ, ОКБ-1 БАШ КОНСТРУКТОРЫ

«Туполев шарашкасында» Королёв «контрреволюцион троцкистлык эшчәнлеге» өчен срогын уза. 1942 елда Казанга, 16 нчы авиазавод (хәзерге – КМҖБ) каршындагы төрмә тибындагы ОКБ-16 га күчерелә, анда авиациядә куллану максатыннан яңа типтагы ракета двигательләре эшлиләр. 1943 ел башында Сергей Павловичны реактив җайланмалар төркеменең баш конструкторы итеп билгелиләр. Пе-2 бомбардировщигының техник характеристикаларын яхшырту белән шөгыльләнә, мондый ракета җайланмасы куелган беренче очыш 1943 елның октябрендә була. 1944 елның августында Королёвны, хөкем карарын юкка чыгарып, төрмәдән вакытыннан алда азат итәләр, фатир бирәләр. Шуннан соң космик ОКБ-1 нең булачак баш конструкторы тагын бер ел Казанда эшли. Казан авиация институтының реактив двигательләр кафедрасында тәүге укытучыларының берсе була.

УРАЛ ЗАКИРОВ, ГАЛИМ, ИНЖЕНЕР

«Анда булырга язсын!» – Урал Закировка аталган Ай фотосын космонавт Валерий Кубасов шулай имзалаган. Урал Наилевичка галәмгә очарга туры килми. Әмма Казанның Белинский исемендәге 19 нчы мәктәбен тәмамлаган, физика-математика фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешкән Урал Закиров космосны үзләштерүгә зур өлеш кертә. 1965–1971 елларда ул баш конструкторы Сергей Королёв булган ОКБ-1 дә әйдәп баручы инженер булып эшли, космик аппаратларны проектлау һәм сынауда катнаша. Борт системаларының программалы автомат җайланмасын, космонавтларның яңа төр пульты буенча техник бирем әзерләү белән шөгыльләнә. 1965 ел ахыры – 1966 ел башында ОКБ-1 (ЦКБЭМ) отрядына космонавтларның беренче төркемендә катнашучы буларак медицина тикшерүе уза, әмма күзе начар күрү сәбәпле, отрядка кертелми.

РОАЛЬД СӘГЪДИЕВ, СССР ФА АКАДЕМИГЫ



Казанның 19 нчы мәктәбен тәмамлый. 1973-1988 елларда СССР Фәннәр академиясенең Космик тикшеренүләр институты директоры була. Бу вазыйфаны ул плазма физикасы өлкәсендә илнең әйдәп баручы белгече буларак били. КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаре Михаил Горбачёвның космонавтика һәм хәрби космик системалар мәсьәләләре буенча киңәшчесе була, АКШ белән Женевада (1985), Вашингтонда (1987) һәм Мәскәүдә (1988) узган югары дәрәҗәдәге сөйләшүләрдә киңәшче буларак катнаша. АКШның Мэриленд штаты Университетының «Көнчыгыш - Көнбатыш» үзәге директоры, НАСА эксперты.

ИДЕЛ БУЙЛАП СӘЯХӘТ. ҖИРЛЕ АСПЕКТ

Әхмәт Шакиров

«Сергей Дягилев», «Александр Пушкин», «Мостай Кәрим», «Александр Суворов»... Апрель аенда Казан елга портыннан кузгалып китәчәк теплоходлар исемлеге «Казан – биш диңгез порты» дип сөйләгән чакларны искә төшерә. Кызганыч, бу лайнерларның берсе генә дә безнең портка карамый. Әлеге теплоходларда елга круизларын да Татарстан туроператорлары оештырмый...

Мәскәү һәм Санкт-Петербург, Самара һәм Түбән Новгород, Пермь һәм Ростов-на-Дону – бүген илебез елга флотының төп өлеше әлеге шәһәрләрдә тупланган. Премиум һәм люкс класстагы круиз теплоходлары да, космик эраның яшьтәшләре булган гадирәкләре дә. Елга круизларын оештыручы төп туроператорлар да шул шәһәрләрдә урнашкан. Алар яңа маршрутлар уйлап таба, судноларда хезмәт күрсәтүне оештыра һәм әзер продуктлар тәкъдим итә. Әлбәттә, үзләре теләгән бәяләре буенча.

СӘЯХӘТКӘ – «ЯТ» ФЛАГ АСТЫНДА

– Мин елга сәяхәтен яратучы гап-гади кеше, шуңа күрә юлламаны кайсы туроператордан сатып алсам да ярый, – ди 25 еллык круиз тәҗрибәсенә ия әлмәтле Равил Галәвиев. – Тик бер закончалык бар: еш кына круиз маршруты Казаннан башланмый, юллама сатып алгач, теплоходка юл уңаеннан буш урынга кереп утырасың. Табигый ки, урыннарны сайлау, аларның саны чикле була....

– Үзебезнең җирле оператор булмагач, син турны арадашчы фирмадан сатып алырга мәҗбүр, әлбәттә, бәясе арзанрак булмый, – ди беренче тапкыр Идел буенча круизда 90 нчы еллар башында булган казанлы Анатолий Смирнов. – Һәрхәлдә, бәяләргә карасаң, шулай тоела. Апрель ахырында Казаннан Мәскәүгә кадәр алты көнлек сәяхәткә ике кеше өчен йөз мең сум түләү, әле бу стандарт каюта өчен – бу артык инде...

– Мине турфирмалар тәкъдим иткән маршрутлар һәрвакытта да канәгатьләндерми. Бездә кыска – бер-ике көнлек турлар бөтенләй юк яисә бик аз. Казан–Болгар–Зөя, Казан–Чистай–Алабуга кебек маршрутлар, мәсәлән, – дип саный Яшел Үзән районын-

Фото: Әскәр Сабиров

нан Сергей Тихонов. – Үзебезнең Татарстан теплоходлары булмагач, республика һәм күрше төбәкләр буенча оригиналь программалар эшләү һәм аларны үстерү мөмкинлеге дә юк, гәрчә кызыклы вариантлар бик күп булса да.

Бу без үткәргән блиц-сораштырудан алынган кайбер фикерләр генә. Сораштыруның максаты туристлык продуктының читтән тәкъдим ителүе, ул вакытта көтелмәгән хәлләрнең ихтималлыгы потенциаль сәяхәтче өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын ачыклау иде. Бәяләр, ниндидер турларга кытлык һәм аларның географиясен җирле үзенчәлек һәм теләкләрне исәпкә алып киңәйтә алмау – бу уңайсызлыкларның кайберләре генә...

Хәер, күпме кеше булса, шулкадәр фикердер. Ләкин төгәл күрсәткечләр бар. Әгәр круиз маршрутларын оештыручы башкалада яки күрше төбәктә утыра икән, димәк, турны сатудан кергән акча да, салымнар да шунда китә. Бу суммалар зурмы соң? Әле биш ел элек Вячеслав Самолин, ул чакта ук җирле круизларны оештыручы бердәнбер кеше, биш-алты миллиард сум дигән иде. Аның фикеренчә, үзебезнең туроператорлар һәм теплоходлар булмау сәбәпле, республикадан шулкадәр акча читкә китә.

Биш ел элек Казаннан Әстерханга кадәр ике кешелек тур 60–70 меңгә төшә иде. Бүген – якынча ике тапкырга күбрәк. Аңлавыбызча, Самолин атаган сумма бу вакыт эчендә һич кенә дә кими алмый.

ФЛАГМАН БУЛУДАН – ТИК ТОРУГА

Идел, Чулман, Агыйдел, Нократ, Казансу елгалары кушылган урын... Якынча мең километрга сузылган су юлы, матур ярлар, яр буйларында утырган борынгы калалар һәм ЮНЕСКО Исемлегенә кергән уникаль һәйкәлләр... Иң тыгыз юллар киселешендә урнашкан Татарстанга Аллаһ үзе тик торырга түгел, ә елга круизлары базарында әйдәп баручы булырга кушкандыр кебек.

Ул кайчандыр шулай булган да. Өлкән буын казанлылар хәтерлидер: 60 нчы елларда, Мәскәүдә яисә Питерда түгел, нәкъ менә Казанда беренче тапкыр чит ил туристларын Идел буйлап сәяхәткә алып чыгалар. «Козьма Минин» теплоходы пионер булып санала, ул, совет «Интуристы»-ның бай клиентларын утыртып, Казаннан Ростов-на-Донуга кадәр йөри. Үз гражданнары турында да онытмыйлар.

«1980 нче елларда Туризм буенча татар өлкә советы җиде теплоход тота. Ленинградка дүрт палубалы теплоходта унсигез көнлек круиз, экскурсияләр, өч тапкыр туклануны да кертеп, совет туристына 87 сумга төшә иде, – дип сөйләде миңа төбәктә Идел буйлап круизларны оештыру башында торган Вячеслав Самолин. – Круиз туризмының тагын бер күтәрелеше үзгәртеп кору чорына туры килде. 1987 елдан Казанда немец туристлары белән Идел буйлап сәяхәтләр оештырылды».

Капиталистик чор башлангач, Казандагы бөтен теплоход диярлек яңа хуҗаларына китә. Әмма 90 нчы еллар уртасына кадәр республикада әле уникe туроператор исәпләнә. Алар Идел һәм Чулман буйлап круизлар оештыра, сезонга Пермь, Түбән Новгород һәм Самара судно хуҗаларыннан 24 ләп теплоходны арендага алып тора. Аренда, әлбәттә, башкалардан өстенлекне арттырмый, җирле фирмалар өстәмә чыгымнарны компенсацияләргә тырыша, үзләренең оригиналь продуктын һәм сыйфатлы сервисын тәкъдим итә.

Әмма могҗиза була алмый, базарның кырыс таләпләре барысын да үз урынына куя. Теплоходлары үзләренеке булган эре туроператорлар әкренләп атсыз көндәшләрен йота бара. Моңа өстәп елга флотының тиз кыскаруы да зур этәргеч бирә: совет чорыннан калган иске теплоходлар бер-бер артлы сафтан чыга бара. Мәсәлән, «Татфлот» та үзенең теплоходыннан колак кага: өч палубалы «Константин Циолковский» икенче меңьеллык башында Санкт-Петербург портында яна башлый һәм бата.

Калганнарын арендага алу кыенлаша, раритетларны суда йөзәрлек итеп саклап калу тагын да авыррак була.

Кызганыч, әмма Татарстанда круизлар өлкәсендә кайчандыр пионер саналган кеше үзенең туроператорлык эшчәнлеген соңгы булып туктата. Вячеслав Самолин һәм аның «Идел сәяхәтләре+» фирмасы соңгы көнгә кадәр авырлыкларга каршы көрәшә, әмма барысы да 2018 елда туктап кала: туроператор клиентлар алдындагы бурычын үти алмый. Аның үз флотын булдырырга теләвен банкротлыкка китергән соңгы гамәл дип санарга мөмкин, чөнки кредитка сатып алынган өч палублы иске «Очарованный странник» сәяхәткә чыгуга караганда күбрәк тик торырга мәҗбүр була, ремонт исә миллионнар таләп итеп, чыгымнарны арттыра гына.

ТАТАРСТАН ТИРӘЛИ СӘЯХӘТ. ДӘВАМЫ БАРМЫ?

Ярар, җирле туроператорлар да, Татарстан портында теркәлгән лайнерлар да булмасын, ди. Яхшымы, начармы – ләкин «чит» туроператорлар бу тармактагы буш урыннарны күрә. Казан порты причалында сезон вакытында лайнерлар күп. Болгарга да, Зөягә дә, Чистайга да, Тәтешкә дә круиз судналары туктый...

Әлбәттә, әгәр без Татарстанның бай туристлык потенциалын алга таба үстерергә теләмибез икән, проблемадан баш тартырга,

хәтта Татарстаннан агып киткән ул миллиардларга күз йома алабыз. Ләкин билгесезлеккә алып бара торган бу юл кемгә генә ошар икән.

Бу урында минем нигәдер эре спорт чараларының берсе барган көннәрдә Казан елга портындагы вакыйга исемә төште. Причал янында «Борис Полевой»га утырып круизга барырга тиешле туристлар җыелды, ә теплоход нигәдер бик озак тоткарлана. Сәбәбе берничә сәгатьтән, судно яр буена килеп туктагач ачыкланды: спорт форумының оештыру комитеты өчен ашыгыч рәвештә елга буйлап сәяхәт оештырырга кирәк булган икән. Чараны өзәргә ярамый. Флот булмау сәбәпле, җирле туроператор юлламалары булган туристларны көттерергә мәҗбүр була, кисәтеп торуны да кирәк санамый.

Елга круизын тиз оештыру, стандарт булмаган маршрутлар төзү, яңа шәһәр яки «яшел тукталышлар» ачу – болар барысы да үз теплоходларың һәм җирле туроператорың булмаганда бик проблемалы мәсьәлә. Шунысын да әйтергә кирәк: кайчандыр җирле туроператор тотынмаган булса, Казаннан ике көнгә Болгар, Тәтеш, Алабуга һәм Зөягә барулар, шулай ук Татарстанның Идел һәм Чулман елгалары ярындагы шәһәрләренә аерым елга турлары оешкан булыр идеме икән? Бүген туристны Татарстанда ике-өч көннән дә күбрәккә ничек калдырырга дип баш ватабыз. Ә аларга Идел, Чулман яисә Нократ елгалары буйлап круиз тәкъдим итсәк? Вариант бит?

Кызганычка каршы, хәзер бу, бигрәк тә сезонның кызу чагында, мөмкин хәл түгел. Юлламаларны күпкә алданрак алып куярга кирәк, теплоход рейска киткәнче бер көн-бер атна элек сатып алу могҗизагатиң. Туристларның зур төркеме өчен теплоходка заказ биреп тә булмый, гәрчә элек, республикада үз теплоходларыбыз һәм туроператорларыбыз булганда, якын-тирәдәге шәһәрләргә корпоратив сәяхәтләр оештыру бик популяр иде. Бер генә уй башка килә: Татарстанга үз теплоходлары булган үз туроператорлары кирәк.

ХЫЯЛДАГЫ КОРАБ. ӘЛЕГӘ ПРОЕКТТА

Әлбәттә, круиз туризмын үстерергә һәм үз теплоходлары булган коллегалары белән көндәшлек итәргә сәләтле җитди төбәк туроператоры үзеннән-үзе пәйда була алмый. Яхшы судно сатып алуга инвестицияләр кертергә курыкмаган һәм, иң мөһиме, моңа әзер бизнесмен табылуы да шикле, чөнки әлеге эшкә салынган миллиард сумнардагы чыгымнарның аклануын шактый озак көтәргә туры киләчәк. Совет чорыннан калган бик тиз искереп баручы флотның берәр судносын сатып алу коткармый – бу хәтта кыска вакыт өчен дә туры килми. Моңа ачык мисал – «Идел сәяхәтләре»нең фаҗигале язмышы.

Икенче яктан, нәкъ менә бүген, кичә яки иртәгә түгел, республиканың елга круизлары үзәге статусын торгызу өчен иң уңайлы вакыт. Беренчедән, елга буйлап сәяхәт итүгә ихтыяҗ арта: турларны, кагыйдә буларак, берничә ай элек сатып алырга туры килә. Икенчедән, елга круизы базарында иң зур уенчылар да бүген күбесе илле елдан артык кулланышта булган корабларга ия. Аңлашыла ки, экономия һәм уңайлылык ягыннан алар дөнья судно төзелешенең иң яхшы таләпләрен исәпкә алып төзелергә тиешле теплоход белән җитди ярыша алмаячак (шул ук Европада судноларны чыгару беркайчан да туктатылмаган).

Шунысы мөһим: мондый теплоход, проектта гына булса да, Татарстанда бар. 2021 елның июлендә Санкт-Петербургтагы Хәрби-диңгез салонында «Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе Яшел Үзән проект-конструкторлык бюросы эшләнмәсен күрсәтте, ул вакытта әле эскиз вариантында. Бу 170 пассажирга исәпләнгән өч палубалы пассажир теплоходы. Барлык уңайлыклары булган люкс, ярымлюкс һәм стандарт каюталар, ресторан, кинозал... Теплоходта елга һәм диңгез яр буенда уңайлы йөзү өчен барысы да каралган. Совет чорыннан соң төзелгән бердәнбер «Мостай Кәрим» лайнерыннан аермалы буларак, Яшел Үзән варианты артык зур түгел. Мөгаен, ул «биш йолдыз»лы түгел, «дүрт йолдыз»лы теплоходтыр, әмма потенциаль хуҗалар фикеренчә, нәкъ менә шундый корабларга елга круизлары базарында ихтыяҗ зур да. Һәм иң мөһиме, исәпләүләргә күз салсак, мондый теплоходны төзү, совет чорыннан соң төзелгән бердәнбер судно белән чагыштырганда, ике тапкырга арзанракка төшәчәк (ике ел элек аталган сан 1,62 млрд сум иде).

Сүз уңаеннан, Санкт-Петербургта хәтта А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы 10 круиз теплоходы төзелешен ышанып тапшырырлык төп башкаручы була ала, «Ак барс» суднолар төзү корпорациясе ниндидер бер партнер белән пассажир судноларын төзү буенча хезмәттәшлек турында стратегик килешүгә кул куярга әзерләнә, дип тә белдерел-

де. Корпорациянең генераль директоры Ренат Мистахов исә матбугат чараларына, бу бәя диапазоны коммерцияле эксплуатация ягыннан иң перспективалы вариант, дип аңлатты.

Булачак Татарстан теплоходларының беренче потенциаль заказчысының исеме аталмады, әмма Мистахов судно төзелешенең техник йөкләмәсен нәкъ менә ул формалаштырды дип белдерде. «Шунда ук контрактка күчмәячәкбез, финанслау инструменты кирәк», – дип тә кисәтте. Мондый вариантларның берсе – лизинг компанияләре – ГТЛК яисә «Машпромлизинг» акчаларын җәлеп итү диелде. Алар ярдәмендә сәяхәтчеләрне ташучы елына 2,5 процентлы ташламага ия лизинг та, ихтимал, субсидия дә алыр иде....

Күрәсең, эш бүген дә контрактка кадәр барып җитмәгән. Бәлки, илдәге вазгыятьнең үзгәрүе һәм әлеге хәлләрдә финанслау инструментының табылмавы аркасындадыр.

КИЛӘЧӘК ФЛОТЫ

Әмма, катлаулы булуына да карамастан, нәкъ менә соңгы ел илдә круиз флотын яңарту мөмкинлегенә өмет саклануын күрсәтте. Эчке су юллары өчен круиз судносы проекты элеккечә үк «Ак Барс» суднолар корпорациясе сайтында эленеп тора. Узган ел башында Хөкүмәт круиз туризмын үстерү концепциясен раслады. Төп бурычларның берсе – Россиядә диңгез һәм елга круизлары санын арттыру һәм мондый сәяхәтләрне тагын да уңайлырак һәм кызыклырак итү. Ниһаять, узган елның ноябрендә Россия Президенты Владимир Путин Хөкүмәткә «су транспортының граждан судноларына ташламалы лизинг программасы кысаларында» «елга – диңгез» классына караган, ким дигәндә, 140 круиз судносы төзелешен финанслау мәсьәләсен тикшерергә кушты. Шулай ук Президент күрсәтмәсе буенча Хөкүмәт круиз һәм ял итеп йөрү флотын яңарту, порт инфраструктурасын, круиз һәм пассажир суднолары өчен причал корылмаларын төзү һәм яңарту мәсьәләләрен тикшерергә тиеш.

Күргәнебезчә, Президент күрсәтмәсе бүгенге көнгә кадәр флотны яңартуга комачаулаган төп проблеманы хәл итәргә тиеш, ягъни яңа кораблар төзү буенча кыйбатлы проектларны финанслауда дәүләтнең катнашуы көтелә. Күрсәтмәне үтәү срокларының кырыслыгын (быелның апреле) исәпкә алсак, нәтиҗәне күрми калмыйбыз. Күптән түгел Хөкүмәтнең граждан флотына караган җиде судно төзелешенә 15 миллиард сум акча бүлеп бирелүе турындагы хәбәре – беренче карлыгачтыр.

Татарстан өчен, ниһаять, үз туроператоры ярдәмендә (идеалда – республикада ясалган теплоходларда) елга круизларын оештыруның реаль мөмкинлеге тууы белән килешәсездер. Федераль үзәк белән уртак финанслау шартларында татарстанлыларның шактый проектны уңышлы тормышка ашыру тәҗрибәсен һәм осталыгын исәпкә алганда, мондый перспектива фантастика тоелмый. Бигрәк тә икътисадыбызның иң көчле эшмәкәрләре белән дәүләт-шәхси партнерлыгы нәтиҗәсендә нык-лы, тотрыклы туроператор пәйда булса.

...Шушы көннәрдә электрон массакүләм мәгълүмат чараларында «Өч елга: Идел, Нократ, Чулман» туристлык маршруты турында сөйләделәр. Дөрес, бу маршрут Россия тимер юллары тарафыннан оештырылган, һәм круиз, әлбәттә, поездда, тәгәрмәчләр тавышы астында узачак. Тимер юл буйлап сәяхәт итүгә каршы түгелмен, әмма шулай да Россиянең иң мәшһүр өч елгасының матурлыгына теплоход бортыннан соклану яхшырак булыр иде. Елга круизларын оештыручының берсе генә булса да Казанныкы саналган очракта моның нәкъ шулай килеп чыгачагына иманым камил. Моннан күп еллар элек Идел буенча сәяхәтләр Казаннан башланып, турларны һәркем сатып ала алган чаклардагы кебек...



акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

төп тема

Бу санда тәкъдим итәбез:

Шәһәрдән читтә **кемнәр** һәм **ничек** яши

Хыялны чынга ашыру өчен **ничә** песи кирәк

Ни өчен шәһәрлеләр авылны сайлый

Максатка ирешү өчен **нишләргә**

ТАБИГАТЬ МАТУРЛЫГЫ

Йорт янын тәртипкә китереп кенә калмыйча, аны хәтергә уелырлык, зәвыклы, уңайлы итү өчен нәрсә эшләргә кирәк? «Татарстан» журналы сорауларына республиканың танылган «Неолит-Дизайн» компаниясе директоры Ләйсән Шлайфер җавап бирә. Студия Татарстан территориясендә инде 15 елдан артык ландшафт дизайны һәм комплекслы төзекләндерү проектларын уңышлы тормышка ашыра.

– Ләйсән Илдаровна, бүген ландшафт дизайнында нинди юнәлешләргә өстенлек бирелә?

– Алар күп, ләкин иң мөһиме – табигать эстетикасы, ягъни үсемлекләрне һәм ясалма булмаган материалларны табигый мохит тудыру өчен куллану. Су белән бәйле нәрсәләр, төрле яктырту системалары да популяр.

– Җир кишәрлеген тәртипкә китерү белән шөгыльләнәчәк компанияне ничек сайларга?

– Ландшафт дизайнының үзенчәлеге шунда: матур манзара артында профессиональ эш таләп ителгән катлаулы процесс тора. Гамәлгә ашырылган проектларны карагыз, элеккеге клиентлары һәм партнерлары бу компанияне киңәш итәме-юкмы икәнлеге белән кызыксыныгыз. Студиядә проектлаучылар һәм башка белгечләрдән гыйбарәт штат булырга тиеш. Дизайнерларының һәм яшелләндерү белән шөгыльләнүчеләренең эшенә аеруча игътибар итегез. Җитди компаниянең тәэминатчы ширкәтләр белән дә элемтәләре җайга салынган була. Ул, тиешле сыйфатны саклаган хәлдә, куелган вакытка өлгерерлек, мәсьәләләрне тиз хәл итәрлек тәҗрибәгә һәм структурага ия булырга тиеш.

– Кишәрлектә эш нәрсәдән башлана?

– Заказчы белән очрашудан. Шунда без аның теләк-ниятләрен өйрәнәбез, үлчәүләр алабыз һәм проектны эшләү өчен кирәкле башка мәгълүматны туплыйбыз. Болар барысы да кыш көне эшләнсә, бик яхшы. Аннары проект ясап, клиентка тәкъдим итәбез. Детальләр турында сөйләшәбез, аерым алганда, материаллар һәм үсемлекләрне сайлыйбыз, проектка үзгәрешләр кертәбез. Шуннан соң смета белән эш графигын төзелә, һәм ниятләгәнне тормышка ашыру этабы башлана.

– Ә сыйфатны кем күзәтә?

– Эшне оештыручы аларның барышын контрольдә тота, дизайнер авторлык идеяләрен гамәлгә ашыруны күзәтә, объектка билгеләнгән аерым хезмәткәр эшләрнең башкарылу сыйфатын һәм гомумән проектның ни рәвешле гамәлгә ашырылуын тикшерә.

– Сезнең клиентлар кемнәр ул?

– Заказчыларның төп категориясе – юридик затлар. Бу, нигездә, проектның тулысынча әзер хәлдә тапшырылуын таләп итә торган генераль подряд оешмалары. Аларга бөтен нәрсәне үзең сатып алып, килештерәсен килештереп, гамәлгә ашырып бирергә кирәк.

Клиентларның икенче категориясе – шәхси заказчылар: уңышка ирешкән, яхшы зәвыклы, хәлле кешеләр. Һәрнәрсәнең анык, төгәл булуын яраталар, үз вакытларының кадерен беләләр һәм ике арада җылы, уңайлы элемтә корылуын хуп күрәләр. Алар үз эшләрендә тәҗрибәле, оста, шуңа күрә шундый ук профессионаллар белән эш итеп, түләгән акчаларына нәрсә алачакларын аңларга-күрергә телиләр.

Төзелеш, ремонт, төзекләндерү эшләренең клиентларыбыз өчен стресс икәнен аңлыйбыз. Шуңа күрә без үзара элемтәне һәр сорау мөмкин кадәр шома чишелерлек итеп корырга тырышабыз.

– Әгәр заказчы ниндидер искиткеч нәрсә уйлап тапкан очракта нишлисез?

– Мондый идеяне тормышка ашыру – ахыр чиктә канәгатьлек китерә торган бер сынау ул. Шуңа күрә бу сорауга җавап: без моны һичшиксез булдырабыз!

Без заказчының визуаль образларын чынга ашыра торган, шәхсән аның теләкләренә туры килгән яңалыклар кертәбез һәм инде башкарылган эшләребез белән горурланабыз.

– Студиягез ясаган ландшафтлар, яшеллек һәм төзекләндерү нәтиҗәләре кешеләрне озак еллар шатландырып тора, менә шул мөһим.

– Әйе, һәм бу очраклы түгел: һәр проектка җаваплылык тоеп алынабыз. Сүзебезне йомгаклап әйткәндә, матур ландшафт дизайны – хәлиткеч факторларның тулы бер җыелмасы ул. Бу эш тәҗрибә, белем, сыйфатлы материаллар, табигатькә хөрмәт таләп итә. Ә иң мөһиме – ул заказчыларыбызның хыялларын тормышка ашырып, аларны сөендереп торырга тиеш!

Фото «Неолит-Дизайн» компаниясе тарафыннан тәкъдим ителде. РЕКЛАМА

«Татарстан» журналының махсус проекты

ШӘҺӘРДӘН ЧИТТӘ ЯШӘҮ

СЕЗНЕ НӘРСӘ КЫЗЫКТЫРА?

- шау-шулы урамнармы;
- машиналар ыгы-зыгысы, бөкеләрме;
- тынчу һавамы;
- сездән өстә, аста, янда яшәүче күпсанлы күршеләрме;
- көне буе фатирда сезне көтеп утырган этегезме...

ТР Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча 2023 ел башында Татарстан Республикасы территориясендә 4 001 625 кеше яшәгән, шуларның 3 071 356сы – шәһәр, ә калган 930 269ы авыл халкы.

ТАТАРСТАНДА ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ 23% ТАН АРТЫГЫ ШӘҺӘРДӘН ЧИТТӘ ТОРМЫШ ИТҮ РӘВЕШЕН САЙЛЫЙ.

ЯИСӘ:

- **табигатьтә шашлык кыздырумы;**
- **саф һавамы;**
- **чирәмдә ялан тәпи йөрүме;**
- **яшелчәне түтәлдән өзеп ашаумы;**
- **салым һәм коммуналь ташламалармы;**
- **үз җаегызга яшәүме;**
- **йорт хайваннары өчен иркенлекме...**



Фото: Светлана Ефименко

Мондый минус һәм плюслар дача алырга, юк, дача гына түгел, йорт салырга һәм гомумән шәһәрдән читкәрәк күченеп яшәргә хыялланган һәркемнең башында кайныйдыр.

Авыл тормышына кызыгу яңалык түгел: мондый күченүләр һәрвакыт булган, кемдер шәһәрне авылга алыштырган, авылдан калага китүчеләр тагын да күбрәк булган. Табигатькә якынрак күченгән кешеләр, югарыда саналган плюслардан тыш, шактый күп минуслар – нәкъ менә кемнедер туган ягын ташлап калага китәргә мәҗбүр иткән уңайсызлыклар белән дә очраша: кар чистартырга, үлән чабарга, бакча казырга, тавык-чебеш тотарга өйрәнә. Бәлки, бу бик тиз туйдырыр, һәм алар яңадан шәһәр тормышын сагыныр, чөнки анда уңай яклар күбрәк булып чыга. Ләкин бүген сүзебез ул турыда түгел.

Бүген без Казаннан читтә – шәһәр кырыендагы аз катлы йортларда, табигать кочагында яшәүчеләр тормышы турында сөйлибез.

шәҗәрәнең

Кощаководан
Наилә һәм Александр Петровлар

КӨН САЕН ТАБИГАТЬ ХОЗУРЫНДА

Фото: Александр Ефремов

Дамир Үтәмешев

Петровлар гаиләсе Кощаково авылына 13 ел элек күченгән.

– Бу иремнең туган авылы, – дип аңлата Наилә Наримановна. – Мин үзем шәһәр кызы, авылда яшәрмен дип уйлап та караганым булмады, әмма иремнең кайтасы килде, ул кыстады. Бу җир иремә әбисеннән мирас булып калды. Иске генә өе дә бар иде. 2004 елда шушы нигездә үз өебезне сала башладык, хәзер дә шунда яшибез. Төзелеш бүгенге көнгә кадәр дәвам итә, – дип көлә ул.

– Казанда Космонавтлар урамында фатирыбыз да бар, өйне шунда яши-яши төзедек. Хәзер анда гаиләсе: ире, ике баласы белән белән кызыбыз яши.

Тормыш-көнкүреш өчен бөтен кирәк-яракны күрше совхоздан алабыз. Анда балалар бакчасы, мәктәп, берничә азык-төлек кибете, амбулатория һәм җәмәгать мунчасы бар, ял итәргә кечкенә генә парк та ясалган. Анда гел бәйрәмнәр булып тора, мондый күңел ачу чараларына халык күп йөри.

Юл белән дә проблема юк, бөтен җиргә машина белән йөрибез – үзем дә, ирем дә машиналы. Царево Village торак комплексыннан Җиңү проспектына кадәр барган 123 нче автобус маршруты да безнең авыл яныннан уза, 20 минут саен йөреп торган автобустан метрога, теләсә кайсы башка җәмәгать транспортына күчеп утырып, кирәкле җиргә барып җитәргә мөмкин.

Мин инде бер ел пенсиядә, элегрәк Родина урамындагы автомастерскойда колорист – төсләр сайлаучы булып эшләдем. Ирем дә шул ук урамдагы «Водоканал» предприятиесендә авария хезмәтендә эшли. Бөкеләр булмаганда машина белән 25 минутлык юл.

Олыгая барган саен җирдә, бакча эшләре белән шөгыльләнергә ярата башладым, яшелчә, төрле тәмләткеч үләннәр үстерәм. Утырткан агачларыбыз инде җимеш бирә башлады. Өебез каршындагы түтәлләрдә җәй буе чәчәк үстерәбез, бик күңелле яшибез.

Теләсәк-теләмәсәк тә, авыл тормышының уңай якларын 2020 елда коронавирус пандемиясе башлангач һәм карантин игълан ителгәч тойдык. Авыл халкының йорт тирәсенә чыгу, саф һава сулау, хәрәкәтләнү мөмкинлеге булды.

13 елга бер мәртәбә дә авылда яшәвемә үкенмәдем. Саф һава сулыйсың, иркенлек, үз кулларың белән үстергән ризыкларны ашыйсың, туганнарыңны бер түбә астына җыя аласың... Моның өчен үкенеп буламыни?! Бәхет бит бу.

шәһәрдән читтә

Кече Елгадан
Суфия һәм Таһир Ибәтуллиннар

БЕЗНЕҢ МОНДА БАРЫСЫ ДА ШӘҺӘРДӘГЕЧӘ

Фото: Александр Ефремов

– Миңа 59 яшь, Пәрәү авылы кызы мин, 21 яшькә кадәр шунда яшәдем, ә соңгы 38 елда Кече Елгада гомер итәм. Күченгәннән бирле үзебезнең ФАПта фельдшер булып эшлим, – дип сөйли Суфия Габдрахман кызы. – Ирем Таһир Нәзир улына – 61 яшь, ул шушы авылда туып үскән. Хәзер мәктәптә каравылчы булып эшли, ә элек механизатор булып хезмәт куйды, ул чакта авыл «Җиңү» колхозына керә иде.

Кече Елгада барысы да шәһәрдәгечә, күләм ягыннан гына кечерәк. Балалар бакчасы, мәктәп, китапханә, мәдәният йорты, кибетләрне әйткән дә юк. Мәдәният йорты гөрләп тора, үзешчәннәр тарафыннан спектакльләр дә куела. Кешегә тагын нәрсә кирәк?

Ике кызыбыз да Казанда яши, гаиләле, өчәр бала үстерәләр. Алар, әлбәттә, безгә ешрак кайта, үзебез дә кунакка баргалыйбыз. Балык Бистәсеннән Үзәк автовокзалга кадәр 592 нче маршрут автобусы йөрсә дә, машина белән йөрибез. Үз машинабыз белән җайлырак, автобусны көтәргә кирәк, шәһәргә кадәр ике сәгатьтән артык бара, ә машинада – сәгатьтән артыклык юл.

Без гомер буе авылда яшәдек, табигатебез буенча да авыл кешеләре. Бәлки, кайчан да булса Казанга күчеп китәрбез, чөнки анда да фатирыбыз бар. Ләкин хәзергә бу мөмкин хәл түгел, чөнки безнең кайгыртуга һәм тәрбиягә мохтаҗ этиәниебез алдындагы бурычыбыз бар.

Үземнең авылдагы тормышымнан канәгать. Ләкин җаным туган авыл өчен сызлана – яшьләр шәһәргә китә, авылда кеше калмый. Беләсезме, бүген мәктәптә бер генә беренче сыйныф укучысы да юк! Хәзер авылда 700дән артык кеше яши. Ә бит кайчандыр авылыбыз алдынгылар рәтендә булган, колхоз сөт саву һәм терлеклекчелек күрсәткечләре буенча дан тоткан. Тирә-якта, хуҗасын көтеп, эшкәртелми яткан күпме авыл хуҗалыгы җирләре ята, әмма яшьләр хәзер басуда эшләргә теләми. Бу хәлләр кайчан да булса үзгәрер дип өметләнәм.



шәһәрдән читтә

Сингелдән
Мария һәм Александр Шагаровлар

БУ УРЫННЫ БЕР КҮРҮДӘ ЯРАТТЫК

Фото: Александр Ефремов

– Үзем дә, хатыным Мария дә Казанда туып үстек, гомер буе шунда яшәдек, – дип сөйли Александр. – 2018 елның җәендә Сингелгә, бер дустыбызга кунакка бардык. Аларның монда җәйге йортлары бар иде. Безгә бу тыныч һәм уңайлы урын бик ошады, һәм дустыбызны өен сатарга күндердек.

Аны, ашыкмыйча гына, үз җаебызга гына үзгәртеп корырга һәм киңәйтергә тотындык. Әмма 2020 елгы пандемия планнарны бозды, шәһәрдән куәнеп, йортыбызны үз көчебез белән күтәрергә дигән фикергә килдек.

Безнең авыл бик кечкенә, уңайлыклардан – төзелеш һәм азык-төлек кибетләре генә. Иң якын мәктәп Рождествено авылында, балаларны укырга мәктәп автобусы йөртә. Кечкенә генә ФАП бар. Калганнарын Казанда сатып алабыз.

Сингелдә халык бик тырыш. Сөт терлекчелеге белән шөгыльләнүче фермерлар да бар. Кемдер үз хуҗалыгын тота. Минем Казанда үз автосервисым бар, анда хатыным ярдәмчем булып эшли. Бу безнең гаилә эше.

Машинада эш урынына 50 минут барырга кирәк. Шәһәргә кадәр 509 нчы маршрут автобусы йөрсә дә, җәмәгать транспортына утырмыйбыз. Ә автобус көнгә 8 тапкыр йөри!

Буш вакытым юк диярлек: автосервистан тыш, монда кечкенә генә хуҗалыгыбыз бар – тугыз тавык, бакча. Калган буш вакытымны гаиләмә багышлыйм: хатыныма, кызларыма. Ике эт тә асрыйбыз: Одри исемле бультерьер һәм Вок исемле Стаффордширд терьеры.

Казанда да фатирыбыз бар. Анда эштән төшке ашка кайтабыз, соңга калган вакытларда кунып та калгалыйбыз.

Бу урынны мин бер күрүдә яраттым, монда тыныч, бернинди дә ыгы-зыгы сизелми. Шәһәрдә һәр адымда күзгә ташланган мәгълүмат ташкыны, элмә такталар, реклама билбордлары – берсе дә юк. Бу минем көч туплый торган үз урыным дип саныйм, монда миңа яшәргә дә, суларга да җиңелрәк.

Шәһәрдән читтә

ЭТ ИЯРТКӘН – ИПТӘШЛЕ

Бу язмабызда Анастасия Хатыйпова этләрнең дөрес токымын сайлау, аларның хуҗаларны йорт салырга, агач утыртырга, өч бала һәм бер онык үстерергә мәҗбүр итүе һәм тормышны яхшы якка үзгәртүе турында сөйли.

ФЛЕГМАТИК САК ЭТЕ

– Минем беркайчан да эт асрарга җыенганым юк, иде, гомумән аларны яратып та бетерми идем, – дип сөйли безгә Тибет мастифларын үрчетүче Анастасия Хатыйпова. – Беркөн без Ливадиядә бакча сатып алдык, анда кыш көне дә яшәп була иде. Шул чакта ирем белән кызым эт алырга күндерделәр. Исәпләре Көнчыгыш Европа овчаркасын алу иде. Мин этне ашатырга гына ризалаштым, карау-тәрбияләүне алар башкарырга тиеш дип сөйләштек.

Ләкин бу токым миңа ошамый иде. Интернетта «флегматик сак эте» дип җыйган идем, «Тибет мастифы» чыкты. Бу 2011 ел иде, әлеге токым көчекләре 80 мең сум тора.

Ирем бу бәяне кыйбатсынды. Мин исә, киресенчә, этләргә кагылышлы төрле форумнарга кереп, мастифларның үзенчәлеген, холкын өйрәнергә һәм акча тупларга керештем.

Фотолар Анастасия Хатыйпова архивыннан

«НАСЛЕДИЕ ТИБЕТА ЕСОН»

Без питомниклар буйлап йөри башладык: Екатеринбург, Мәскәү, Пермь... Түбән Новгородта, ниһаять, үзебез хыялланган этне таптык. Аның хуҗасы Светлана Шарова белән хәзер дә дус яшибез һәм хезмәттәшлек итәбез. Этебезнең тулы кушаматы «Наследие Тибета Есон» иде. Аны бакчага алып кайттык. Һәм нәкъ менә шул кышта 15 елга беренче тапкыр андагы электр утын өзделәр! Тиз арада бөтен нәрсәне сатып, җир алдык. Ярты ел эчендә Зәңгәр күлдәге Щербаковода йорт салып, үз почмагыбызга күчендек. Тагын бер эт – Латифаны алдык. Ул безнең – матурлык буенча Россия, дөнья, Италия, Беларусь чемпионы! Латифа хендлер (этне күргәзмәләргә йөртүче махсус кеше) белән үзебез дә күрмәгән әллә ничә илдә булып кайтты инде.

ДҮРТЕСЕНӘ - ДҮРТ ХОЛЫК

Хәзер бездә дүрт эт яши: Латифа, аның кызы Гела Сида, Латифаның онығы Ютера һәм бәләкәй Джуна. Есон былтыр үлде, аңа 9 яшь иде.

Һәр этнең – үз холкы. Есон... кеше кебек иде. Бик зыялы, горур, тәртипле. Патша инде менә! Без эштән кайтканда, башка этләр кебек өскә сикерми, башын иеп, аягын күтәреп, тыйнак кына сәламли.

Латифа – бер дә берүзе генә тора алмый: аңа йә этләр, йә кешеләр янында булырга кирәк. Күзгә карауга ук, барысын да аңлый. Гәрчә карап торышка ул бик усал күренсә дә, чынлыкта исә бик назлы һәм иркә.

Акыллы Ютера – иң каты тавышлысы, урамнан узган бөтен кешегә өреп кала. Ул безнең төп сакчыбыз – янында тычкан да үтә алмый.

ЕШИМИ РАЙ, ЕРОН ИСАР ҺӘМ ЕЖЕВИКА

Этләр безнең тормышны тамырдан үзгәртте. Хәзер безнең бөтен дусларыбыз – эт асраучылар. Онығым Эвелина белән этләрне ашатабыз да, юып-тарыйбыз да, күргәзмәләргә дә йөртәбез. Мин хәзер бу мәшәкатьләрдән башка элек ничек яшәвемне күз алдыма да китерә алмыйм.

Этләрнең вольеры бар, тик алар нигездә урамда яши. Кар өстендә яки болдырда йокларга яраталар. Көчле җил йә яңгыр булганда, каты буран котырганда гына вольерларына керәләр.

Февральдә Ютера балалады – көчекләргә Ешими Рай, Ерон Исар һәм Ежевика дип исем куштык. Бик матурлар. Күптән көтеп алынган көчекләр. Аларны булачак хуҗалары да түземсезләнеп көтә инде.

ЭТ ДАРУЫ

Этләремне бик яратам. Ничек алай килеп чыктымы? Белмим, мөгаен, Тибет мастифлары үзләренең акыллы булулары белән мине гашыйк иткәннәрдер. Кеше акылы бар кебек үзләрендә. Өйдә берәребезнең берәр җире авырта башласа, кешеләр өчен дару табып булмый – хәтта тырналып канаган тезләргә дә эткә дигән «зеленка» сөртергә туры килә.

Минем өч балам хәзер зурлар инде. Этләрне карарга барысыннан да күбрәк онығым Эвелина булыша. Аңа 13 яшь, киләчәктә ветеринар булырга хыяллана.

ДҮРТКӘ ДҮРТ

Үз йортында мәчесез дә яшәп булмый. Бездә алар да дүртәү. Мейн кун токымлы Хеннеси (Нәсә) песиен мин тәмугтан коткарып калдым дияргә дә була. «1000 сумга мейн кун сатам» дигән игъланны күргәч, карарга киттем. Анда коточкыч шартларда, бик сасы бүлмәдә бер көтү мәче асрыйлар иде. Шундук алып киттем. Безнең Нәсә башта кешеләрдән бик курыкты. Өч ай буе карават астыннан чыкмады. Монда аны беркем дә кыерсытырга җыенмавын аңлагач кына тынычланды. Каты тавыштан да, ирләр белән балалардан да шүрли иде. Күрәсең, ул бик күпне күргән.

Курил бобтейлына охшаган (кыска койрыклы) Яськаны кечкенә вакытында урамнан тапкан идек.

Зәңгәр рус токымлы мәчегә бик охшаган Моисейны кызым Чаллы урамыннан алып кайтты – ул аның машинасына сикереп менгән.

Һәм бер мәчебезнең генә токымын раслый торган документлары бар – Курил бобтейлы токымлы Мася Питердан кадәр кайтты.

Менә шундый песиләр яши бездә. Үзара да, этләр белән дә тату-тыныч гомер сөрәләр.

Мася (өстә) белән Яся гел бергә.

Безнең җиңүләр.

Безнең беренче Тибет мастифы – Есон.

ПЕСИЛЕ ӨЙ

Николай Крушинин

Бәхет өчен ничә песи кирәк – берме, икеме, әллә дүртме? Саванна токымын үрчетүче Ольга Пылаевага бер дистә дә аз, аның шәһәр читендәге йортының бөтен бүлмәсе нәфис мыраубикәләр белән тулган. Һәркайсы үзенчә катлаулы холыклы, барысы да горур һәм хөр, барысы да нәфис һәм нәселле. Кайберләре яңа хуҗаларына юл тотарга мөмкин, кайсылары хуҗабикәләре янында кала.

ЧЫНГА АШКАН ХЫЯЛ

– Песи яратуым, мөгаен, туганнан бирледер. Бездә гел песиләр, кимерүчеләр, сөйрәлүчеләр яши иде. Балачактан ук бабам мине урманга йөртте, балыкка иярте барды, табигать белән кызыксынуымны төрлечә үстерергә тырышты. Болар барысы да киләчәгемне табигать фәннәре белән бәйләү һәм Казан дәүләт университетының биофагына укырга керү теләгән уятты. Алты яшемдә үк мин туганнарыма академик булу һәм авылда йорт хайваннары гөжләп торган өй тоту турындагы ниятләремне җиткердем. Академиклык теләге, кызганыч, чынга ашмады, әмма башка пунктларга килгәндә, хәзерге чынбарлыгым балачак хыялларына бик туры килә.

ЗООПАРКЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРҮ

Күпчелек хезмәттәшләрем-фикердәшләремнеке кебек, минем дә хәзерге тормышым бер песидән башланды. Ирем белән кавышкач, ике өй зоопаркын берләштердек тә моңарчы кул җитмәгәнне чынга ашырырга керештек: Берн зенненхунды көчеген сатып алдык, песи турында да уйлаша башладык. Мин шунда ук саванна токымына тукталдым, әмма 2011 елда Россиядә мондый мәче сатып алу чынга ашмаслык хыял гына иде. Песине Америкадан алып кайту нияте барып чыкмады, һәм мин башка токымга игътибар иттем. Бу токым песиләре дә кыргый хайванга охшаган иде. Шул рәвешле бездә Лаура исемле бенгал мәчесе пәйда булды. Ул ана була алмаса да, токымлы мәчеләр үрчетү белән ма-

Фотолар Ольга Пылаева архивыннан алынды

выгуыма оеткы салды. Мин песи үрчетүчеләр арасында танышлар булдырдым, илебездә фелинологиянең патриархы дип атарлык Светлана Борисовна Пономарева минем остазыма әйләнде. Тиздән өемдә ике мәче, кулымда питомникны теркәү сертификаты белән фелинолог дипломы пәйда булды. Болар күңелдә зурдан-зур ниятләр уятты.

ЯЗМЫШ БИЛГЕСЕ

Форумнар, семинарлар, күргәзмәләр – ял көннәре һәм отпусклар әнә шулай уза иде. Зоолог белгечлеге, шуңа бәйле рәвештә хайваннар генетикасы һәм физиологиясе өлкәсендәге белемнәрем булышты. Әле дөньяга аваз гына салган питомнигыбыз тиз арада халыкара дәрәҗәгә чыкты, без башка илләр белән элемтәләр урнаштырдык, генофондны киңәйтү өчен, чит илләрдән нәселле мәчеләр алып кайттык. 2016 елда Бөекбританиядәге бер мәче үрчетүче ханым минем бенгал мәчесе белән кызыксынды һәм көтмәгәндә саванна токымлы песи белән алмашырга тәкъдим итте. Мин моңа язмышның бер билгесе дип карадым һәм инде 30 декабрьдә Мәскәүдә затлы яңа ел бүләген каршы алдым. Бу бүләк исә безнең киләчәктәге эшчәнлек юнәлешен тәмам билгеләп куйды да. Шул ук чорда мин Россиядә саванна токымын үрчетүдә шәп белгеч саналган Гөлназ Шәрифҗанова белән таныштым. Без партнерлар гына түгел, якын дусларга да әйләндек.

БЕНГАЛЛАР УРЫНЫНА САВАННА МӘЧЕЛӘРЕ

Тора-бара берничә урындыкта берьюлы утырып тору мөмкин түгеллеген аңладым һәм бөтен игътибарны бер токымга юнәлттем: бенгал токымы белән бәйле программага нокта куеп, саванна мәчеләрен генә үрчетү эшенә керештем. Әлбәттә, ул зур күзле, һәрвакыт гаҗәпләнгән кыяфәттәге гүзәл мыраубикәләрдән аерылу бераз кызганыч булды, аларны тәрбияләү-үстерүгә шулкадәр күп көч һәм ярату салынган иде бит. Горурланырлыгыбыз да бар – безнең бенгаллар арасында Россия һәм чит илләрнең танылган питомникларындагы нәселләргә нигез салган песиләр бар. Мин планета буйлап таралган мыраубикәләремнең хуҗалары белән элемтәне өзмим, әмма саванна токымы – яңа һәм өметле эш, аны үстерү өчен бөтен вакытны һәм бар көчне бирергә кирәк.

ХАЙВАННАР ДӨНЬЯНЫ ЯХШЫРТА

Хәер, гаиләбездәге ике эт, экзотик кошлар да игътибарсыз калмый һәм, әлбәттә, дүрт аяклы, канатлы дусларыбызны карау эшендә кызым белән улым – ышанычлы ярдәмчеләрем. Йортта җан ияләре тоту – бик күркәм гадәт. Алар дөньяны яхшырта, кешеләрдә игелеклелекне арттыра.

– Гаиләдә балалар песиләрдән соңрак пәйда булдылар, алар песи койрыгына тотынып йөрергә өйрәнделәр.

шәһәрдән читтә

БАКЧАЧЫ БЛОГЕР ХАНЫМ

Анна Ессина көннәрдән бер көнне тормышын тамырдан үзгәртергә карар кыла: шәһәрдән авылга күченә һәм күзе төшкән бөтен нәрсәне үстерергә керешә. Хаталана-ялгыша-сыный-өйрәнә торгач, зур тәҗрибә туплый һәм бакчачылык-яшелчәчелек өлкәсендә алдынгы карашлы белгеч кенә түгел, шәп блогерга да әйләнә.

НЮШАНЫ – ТӘХЕТКӘ!

– Без чын шәһәр кешесе идек, – дип сүзен башлый Анна. – Дача, бакча һәм шәһәрдән читтә яшәүнең рәхәтлекләрен безнең гаилә бөтенләй аңламый, моны үзеңне җәфалауга, интектерүгә саный иде. Әмма бервакыт барыбыз бергә җыелгач, Папулис (соцчелтәрләрдә этиләренең исеме. – Ред.иск.) белән икебез берьюлы «Нюшаны – патшалыкка!» (Нюша исә минем челтәрдәге кыскартылган исемем) дип әйткәнебезне сизми дә калдык. Ипотека богауларыннан котылырга вакыт!

Шулай итеп алар шәһәрдәге кыйбатлы күчемсез милекләрен сатып, авылда йорт алалар. Столбище Аннаның үз авылына әйләнә. Ни өченме?

– Мин теоретик булсам, Папулис – математик акылга ия практик, – дип аңлата Анна. – Чакрымнарны, бензин бәясен санап, ул шәһәрдән 10–15 километр ераклыкта урнашырга кирәклеген исәпләп чыгарды. Һәм бу Столбище авылы булып чыкты.

ҮГЕЗБОЗАУМЫ, ӘЛЛӘ ТРАКТОРМЫ?

Авыл тормышына тиз кереп китәләр – түтәлләр, теплица, газон, чүп утау, кар көрәү һ.б.лар. Боларның барысына да ничек өлгерергә?

Фото: Анна Ессина архивыннан һәм Алсу Шакирова

– Йолдызлык буенча мин Үгезбозау, холкым буенча – трактор, үзем дә эшсез утыра алмыйм, башкаларны да тик тотмыйм, – дип аңлата Анна. – Шунлыктан мин ул чактагы «рәхәт эшсезлек чорында» бер даһи фикергә килеп, «Огороднутая садистка» блогын ачып җибәрдем.

БЛОГ ХӘБӘРЛӘРЕ

– Минем блогта нәрсәләр бармы? – дип, Анна-Нюша бармакларын бөгә-бөгә санап китә:

«Ызгыш-талаш. Интрига-мәкер. Тикшерү.

Теплица хәбәрләре. Үсентеләр хакында имеш-мимешләр. Бакчадан репортажлар.

Гөблә. Күршеләр. Фитофтора.

Акыл сатам. Киңәш бирәм. Өйрәтәм».

Мондый җитди темаларны шундый юмор белән яктыртырга кемнең хәленнән килсен тагын?!

ЮМОР НӘСЕЛДӘН КИЛӘ

– Юмор белән үзирония миңа табиб әниемнән килә, – ди Анна. – 23 нче хромосомада геннар дәрәҗәсендә күчкән ул. Минем бурычым исә әлеге сәләтне квадратка, кубка, параллелепипедка арттыру иде. Әлегә шактый оста килеп чыга кебек.

Блогны хәзер Ессиннар бөтен гаиләләре белән бергә алып бара икән. Ире Алексейның, кызы Алисаның гына түгел, хәтта Бастинда белән Таисия кушаматлы усал этләренең дә популярлыкка исләре китми икән: видеога төшерүне дә тыныч кабул итәләр, йолдыз чиреннән дә интекмиләр.

– Без шау-шу куптарыр дәрәҗәдә популяр түгел бит, йолдыз чире беребездә дә юк. Дөрес, кайвакыт язылучыларымның бергә фотога төшәргә теләве кыен хәлгә куйгалый – чәчне-башны туздырып, аякка галош элеп, бакчада эшләгән киемнәрдән генә кибеткә ипи алырга барган чакта очрасалар бигрәк тә.

Блогым «брендларыннан» берсе булган Папулис та ниһаять моның котылгысызлыгын аңлады. Киңәшләр биреп кенә калмыйча, яраткан хатыны үтенгәндә камера каршында биеп тә күрсәтергә мөмкин.

ТОРМЫШ ТУРЫНДА СЕРИАЛ

Бакчада казынганда, розаларны кышка әзерләгәндә, үлән бете һәм пәрәвез талпаны кебек бакча «җанварлары» белән көрәшкәндә, Анна үзе уйлап тапкан персонажы – «Огороднутая садистка» роленә шулкадәр кереп китә ки, аның эфирга чыгуын халык мавыктыргыч бакча сериалының чираттагы сериясе кебек кабул итә – аларда җәнҗаллар да, мәкер-коткылар да, тикшерүләр дә җитәрлек була. Мөгаен, үз эшеңнең, үзең катнашкан реалити-шоуның мондый «сериалында» күп акча да эшләп була торгандыр.

– Блогта күп акча эшләү өчен хәзер модага кергән һөнәр иясе – инфочегән булырга кирәк, – дип елмая Анна. – Марафоннар үткәрү, нәрсәнедер үстерү һәм үрчетү курсларын сату таләп итеәл. Мин исә боларны бушлай эшлим. Миңа кызык.



Дүрт ел яшәгәннән соң, авыл тормышының уңай һәм тискәре якларын аңларга була инде. Анна Ессина да аңлаган:

– Тискәре яклары юк, чөнки аларны эзләргә вакыт та, сәбәп тә юк. Юлыбызны, язмышыбызны һәм яшәү урыныбызны без барыбыз да үзебез сайлыйбыз бит.



Папулис белән.

Нюша белән.



Алиса белән.

Бастинда белән Таисия – Анна төшерә торган «сериалның» алыштыргысыз геройлары.

– Йолдызлык буенча мин Үгезбозау, холкым буенча – трактор, үзем дә эшсез утыра алмыйм, башкаларны да тик тотмыйм, – ди Анна.

PRESSA

редакция кухнясы

«ХАЛЫК ГИМНЫ» АВТОРЫННАН – МАНТЫЙ

Татьяна Вафина

«Татарстан»ның күчмә «Редакция кухнясы» бүген Зәй районының Бохарай авылына, кабаклы мантый белән сыйланырга юл тота. Аны өч куллап әзерләячәкләр. Эш шунда ки, шеф-ашчыбыз – җырлар язучы композитор Роберт Андреев – күптән түгел кулын имгәткән. Шунлыктан мәгълүм фильмдагы «бриллиант кулны» хәтерләткән кул иясенә пешеренергә тугрылыклы хәләл җефете Мәдинә ханым ярдәм итәчәк. Димәк, өч куллап булып чыга. Тәмле мантый исә өч кенә түгел, бик кү-ү-үп булачак!

«БРИЛЛИАНТ КУЛ»

Мәдинә Мөнир кызы камыр басканда, Роберт Егорович, сул кулына кашык алып, эчлекне болгата. Үзенең җырларын тыңлыйтыңлый, музыка язу теләге тудыра торган шигырьләрне ничек табуы хакында сөйли.

– Кайвакыт шигырьләрне (нигездә классиканы) укыганда ук, шул мизгелдә башымда туган музыкага сүзләренең ятып торуын тоям. Әлеге процесс бик шәхси, әмма бик кызыклы да. Мин шундук мавыгып китәм: башта үзалдыма көйлим, аннары берничә тапкыр уйнап карыйм, кайбер урыннарын төзәтәм – җырларым менә шулай туа.

КҮП БАЛАЛЫ АТА

– Ничәләп җырыгыз бар, санаганыгыз бармы?

– 1985 елда мин Роберт Рәкыйпов сүзләренә «Зөһрә» дигән беренче җырымны яздым. Хәзер инде бер алтмышлап җырым бардыр.

– Арада иң яраткан кайсы?

– Җырларым – балаларым кебек. «Зөһрә» дә, «Әлли-бәлли-бәү» дә, «Росиночка» да, «Мин яратам сине, Татарстан!» да... Аларның барысы да йөрәк аша, илһамланып, яратып язылган. Шунлыктан һәркайсы балам кебек. Берничә балаң булганда, берсен генә аерып яратып буламыни? Барлык «балаларымны» да бертигез яратам, мин – күп балалы ата.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

Камыр өчен:
- Он – 500–600 г;
- Йомырка – 2 данә;
- Су – 1 стакан;
- Үсемлек мае – 1–2 аш кашыгы;
- Тоз – 1 чәй кашыгы.

Эчлек өчен:
- Сыер итеннән фарш – 600 г;
- Терлекнең эч мае (туңмай) – 100 г;
- Кабак – 300 г;
- Суган – 5–6 баш;
- Тоз, борыч – тәменчә.

Фото: Александр Ефремов

1 – Җырларым балаларым кебек. Бөтен «баламны» да бертигез яратам, мин – күп балалы ата.

2 Хәнҗәр – диңгезченең төп «аш-су коралы».

ТУМЫШТАН ТАЛАНТЛЫ

– Нота грамотасына кайда өйрәндегез?

– Нота грамотасын белмәгән килеш башладым мин. Үземне биш яшемнән бирле хәтерлим – туган авылымдагы (ТАССРның Сарман районы Баткак авылы – ред.иск.) йортыбызның салам түбәсенә менеп басам, кулыма такта тотам да гармунда уйнаган булып кыланам, үзем җырлыйм. Күрәмсең, эти-әнидән күчкәндер, алар икесе дә тальян гармунда халык көйләрен уйнарга һәм керәшен татарларының җырларын җырларга бик маһир иде. Беренче сыйныфны тәмамлагач, әтием миңа тальян гармун алып бирде. Бәхет басты инде мине! Үзлегемнән уйнарга да өйрәндем. Өченче сыйныфтан соң инде, Яшьләр авылы янындагы урманда урнашкан пионер лагеренда тальян уйнап, рәхәтләнеп дискотекалар үткәрә идем.

Мәдәният институтын тәмамлагач (белгечлегем – «ял итүне оештыручы» бит минем), хәтерлим әле, башкаручылар конкурсында катнаштым, анда бөтен Россиядән 62 кеше җыелган иде. Үземнең «Әлли-бәлли-бәү» җырым белән беренче урынны яуладым. Шуннан соң миңа музыкаль белем алырга тәкъдим иттеләр. Мин ике ел музыка училищесында укыдым: ноталарны да, сольфеджио да – кирәкле бөтен нәрсәне өйрәндем. Хәзер үз җырларымны нотага сала алам. Әллә ни тирән белемем бар дип мактанмыйм, әмма көй язуның асылын беләм.

БЕРЕНЧЕ ҖЫРЛАУ ХОКУКЫ

Мәдинә ханым камыр җәйгән арада сораштырабыз – шулкадәр «күп балалы» атаның хатыны булу кыенмы?

– Аның янәшәсендә бик җиңел, рәхәт, – дип елмая ул. – Роберт миңа җырларын җырлый, мин аны тәмле итеп ашатам – белгечлегем буенча ашчы бит үзем. Һәм һәр яңа җырын Роберт беренче тапкыр бары миннән генә җырлатып карый. Музыкасын иҗат итә, берничә тапкыр уйный, магнитофонга яздыра да мине чакыра: «Әйдә, җырла әле, ничегрәк яңгырый икән, тыңлап карыйм», – ди. Һәм мин җырлыйм. Дөрес, өйдә генә, башка беркайда да җырламыйм.

Ул әле гаиләдә бик яхшы ир һәм әти дә. Көйләр язып кына калмый, бөтен эшне белә. Бик шәп төзүче дә, җиһазлар ясаучы да. Менә дигән кием элгечләре ясый – әнә, берсе безнең бүлмәдә тора әле. Бөтен дусларыбызның туган көннәренә дә шундыйны үз кулы белән ясап бүләк итә. Оныкларыбызга агачтан «Максим» пулеметы, пистолетлар ясый. Талантлы кеше һәр яктан талантлы ул, диләр бит әле!

ГАИЛӘ НЫКЛЫГЫ СЕРЕ

Мондый мактаудан соң Роберт Егорович та эреп китә. Һәм «Татарстан»га Андреевлар гаиләсенең бәхет серен ача – алар 44 ел буе пар канат булып яшиләр икән инде. Ноябрьдә сапфир туйларын – 45 ел бергә гомер итүләрен билгеләп үтәргә җыеналар. Роберт Егорович әйтүенчә, гаиләдә иң мөһиме – бер-береңә ышану ул.

– Иң мөһиме – мәхәббәт һәм ышаныч. Без 1975 елда, мин армиягә китәр алдыннан таныштык. Беренче көнне үк мин аны озата бардым һәм, хатыным булачаксың, дидем. Ә мин бер әйттем икән – димәк, шулай булачак та. Мин техникум тәмамладым, Мәдинә мине армиягә озатты. Диңгез флотында, Ерак Көнчыгышта хезмәт иттем. 1978 елның маенда кайттым, ноябрьдә инде өйләнештек тә.

Мантый бөгәргә керешкәндә, Мәдинә ханым күрсәтмәләрен бирә:

– Син бер кул белән бөгә алмыйсың инде. Һәрбер мантыйны майга манып алып, түгәрәккә тезә барырсың. Тик артык якын куйма, югыйсә берберсенә ябышачак!

Роберт Егорович килешеп баш чайкый:

– Без пилмән һәм мантыйны гел икәү бөгәбез, – ди ул. – Әлеге процесс миңа бик ошый.

– Тозлы гына була күрмәсен инде, – дип хафалана Мәдинә ханым.

– Әгәр берәр кешене бик каты яратсаң, тозны күбрәк салып җибәрүең бар, – дип шаярта ире. – Менә хәзер мине ничек яратуыңны тикшереп карыйбыз инде.

БИГРӘК ТӘМЛЕ БӘРӘҢГЕ!

– Курыкмагыз, тозлы булмаячак, – дип тынычландыра «Татарстан»ны Роберт Егорович. – Минем хатыным бөтен нәрсәне бик тәмле пешерә. Ә менә ул өйдә булмаганда, үземә әзерләргә туры килә. Былтыр ул Лениногорскида ял иткәндә – июль ае иде – яшелчә бакчасын мин карадым. Җиләк җыям да – варенье кайнатам, кыяр җыям да – тозлыйм, әрәм итеп булмый бит инде аларны. Аш та пешердем, бәрәңге дә. Минем яраткан рецептым мондый: бәрәңгене пешерәм дә, шуңа сөт, суган, йомырка, атланмай кушып төям – бик тәмле боламык килеп чыга, һәм үзем шулай пешерә алганга горурланам да әле. Тик хатыным пешергәне барыбер тәмлерәк була – ул һөнәре буенча ашчы бит! Мин хатынымнан бик уңдым, ул мине гомерем буе бик тәмле ашата!

– Безнең Роберт бәрәңге ярата ул, – дип сүзгә кушыла Мәдинә ханым. – Пилмәнне дә бәрәңге белән пешерергә куша – фаршка да, шулпага да бәрәңге салдыра.

– Бәрәңге – икенче икмәк бит! – дип нәтиҗә ясый композитор. – Аны без 24 сутый җирдә үзебез үстерәбез, рәхәтләнеп ашарлык була. Карбыз белән кавын да утыртабыз әле. Корылыклы елда 72 карбыз үстердек! Шуңа күңелсезләнеп утырырга вакыт юк.

ХӘЙЛӘ ДӘ КИРӘК

Оныклар да күңелсезләнеп утырырга бирми. Андреевларның бишәү алар. Бирегә килүгә, саф һавада рәхәтләнеп уйный башлыйлар. Бабалары пистолет ясап бирсә, әбиләре тәм-томнар белән сыйлый.

– Тик менә бу мантыйны алар ашамас иде – кабак яратмыйлар, – дип зарлана Мәдинә ханым. – Ә кабак бик файдалы бит! Җаен табарга

3
Беренче җырлау хокукы һәрвакыт Мәдинәнеке.

4
– Минтимер Шәрип улы Азнакайга килгәч, мине кочып алды һәм: «Безнең рәсми гимныбыз Рөстәм Яхин музыкасына язылган, ә синең җырың исә – халык гимны», – диде.

5
Бу бит мин – чык бөртегең синең...

1 Сытабыз

2 Салабыз

3 Өстибез

4 Кушабыз

5 Болгатабыз

6 Басабыз

7 Төреп куябыз

8 Турыйбыз

9 Турыйбыз

10 Кушабыз

11 Өстибез

12 Борыч сибәбез

13 Тоз сибәбез

14 Болгатабыз

15 Җәябез

16 Кисәбез

17 Салабыз

18 Бөгәбез

19 Матурлыйбыз

20 Манабыз

21 Тезәбез

22 Пешерәбез

23 Майлыйбыз

туры килә. Кабак бәлеше пешерәм дә, әфлисуннықы дип хәйләлим – сыпырталар гына!

ӨЧ «ХУҖА»

– Һәр җырның өч «хуҗасы» бар: сүз авторы, көй авторы һәм башкаручы. Сезнеңчә, кайсы мөһимрәк?

– Сүз авторы һәм композитор әлбәттә, – дип уйлап та тормый җавап бирә Андреев. – Башкаручы исә безнең җырны тыңлаучыга җиткерә. Аннан башка да булмый. Әгәр сирәк башкарыла икән, җыр тиз онытыла. Минем җырларымның яртысыннан артыгын артистлар башкара, алар җырны дөньяга таныта, популярлаштыра: Салават Фәтхетдинов, Зөһрә Шәрифуллина, Галина Казанцева, Илсур Сафин, Бәширә Насыйрова, Асаф Вәлиев, Хәния Фәрхи, Вадим Захаров, Мирсәет Сөнгатуллин, Гөлдания Хәйруллина, Айгөл Сагынбаева, Гөлзада Сафиуллина... Мин аларның барысы белән дә таныш. Галина Казанцева белән исә бергә гастрольдә дә йөргәнебез бар. Зөһрә Шәрифуллина безгә еш килә. Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Рафаэль Ильясовның да бездә кунакта булганы бар иде...

Әмма җырга ихтыяҗ зур булса да, Татарстан композиторлары олигархка әйләнми. Безнең менталитет башка ахры. Хәтеремдә, Татарстан интеллектуаль милек агентлыгында (ТАИС) беренче тапкыр гонорар түләнгәч, шалтыратып, килеп алырга куштылар. Ул чакта акча миллионнар белән исәпләнә иде. Менә мин, машинама миллион сумлык ягулык салып, шуны алырга киттем – 36 мең сум бирделәр. Аннары Россия авторлар җәмгыятенә (РАО) күчтем. 500 сум акча түләдем, җырларымны теркәдем. Һәм алты елда 4 мең сум акча эшләдем. Кызганыч ки, авторлар җәмгыяте бездә эшләми. Кайвакыт хәтта телевидениедә дә җырның авторларын атамыйлар. Чөнки безгә, җыр «хуҗаларына», гонорар түлиселәре килми.

«МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТАТАРСТАН»

– Сезнең бер җырыгызның язмышы бик бәхетле. Татарстанда аны, минемчә, татарлар гына түгел, башка милләт вәкилләре дә, татарча бөтенләй аңламаучылар да белә, ярата, җырлый...

– Татарстанда гына да түгел әле! Аның өчен Тукай бүләген дә алдым.

Бервакыт Карабашта ял базасында «Бердәм Россия» ниндидер чара үткәргән иде. Без артистларны да чакырдылар. Мин Комидан килгән бер малай белән таныштым – тавышы да бик матур, яхшы җырлый да. Безнең Әлмәт музыка училищесы директоры исә әлеге малайга: «Мин яратам сине, Татарстан» җырын менә ул язган бит», – дип, миңа төртеп күрсәтте. Малай сөенде инде: «Без ул матур җырны гел җырлыйбыз бит!» – ди.

«Мин яратам сине, Татарстан» җырын мин 1990 елда, Республика көненә багышлап, Роберт Рәкыйпов сүзләренә яздым. Ул чакта әле ноталарны белми идем. Гармунда уйнап, магнитофонга яздырдым. Әлмәттәге дусларым нотага салды. 1991 елда Балтыйк буендагы Сабан туенда үзем җырладым. Мәскәүдәге федераль Сабан туенда да җырладым. Чаллыдагы үзешчән башкаручылар отып алды, кассеталарга яздырды һәм шуннан башланды инде. Салаватка да барып җиткән. Ул 1995 елда Чаллыда яши иде. Шунда очраштык та. Бу җыр аның визит карточкасына әйләнде дисәң дә була. Хәзергә кадәр җырлый. Быелтыр исә бөтен Җир шарында яңгырады, аны бөтен татарлар җырлады: Америкада, Канадада, Гарәп Әмирлекләрендә... Салават аны бөтен җиһанга танытты. 2016 елда туган көнемдә Салават үзенең концертында мине сәхнәгә чакырып тәбрикләде, һәм без бу җырны аның белән икәү җырладык.

Гимн сайлаганда, конкурста минем бу җырымны да тикшергәннәр. Тик ул гимн була алмый шул. Ә менә Минтимер Шәрип улы Азнакайга килгәч, мине кочып алды һәм: «Безнең рәсми гимныбыз Рөстәм Яхин музыкасына язылган, ә синең җырың исә – халык гимны», – диде.

6

– Без 44 ел буе бергә. Ноябрьдә сапфир туебызны – 45 ел бергә гомер итүебезне билгеләп үтәргә җыенабыз. Роберт Егорович әйтүенчә, гаиләдә иң мөһиме – бер-береңә тугры ышану ул, – ди Мәдинә ханым.

«РОСИНОЧКА» КӨЕНӘ

– Башка җырларыгыз турында да шундый мавыктыргыч бәяннарыгыз юкмы соң?

– Бәян ук түгел инде, әмма һәркайсы хакында нәрсә дә булса сөйләп була. Мәсәлән, «Это я – росиночка твоя» җырының тарихы болайрак. Мин гел клубта мәдәният хезмәткәре булдым бит. Берара дуслар белән тамада булып та йөрдек. Тик бу уңайсыз, ял көннәрендә өйдә булмыйсың, кич соң кайтасың. Хәзер моның белән шөгыльләнмим. Әмма клуб әше һаман үзеннән җибәрми әле. Безнең күршебез – клуб мөдире – Мәдинә белән мине пенсионерлар ансамбле оештырырга күндерде. Мин шунда «Это я – росиночка твоя» җырын җырлаган идем, ансамбльнең исеме дә табылды – «Росиночка» булды да куйды.

***

«Росиночка»ны тыңлаган арада мантый да пешеп чыкты.

Мондый искиткеч тәмле мантый белән моңарчы беркайчан да сыйланганыбыз юк иде әле!

7

«Росиночка»ны тыңлаган арада мантый да пешеп чыкты. Мондый искиткеч тәмле мантый белән моңарчы беркайчан да сыйланганыбыз юк иде әле!

ЯШЬ БУЛЫП КАЛУНЫҢ СЕРЕ – СПОРТ

Руфия Фазылова

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (1997–2016 елларда РФ Эчке эшләр министрлыгының ТР буенча ЮХИДИ идарәсе башлыгы) Рифкать Миңнехановның бик актив яшәвен белмәүче сирәктер мөгаен. Йөгерү, йөзү, чаңгы шуу, велосипедта йөрү, бокс... Ул бу спорт төрләренең һәркайсы белән яхшы таныш. Әлбәттә, профессиональ рәвештә, зур ярышларда катнашып түгел: Рифкать Нургали улы нигездә сәламәтлеген ныгыту өчен шөгыльләнгән. Бүген исә җанына якын тагын бер спорт төрен тапкан...

«БАЛАЧАКТАН МАВЫКТЫМ...»

Авыл баласының күбесе профессиональ спорттан ерак булып үсә, чөнки тренерлар белән шөгыльләнергә мөмкинлекләр юк дәрәҗәсендә. Шулай булуга карамастан, алар үзлегеннән йөзәргә дә өйрәнә, футболын, хоккеен да уйный, велосипедта җилдерүне әйткән дә юк. Ягы-ягы белән әле ир балалар көрәш белән дә шөгыльләнә. Рифкать Нургали улы да әнә шулай балачактан спорт белән тәрбияләнә.

– Кечкенәдән чаңгы шууым истә, – ди ул. – Велосипедта йөрү, йөгерү – барысы да булды инде. Казан югары хәрби инженерлык училищесында укыганда хәрби өч төр ярышы (ату, йөгерү, чаңгы), бокс, авыр атлетика (гер күтәрү) белән мавыктым. Аннары инде армиядә хезмәт иткәндә йөгерү көчле иде. Автомобиль инспекциясенә эшкә килгәч, спортка тагын да күбрәк игътибар бирдем: чаңгыда йөрдем, тау чаңгыларын да сынадым, футбол уйнадым. Иртәнге биштә торып, ул көн саен йөгерә идем. Ул чакта күп кенә ЮХИДИ хезмәткәрләре дә шушы үрнәктә спортка тартылды.

– Йөгерүнең файдасы зурмы? – дим.

– Дөресен әйтим, үзем өчен алай зур нәтиҗәсен күрмәдем. Шуның өчен дә велосипедта йөрүгә күчтем. Ләкин ул чакта

Фото: Александр Ефремов, stcdn.business-online.ru

бу спорт төре өчен Казанда шартларның бигүк уңай булмаганын аңладым. Хәзер генә ул велосипед спорты популярлаша бара.

– Рифкать Нургалиевич, ә бүген спорт белән шөгыльләнәсезме? – дим.

– Безнең яшьтә спорт дип зурлап сөйләү бик үк дөрес булмас, физкультура белән шөгыльләнәм дип әйтү кирәктер. Соңгы сигез-ун елда скандинав йөреше белән мавыгам. Сәламәтлек өчен аның уңай нәтиҗәсен бик күрәм. Спорт төрен яшь үзенчәлегеннән чыгып сайларга кирәк, дип уйлыйм.

Бүген Рифкать Нургали улы һәр көн иртәнге алтыдан җидегә кадәр скандинав таяклары ярдәмендә җәяү йөри. Көненә ун мең адым тирәсе җәяү йөрү әңгәмәдәшебез өчен гадәти хәл.

– Безнең учреждениедә эшләүче егетләр арасында чын спортчылар бар, – ди Рифкать Нургали улы. – Алар көн саен максатчан рәвештә шөгыльләнә, марафоннарда катнаша. Һәм мин моңа сөенәм, чөнки спорт белән шөгыльләнгән егетләр эчү, тарту белән мавыкмый, яшь булып калуның да сере шунда. Шуңа күрә хезмәткәрләребез спорт белән шөгыльләнә алсын өчен, шартлар тудырабыз. Хәтта аерым вакыт та бирәбез: атнасына ике мәртәбә барлык хезмәткәрләр өчен стадионда бер сәгатьлек тренировка каралган.

«БАЛАЛАР ГАДЖЕТКА ӨСТЕНЛЕК БИРӘ»

Рифкать Нургали улы балачагын искә төшерде. Менә алар агач чаңгылар белән район үзәгенә мәктәпкә бара. Чаңгының әле бавы өзелә, әле аңа кар ябышып ката... Ләкин шулай да барысы да бәхетле: җәен дә, кышын да өйдә утыручы юк!

– 1995 нче елларда тау чаңгысы белән мавыгып алдым, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем. – 2019 елда инструктор белән шөгыльләнә башлагач, чаңгыда дөрес йөрмәгәнемне аңладым. Югыйсә бер дигән шуа идем. Тренер ярдәмендә һәр хәрәкәтне яңадан өйрәнергә туры килде. Шуның өчен дә кечкенәдән инструктор, тренерлар белән шөгыльләнүең хәерле икән. Әлбәттә, мөмкинлек булганда. Бүген бит велосипедлар да, чаңгылар да без үскәндәге кебек түгел – уңайлы, тизйөрешле. Теләге булган кешегә өйрәнүе җиңел.

– Балачак турында сөйләшкәч, бер сорау бирми кала алмыйм: сезнең чор белән чагыштырганда, бүген яшьләр күбрәк өйдә утыра кебек тоелмыймы? – дим.

– Әйе, тоела. Ни гаҗәп, шундый яхшы шартларда да яшьләр спортка түгел, ә гаджетларга өстенлек бирә. Мин моны бик зур хата дип саныйм. Яшь вакытта актив хәрәкәт кирәк. Сәламәтлек олыгайган саен ныграк кирәк икәнен яши-яши аңлыйсың: эшләргә, гаиләне туендырырга... Сәламәтлек булмаса, бер генә хыял-максатыңа да ирешә алмыйсың. Без үскәндә мөмкинлекләр дә юк иде: авылга бер стадион. Өйдәге эшләрне эшләп бетергәннән соң, футбол уйнарга йөгерәсең. Аннары, олыраклар сине командага алсыннар өчен, чиратыңны көтеп торасың. Аннан инде бар көчеңә уйныйсың, үзеңне күрсәтергә кирәк бит. Яхшы нәтиҗә күрсәтсәң, сине тагын уенга чакыралар, дигән сүз. Менә бу стимул булган.

Яшьтән сәламәт яшәү рәвеше алып барган кеше бөтенләй башкача картая. Һәм моны статистика да раслый. Яшьләрне спортка тарту өчен, аның уңай нәтиҗәләре турында күбрәк сөйләргә, күбрәк күрсәтергә кирәк, дип саный әңгәмәдәшебез.

– Спорт әле ул дисциплина да тәрбияли, – ди Рифкать Нургали улы. – Кеше рухи яктан да үсә. Бу мәсьәләдә ата-ана баласына үзе дә үрнәк булырга тиеш. Бергәләп спорт белән шөгыльләнеп, сәламәт яшәү рәвеше алып барган гаиләләрдә татулык, бер-береңне аңлау, хөрмәт итү була.

...Рифкать Нургали улын якыннан белгән кешеләр гел сокланып сөйли: ул һәрвакыт үзен формада тота, хәтта йөрешендә дә үзенә күрә бер таләпчәнлек сизелә. Мин исә тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: аңа һич кенә дә үз яшен биреп булмый! Спорт яратуның уңай нәтиҗәсе менә шушыдыр ул...

Фото: Александр Ефремов

МӘСКӘҮНЕ ЯУЛАГАН АВЫЛ МАЛАЕ, ЯКИ МАКСАТЧАНЛЫК КАЯ ИЛТӘ?

Руфия Фазылова

«Туган» дип сөйләшә ул. Чирмешән якларында якын иткән кешесенә халык шулай дип эндәшә. Бүген Казанда яши. Шамил Ногманов күпкырлы кеше: җырлый, гармунда уйный, көйләр яза, спорт белән шөгыльләнә. Спорт мастерлыгына кандидат исеме бар. 70 яшендә егетләр кебек калуның серен Шамил абый бик кызык итеп сөйләде.

ЧЫНГА АШКАН ХЫЯЛ

Чирмешән районы Ибрай-Каргалы авылында туып үскән Шамил Ногманов кечкенәдән актив була. Бер төркем авыл малае кыш буе чаңгы шуа. Көн саен диярлек биш чакрым ераклыктагы Әмир авылына – энесе Камил белән энисенең апасы янына барып кайта. Кышын чаңгыда, җәен җәяү дигәндәй. Кыскасы, чыныгып үсә ул.

– Совет мәктәбендә спортка бик зур игътибар бирелде, – дип балачагына кайтты әңгәмәдәшем. – «Аҗаган» уеннары, төрле спорт ярышлары... Армиягә баргач исә, спорт белән кызыксынуым тагын да артты. Даими рәвештә йөгерү ярышлары уза иде, әнә шунда беренчелекне алу өчен буш вакыт булган саен шөгыльләндем.

Шамил абый кызык кеше, юк, максатчан дисәм дөресрәк булыр. Мәктәптә укыганда ук ул Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтына укырга керергә дигән максат куя. Дүрт ел рәттән шунда барып имтихан тапшыра. Һәм дүртенчесендә – 1979 елда теләгенә ирешә!

– Ул вакытта әлеге уку йорты турында халык белми дә иде, – ди Шамил абый. – Казанда түгел, хәтта Мәскәү кешеләреннән сорагач та,

кайдалыгын да әйтә алмыйлар. Белешмәләрдә дә юк. Башта әлеге уку йортын эзләп җан чыкты. Ул вакытта институтка керү бик авыр, шулай да тырышсаң мөмкин иде. ТАССРдан бары өч кеше укыдык.

– Ә сез, гади бер авыл баласы, бу уку йортының барлыгын кайдан белдегез? – дим.

– Газетадан укыдым. Кечкенәдән бик күп укый идем. Авыл китапханәсендә укымаган китап калмады. Ул газета-журналлар турында әйткән дә юк.

Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты студенты булгач, Шамил башкаланың «Динамо» стадионында көн саен шөгыльләнә башлый. Тырыш егеткә тренер билгелиләр. Укырга барганчы, иртән иртүк стадионга килеп, йөгерү белән шөгыльләнә. Кичен – тагын тренировка.

– Бер минут та буш вакытым юк иде, чын менә, – дип сөйли Шамил абый. – Студент чакларыбыз күңелле генә түгел, бик файдалы да узды. Эшләргә, спортны яратырга өйрәндек без. Әлбәттә, укуны да онытмадык. Анда «шәләй-вәләй» йөрсәң тотмыйлар...

«БАРЫСЫ ДА КЫЗЫК...»

Институтта укыганда, Шамил Ногманов МДУ каршындагы журналистика курсларына укырга керә. Төп укудан тыш, шулай атнага берничә тапкыр курсларга да йөри. Әле бит төркемнең профоргы, студентларның профсоюз җитәкчесе дә...

– Ничек барысына да вакыт таптыгыз? – дим.

– Максат йөрткәндер, дим. Студент чагында кемнәр белән генә аралашмадым. Советлар Союзы булгач, төрле милләт вәкилләре белән дус булып, бик кызык яшьлек чоры уздырдым. Армиядән кайткан, спортчы, яхшы укыйм, күтәреп кенә йөртмиләр иде үземне.

Әйткәнемчә, Шамил абый – спорт мастерлыгына кандидат. Тренеры аны кырык ике километр йөз туксан биш метрлы марафоннарда катнашырга әзерли. Моннан тыш, йөзә дә, чаңгы да шуа.

– Тренерымның яраткан сүзе бар: «Әгәр син спортчы икән, йөзәргә дә, чаңгыда да йөрергә тиеш». Шуның өчен төрле ярышларда катнаша идем, – ди Шамил абый.

Институтны тәмамлагач, Шамил Ногмановны Әфганстанга (1986–1988 еллар) җибәрәләр, тәрҗемәче булып йөри ул. Аннан кайткач, Мәскәүдә эшләп ала. 1990 елда аны туган ягына чакыралар. ТАССР Хөкүмәте каршында тышкы икътисад элемтәләре бүлеге ачыла, сентябрь аенда ул шунда эшли башлый. 1995 елда бу бүлек ябыла. Шуннан Шамил Ногманов Казан мэриясенә күчә. Аннан соң исә үз эшен ача.

– Системага яраклаша белмим, – ди Шамил абый. – Һәр нәрсәгә үз фикерем бар. Шуның өчен дә белгечлегем буенча озак эшли алмадым. Ләкин язмышыма бик рәхмәтлемен – акны карадан аера беләм. Гомер буе җыйган багажым төрле хәлләрдән зыян күрми чыгу мөмкинлеген бирә.

Соңгы елларда Шамил абый йөгерү белән шөгыльләнми. Әмма һәр иртәдә сәгать ярым күнегүләр ясый: күздән башлап, аяк бармакларына кадәр җәлеп итәлә. Шуңа өстәп дөрес туклану, тәмәке тартмау... – сәламәт калуның төп сере шул икән.

– Шамил абый, ә ни өчен йөгерүне ташладыгыз? – дим.

– Мәскәүдә яшәгәндә, махсус спорт мәйданчыкларында шөгыльләндем. Казанга кайткач, андый җай булмады. Ә өй тирәли йөгереп йөрү белән килешмим. Аннары, асфальтта йөгерергә киңәш тә итмиләр. Аяк астында җир булырга тиеш. Тик менә хәзер үземдә көч таптым: яңадан йөгерә башладым. Максат – берәр марафонда катнашу.

...Шамил абый кебекләр сирәк очрый. Гадәттә, спортчылар фәннән ерак була, яки киресенчә. Ә ул тарихны, берничә телне белә, эрудицияле кеше. Моңа өстәп җыр-моңга сәләтен дә кушсаң... Янәшәбездә әнә шундый үзенчәлекле, талантлы кешеләр барлыгын белгәннән соң, адәм баласының мөмкинлеге чиксез булуын аңлыйсың. Т

ШАМИЛ НОГМАНОВТАН КИҢӘШЛӘР:

- Йокыдан уянгач та сикереп тормаска кирәк. Бер минут чамасы утырып торсаң әйбәт.
- Иртә белән яткан җирдән генә, башта акрынлап бер аякны, аннан икенчесен бөкләп, җайлы гына хәрәкәтләр ясау файдалы.
- Шуннан 30 тапкыр алмаш-тилмәш күзләрне кул белән ышкырга кирәк. Аннары ике кул белән колакларны ныграк басып томалау яхшы. Шуннан маңгайны чәбәкләп алу мәслихәт. Күнегүләр бик күп төрле, алар барысы да кан әйләнешен яхшырта. Иртән даими рәвештә күнегүләр ясасаң, сау-сәламәт буласың.
- Һәр көнне «каз адымы» белән кимендә бер минут йөрергә кирәк. Бу күнегү организмдагы кальцийны саклап калырга ярдәм итә.

ЕЛ ЯРЫМДА ТАГЫН БЕР ГОМЕР ЯШӘДЕМ...

Сөмбел Мөгыйнова

Җир йөзендә нинди генә кешеләр юк. Гаҗәеп талантлы, зыялы, кызыклы, көчле ихтыярлы, сәерләре дә... Шундый үзенчәлекле, кабатланмас шәхесләрнең берсе – Илдус Әхтәм улы Янышев. Ул мәктәпне – алтын медальгә, Казан федераль университетының юридик факультетын кызыл дипломга тәмамлаган, Эчке эшләр министрлыгында эшләп алган, Казан шәһәр Думасында депутат булган, Татарстанның атказанган юристы, бүгенге көндә Татарстан велосипедчылар берлеге оештыручы да, уңышлы эшмәкәр дә. Иң гаҗәбе: моннан нәкъ алты ел элек, ягъни 2017 елның 28 апрелендә ул берүзе, велосипедка утырып, дөнья тирәли сәяхәткә чыгып киткән һәм, ел ярым эчендә 24 мең чакрым юл үтеп, 13 илне гизеп кайткан! Илдус Янышев белән әлеге карарга ничек килүе, нинди нәтиҗәләр ясап кайтуы һәм башкалар турында сөйләштек.

Фотолар Илдус Янышевның гаилә архивыннан

– Илдус абый, сезне велосипедта дөнья буйлап берүзе чыгып киткән тәвәккәл сәяхәтче буларак беләбез. Ел ярым эчендә кайда гына булмагансыз. Бу хыялыгыз ничек туды?

– Мин Казан шәһәрендә гап-гади гаиләдә туып үстем. Мәктәптә укыганда әдәбият белән кызыксына, китаплар укырга ярата идем. Бигрәк тә француз әдәбиятын. Шәхси китапханәмдә сәяхәтләр турында бик күп китап тупланды. Шуларны укый-укый, дөнья күрергә хыялландым. Геройларымның барысы да сәяхәтче, ә минем нигә мондый мөмкинлегем юк, дигән уй туды. Һәм бу канәгатьсезлек киләчәктә дөнья гизәчәкмен дигән хыялымны ныгытты.

Әзрәк үсә төшкәч, инглиз музыкасы белән мавыгып киттем. Аларны барлый, тәрҗемә итә башладым. Моның өчен инглиз телен ныграк өйрәнергә керештем. Ул елларда бик популяр булган «Битлз» төркеменә гашыйк булдым. Аларның туган иленә бару теләге дә туды. (Алга китеп булса да, әйтик: балачак хыялын Илдус абый, ниһаять, 57 яшендә чынга ашыра. Ул Бөекбританиянең Ливерпуль шәһәренә барып, әлеге рок-төркемнең музеенда була – авт.)

– Димәк, сез китаплар укып, музыка тыңлап үскән бала... Ә спорт?

– Дзюдога йөрдем, беренче разряд алдым. Ә велосипедка килгәндә, абый белән икебезгә бер «Урал» бар иде, мин аңарда 10 яшьтә генә йөрергә өйрәндем, шуңа күрә спорт төре буларак велосипед белән беркайчан да шөгыльләнмәдем.

– Сәяхәт темасына кире әйләнеп кайтсак...

– СССР таркалып, чит илләргә чыгу мөмкинлеге тугач, балачак хыялларым белән яңадан яна башладым. Эчке эшләр министрлыгы системасында 8 ел эшләгәннән соң, үз эшемне ачтым, һәм, ниһаять, сәяхәт итәр өчен бөтен мөмкинлекләр дә барлыкка килде. Башта турист буларак сәяхәт иттем. Аннары прокатка машина алып, гаилә белән бөтен Европаны гиздек. 2007 елда дуслар белән АКШны әйләнеп кайттык. Шул сәяхәтләрнең берсендә Калифорниядә бер немец белән таныштым. Кояшта янып беткән Юрген велосипедына атланган иде. Бөтен кирәк-яраклары шул велосипедына төялгән. Минем исем китте. Янына барып сүз каттым. Ул үзенең Германиядән булуын һәм ялгызы гына велосипедта сәяхәт итүен, Аляскага юл тотуын сөйләде. «Бу сәяхәт сезгә күпмегә төшә инде?» – дип тә сораштым. «Көненә – 10 евро», – диде ул. Безнең акчага күчергәндә, көненә якынча 350 сум дигән сүз. Юрген сөйләгәннәрне ишеткәч, бөтен дөньямның асты өскә килгән кебек булды. Казанга кайтуга, велосипед сатып алдым.

Башта якын араларда йөри башладым. 20 чакрым араны да көчкә-көчкә уза идем. Аннары дустым белән Казаннан Ульяновскига велосипед белән барып карадык, үзебез белән палаткалар да алдык. Бу миңа ошап китте. Тора-бара велосипед һәм кирәк-ярак тутырылган бер рюкзак булса, шул җитә башлады.

Аннан соң гаиләдә дә шундый гадәт керде: велосипедта сәяхәт итүче төрле милләт кешеләрен үземнең өемдә кундырып, ял иттереп, ашатып-эчертеп, юындырып җибәрә башладым. Бездә немец, полякларның тукталганы булды. Алар да дөнья тирәли сәяхәт итүчеләр. Юлда барганнарын күреп, үзем таныша идем. Чакыргач, әлбәттә, баш тартмыйлар. Туктап, хәл алып, яңадан кузгалалар. Теге Юргеннан сорашкан кебек, алардан да мондый сәяхәтләрнең нечкәлекләре турында сораша идем.

– Бу вакытта сез берүзегез генә, велосипедка утырып, дөнья тирәли сәяхәткә чыгарга әзер идегезме? Әллә инде шикләндегезме?

– Әлбәттә, әзер түгел идем. Бик озак уйландым. Ниһаять, 50 яшьләремдә генә шулай ялгызым гына сәяхәткә чыгарга дигән катгый карарга килдем. Хыялымны чынга ашырмасам, гомерем заяга уза кебек тоелды. Ләкин шул вакытта (2010 ел – авт.) мине Казан шәһәр Думасына депутат итеп сайладылар. Җәмәгать эшләре белән шөгыльләнә башлагач, сәяхәт кичектерелде. Депутатлык эшемнең бер юнәлеше башкалабызда велосипед транспортын үстерү булды. Соңрак, бу вазыйфам тәмамлангач, хыялыма кире кайттым.

– Сәяхәткә чыгарга ничек әзерләндегез?

– Иң әүвәл сәламәтлекне карарга кирәк. Фитнеска йөрдем, көн саен күнегүләр ясадым.

Илдус Янышев сәяхәтенә караган кызыклы саннар:

438 – юлда булган көннәр саны,

шуның **408** көне – велосипедта;

24 500 км – шул вакыт эчендә узган юл озынлыгы,

шуның **116 910 метры** – тауга күтәрелүләр.

Илдус Янышев Мәскәүдән Европага барып җитә – Латвия, Литва, Польша, Германия, Нидерландлар, Бельгия, Франция, Испания, Португалия, Бөекбритания аша үтә. 2018 елның гыйнварында АКШка оча һәм анда велосипедта Атлантик океан ярындагы Флорида штатыннан Тын океан ярындагы Сан-Диего шәһәренә кадәр бара. Аннары Кытайның Шанхай шәһәренә оча, шуннан тагын велосипедта Владивостокка юл ала, алга таба бөтен Россияне гизеп, Казанга кайта. Туган ягына кайткач, күргәннәре турында «Бәхет эзләп – велосипедта» дип аталган китап яза.

Витаминнар эчтем. Билгеле, минем яшьтә ерак юлларга чыгып китү зур тәвәккәллек сорый. Үз эшемне дә җайлап калдырырга кирәк. Гаиләмне әхлакый яктан да, матди яктан да әзерләргә. Озак вакытка чыгып китәсемне аңлап эшләдем. Ким дигәндә бер ел узачагын белә идем.

– Якыннарыгыз бу карарыгызны ничек кабул итте?

– Барысы да: «Барма!» – дип үгетләде. Ышанмадылар, дөресен әйткәндә, үзем дә шикләрдән арынып бетмәгән идем әле. Шуңа күрә Казаннан шау-шу куптармыйча гына кузгалып киттем. Мәскәүгә кадәр барып карыйм да, аннан күз күрер, дип уйладым. Мәскәүгә баргач кына, журналистларга бу турыда язарга, сөйләргә рөхсәт бирдем.

– Илдус абый, велосипедыгызны берәр яр кырыенда ташлап, башка транспортка утырып, өйгә кайтып китәсе килгән чаклар булдымы?

– Яшермим: мондый халәт бик еш булды. Юлның иң авыр өлешләрендә. Мәсәлән, Испаниядә Пиреней тауларына, туктамыйча, 1800 метр биеклеккә күтәрелергә туры килде. Җитмәсә, велосипед, аңа төялгән әйберләрнең авырлыгы да шактый – 60 килограмм. Ару-талчыгу да өстәлде. Аннан соң организм үзеннән-үзе иялəште. Шул чакта 15 кг авырлыгымны югалттым.

Спорт сөюче Янышевлар гаиләсе.

Сәяхәткә чыгар алдыннан да, кайткач та комплекслы медицина тикшерүе уздым. Хатыным Гөлнара – белгечлеге буенча спорт табибы. Фиништан соң медицина күрсәткечләре яшәү көчемнең 75 процентка артуын раслады. Миңа ул вакытта 57 яшь булса да, тикшеренүләр биологик яшемне 41 дип күрсәтте.

– Хатыныгыз Гөлнара ханым сез булачак урыннарга алданрак барып торган, медицина ярдәме күрсәткән, дип беләбез. Димәк, хыялыгызның тормышка ашуында аның да роле бар?

– Әлбәттә! Хатыным – балачак хыялымны чынга ашыруга зур өлеш керткән кеше. Дөнья тирәли сәяхәт – уртак җиңүебез. Билгеле, ул бик борчылды. Беренче айларда гел шалтыратып торды. Аннан иялəнде кебек, миңа ышанычы артты, күрәсең.

– Илдус абый, сез велосипедта озак сәяхәт итү мөмкинлеген исбатладыгыз. Юлда төп авырлык нәрсәдә булды? Иң истә калган вакыйга?

– Сәяхәтнең һәр көне үзенчәлекле, һәр көне үзенчә күңелдә уелып калды, аерып әйтү мөмкин дә түгел. Көндәлек тормышта гына ул көннәр бер-берсен кабатлый. Сәяхәт вакытында иң куркынычы – сусыз калу. Авыр вакытларны искә алырга яратмыйм. Шулай да Нью-Йорктагы бер күңелсез хәл турында әйтеп китәргә була: берәү велосипедымны урларга маташты, дөресрәге, таларга. Үз күз алдымда велосипедыма утырып качмакчы иде. Аны куып тотып, үземнең дөнья гизүче сәяхәтче икәнемне аңлатырга, велосипедымны кире кайтарырга туры килде.

– Велосипедта сәяхәт итүчеләргә гади кешеләр ничек карый? Сезгә ярдәм иткән очраклар булдымы?

– Һичшиксез! Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз – юк: янымда гел фәрештәләрем булды. Мин аларны янәшәмдә сизә идем, алар азык, су табарга мөмкинлекләр күрсәтеп торды. Сәяхәтемнең яртысын гади кешеләрдә кунып, бушка ашап үткәрдем. Студентлардан алып, АКШ сенаторына кадәр кунак итте мине. Төрле вакыт булды: төнне бомжлар белән дә, үз телəгем белән полициядәге тоткыннар янында да, чиркәүдә дә, туктальшларда да үткәрергә туры килде. Бу яктан тәҗрибәм зур. Дусларга, таныш-белешләргә еш әйтәм: шушы 438 көндә мин тагын бер гомер яшәдем, дим. Бүген үземне 124 яшьлек кеше итеп тоям.

– Сәяхәт вакытында билгеле бер максатларны күздә тоттыгызмы? Нинди нәтиҗәләр ясадыгыз?

– Әлеге сәяхәттә үзем өчен зур ачышлар ясадым. Беренче чиратта, бүген мин үз-үзем белән горурланам. Минем белән гаиләм, балаларым горурлана. (Илдус абыйның ике кызы һәм бер улы бар – авт.) Физик мөмкинлекләрем артты. Мәсәлән, хәзер Лаеш, Балтач, Арча кебек районнарга барып кайту минем өчен берни түгел.

ТАТАРСТАН БУЕНЧА ВЕЛОМАРШРУТЛАР СХЕМАСЫ



Икенчедән, дөньяга карашым үзгәрде, рухи яктан тулысынча үзгәреш кичердем, бу бит үзенә күрә бер мәдәни хаҗ. Мин ул вакытта да уңышлы эшли торган эшмәкәр идем. Яхшы машинам, шәхси йортым, рестораннарда тукланырлык, биш йолдызлы кунакханәләрдә тукталырлык мөмкинлекләрем бар иде. Ләкин боларның барысыннан да баш тартып, юлга чыктым. Кай көнне авызыма бер сынык ипи дә капмадым, кай көнне киптерелгән ипи белән генә тукланырга туры килде. Юлымда очраган кешеләр нәрсә бирсә, шуны ашадым, туктап, урманда гөмбә җыйдым... Ялгыз гына сәяхәт итү – медитация дә ул. Юлда кеше үз-үзе белән генә кала. Күңеле белән сөйләшә. Авыр вакытларда фәрештәләргә, Күкләргә ялвара, дөрес юл күрсәтүләрен сорый. Дөнья тирәли сәяхәткә кем беләндер чыгып китеп булмыйдыр. Ялгызың хәерлерәк.

Өченчедән, велосипед белән сәяхәт иткәндә, чит илләрнең мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән якыннан танышасың, халкын күрәсең. Илдәге тәртипнең үзенчәлекләрен өйрәнәсең. Туристлар өчен төзелгән сукмаклар буенча түгел, ә үзең сызган маршрут буенча йөрисең.

– Кайсы илләрдә велосипедчылар өчен шартлар яхшырак? Татарстанда хәлләр ничегрәк?

– Нидерландлар – велосипедчылар өчен иң уңайлы ил. Анда велосипедлар саны кеше саныннан күбрәк. Мәктәп укучылары да, министрлары да, миллионерлары да – барысы да велосипедта. Велосипед – көнкүрешнең бер өлеше. Кызыклы факт: Бөтендөнья бәхет рейтингы тикшеренүләре буенча, бу ил иң бәхетлеләр исемлегенә кергән. Чөнки велосипед сәламәтлекне ныгыту белән бергә, кешене бәхетле дә итә икән. Яхшы лимузиннарда утырганнарның елаганнарын күп күрдем, ә велосипедта баручы бер генә кешенең дә елаганын күргәнем юк, диләр бит әле.

Татарстанда велосипедчылар хәрәкәте төрле төбәкләрдә төрлечә оештырылган. Шәхсән мин үзем бу яктан Әлмәт шәһәре өчен бик шат. Шәһәрдә бик яхшы программа эшләп китте, велосипедчылар өчен уңай шартлар тудырылды. Түбән Камада да нәкъ шулай, анда велосипед юллары актив төзелә. Чаллыда да бу теманы күтәргәннәр иде, тик җитәкчеләре алышынгач, тукталып калды. Казан, кызганыч, бу яктан калыша. Шәһәр болай да тыгыз төзелгән, кызу темплар белән яши, дигән сәбәпләр китерелә. Ләкин Европа илләренең башкалалары Казанга караганда да тыгызрак салынган. Шуңа да карамастан шәһәрләрнең буеннан буена велосукмаклар сузылган. Без тик ятмыйбыз, эшлибез. Фикердәшләрем белән бергә Татарстан велосипедчылары берлеген оештырдым. Максатыбыз – велосипедта йөрү мәдәниятен үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, туган ягыбыз табигатен кайгырту. Хәзерге вакытта менә «Тукай юлы» проектын эшлибез. Аның инде схемасы бар. Татарстан буйлап велосипедта сәяхәт итәргә мөмкинлек тудырасыбыз килә. Тукай йөргән сукмаклардан, Кушлавыч, Яңа Кырлай, Арча аша...

– Илдус абый, сез «Ротари Интернешнл» халыкара волонтёрлык оешмасының экология комитеты рәисе дә бит әле. Бу юнәлештә нинди проектлар бар?

– Беренчесе – «Чиста сулар – сәламәт планета» проекты. Максат – дөнья океанына чүп-чар, зарарлы калдыкларның әлегүенә юл куймау. Икенче проект – яшелләндерү. Мәсәлән, без волонтерлар белән, Казан кырыена чыгып, үсентеләр утыртабыз. Өченчесе – «Велоизгелек» проекты. Без иске велосипедларны җыеп, төзәтеп, аларны матди яктан авыр яшәгән гаиләләргә тапшырабыз. Бу юнәлешләр бер-берсе белән бәйләнгән. Мисал өчен, бер чакрым ераклыкны велосипедта яисә җәяү узган кеше җәмгыятькә күпме файда китерә, сәламәтлек саклау чыгымнарын киметә, әйләнә-тирә мохитне пычранудан саклый. Территориябезнең 19 проценты урманнар белән капланган. Һавага бүленеп чыккан углекислый газны эшкәртү өчен 25 процент урман булырга тиеш. Менә бу турыда уйланырга кирәк.

– Илдус абый, тагын нинди хыял-максатлар белән яшисез? Кабат шундый зур сәяхәтләргә чыгу нияте бармы?

– Вазгыятькә бәйле рәвештә, әлегә ерак араларга чыгу мөмкинлеге юк. Республикабызның бөтен районнарын йөреп чыгарга дигән ният бар. Татарстанны башка яктан ачасым килә, бу турыда фильм төшерергә, китап язарга хыялланам. Планнар зурдан... Ходай безгә кул-аяклар биргән. Бүген кешелек бөтенләй аз хәрәкәтләнә. Күпләр төшенкелектә, депрессиядә яши. Ә бит 20 минут велосипедта йөргәннән соң ук, организмда бәхет гормоннары барлыкка килә. Активрак яшик! Хәрәкәттә – бәрәкәт! Т

–Менә сиңа йөз миллион сум акча, һәм син бу велосипедны онытасың, бүтән беркайчан да аңа утырмыйсың, дисәләр, мин, һичшиксез, велосипедны сайлаячакмын.

Илдус Янышев

БУ МӘКТӘПТӘ КИЛӘЧӘК БАШЛАНА

Белем бирү программасында театрны, чит телләрне, проект эшен мөгаллимнәрнең мавыгып эшләве, балалар энергиясе һәм ата-аналар ярдәме белән берләштерсәк, нәрсә килеп чыгачак? Казанның Беренче инженерлык лицеенда бу эксперимент 10 ел дәвам итә.

Фотолар Беренче инженерлык лицееннан алынды. РЕКЛАМА

БЕЛЕМ ҺӘМ ТЫЛСЫМ БЕЛӘН ТУЛГАН КӨН

Сиңа 10 яшь. Син парта артында утырасың, алдыңда инглиз телендә биремнәр язылган кәгазь бите, һәм син ул биремнәрне тиз генә чишеп куясың. Аннары методист өстәле янына утырып, аңа инглиз телендә сыйныфыгыз белән Зөя утрау-шәһәренә экскурсиягә баруыгыз турында сөйлисең. Син рухланып сөйлисең, сиңа бу хатирәләр, үзеңнең алар турында сөйләвең һәм укытучының игътибар белән тыңлавы ошый. Син бүлмәдән канатланып чыгасың, чөнки әле генә үз гомереңдә беренче халыкара имтиханыңны уңышлы тапшырып чыктың. Алда җәй көтә, ә аннары – Казанның Беренче инженерлык лицеендагы ILS (Intellectual Linguistic School) лингвистика мәктәбенең бишенче сыйныфы.

Биредә укуның җиңел барышы, укучыларның белемгә, аралашуга, төрле проектларда катнашырга омтылуы – чып-чын могҗиза. Тәүге дәресләрдә беренче сыйныф укучыларына аларның «тылсымчылар мәктәбе»нә, ягъни ниндидер тылсымнар ясала торган уку йортына килгәнлекләрен аңлаталар. Алар башта – парта артында, аннары чын фәнни лабораторияләрдә ачышлар ясаячак. ILS мәктәбендә төп тылсым осталары – уку йорты мохитен һәркемгә уңайлы һәм кызыклы итеп оештыручы педагоглар. Могҗиза – заманча тенденцияләрне һәм таләпләрне исәпкә алган фән, педагогика.

– Без Инженерлык лицее составына керәбез, аның төп концепциясе – балаларны «лингво+техно» белем бирү принцибы нигезендә үстерү. Балалар башлангыч мәктәптән урта сыйныфларга җайлы гына күчә алсын өчен, сыйфатлы әзерлек кирәк. Шуңа күрә

безнең мәктәп тулы көн программасы белән яши, – ди башлангыч лингвистика мәктәбе директоры Эльмира Митрофанова. – Төшке ашка кадәр – ФГОС буенча дәресләр, өйләдән соң – һәркем өчен мәҗбүри булган өстәмә дәресләр. Көннең беренче яртысындагы укытучыларны төшке аштан соң тьюторлар алыштыра. Бу вазыйфаны без революциягә кадәрге гимназиядән үрнәк итеп алдык, анда һәр сыйныфка бер ханым билгеләнгән булган. Тьюторларның махсус миссиясе бар. Бу остазлар балаларга мөстәкыйль рәвештә әзерләнүдә генә (өй эшләрен эшләү әнә шулай атала) булышып калмый, ә алар белән немец яки инглиз телләрендә сөйләшә дә.

Сүз уңаеннан, көннең беренче яртысында тьюторлар Инженерлык лицееның Smart Kids балалар бакчасында белем бирә, бу исә интеллектуаль яктан да, эмоциональ яктан да уку-укыту эшенең өзлексезлегендә зур роль уйный.

УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ӨЙРӘТҮ

– Кичә без урманга бардык һәм мин моны үзем белән алдым! – дип сөйли такта янына чыккан укучы немец телендә.

– Плащ! – дип фаразлый шулай ук немец телендә бер сыйныфташы.

– Юк, бу плащ түгел, – дип җавап бирә укучы.

– Свитер!

Бу уенны балалар тьютор белән төшке аштан соң уйный. Шулай итеп, көннең беренче яртысындагы дәрестә үткән кием-салым темасы материалы ныгытыла.

– Уен – уку-укыту процессында иң яраткан шөгылем. Ул теләсә кайсы чит телне укыту процессында да бик мөһим. Бу – аралашу практикасының бер төре, шул рәвешле без ялгышырга курыкмыйча аралашырга өйрәнәбез, – ди немец теле укытучысы, тьютор Людмила Никитина.

Тьюторлык балаларның сөйләм күнекмәләрен үстерү коралы гына түгел, ә педагоглар өчен үсеш чарасы да әле.

– Педагогика күңелемә гомумән бик хуш килә, ул башка фәннәрне дә колачлый һәм даими үсештә тора. Һәм миңа монда, ILS мәктәбендә, бер урында таптанмавыбыз ошый, – ди Людмила Никитина.

Мәктәптә бер-берсенең ачык дәресләренә йөрү, методикалар белән уртаклашу гадәткә кергән. Чирек ахырында тьюторлар башкарылган эшкә хисап дәресләре үткәрә. Моннан тыш, алар профильле конференцияләрдә катнаша. Әнә шундый төбәкара конференциядә Людмила Никитина үз фәнни эшен һәм балаларның модальлеге, ягъни аларның мәгълүматны кабул итүнең өстенлекле – аудиаль, визуаль, кинестетик ысулы нигезендә тел укыту методикасын тәкъдим итә. Людмила Анатольевнаның эше беренче урынны яулый.

УКУ-УКЫТУ ТУЛЫ БЕР ГАЛӘМ КЕБЕК

Тьюторлык – ILS педагоглары тарафыннан эшләнгән телләр укыту экосистемасының бер өлеше ул.

– Коммуникатив методикага, ягъни аралашу аша өйрәтүгә баштан ук өстенлек бирдек. Максатыбыз – балаларның чит телләрне туган телләре кебек үк тирәнтен белүенә ярдәм итү. Бу аларга киләчәктә фән һәм технологияләрнең махсус лексикасын куллануга күчү җиңел булсын өчен кирәк. Әлеге ысулны күздә тотканда, телне дәрестә генә өйрәнү җитми. Шуңа күрә безнең программага, ФГОС буенча дәресләрдән тыш, хәзер тьюторлык да, шул тел иясе белән дәресләр, World around us («Безне чолгап алган дөнья») курсы буенча дәресләр дә керә. Уку-укыту эше сыйфатының үрнәкләре итеп, без Speak English халыкара мәктәбе һәм Гёте-институт проектларын сайладык, – дип сөйли уку-укыту эше буенча директор урынбасары, югары квалификация категорияле инглиз теле укытучысы, мәктәптәге телләр укыту программаларының инициаторы һәм авторы Екатерина Гаврилова.

ILS мәктәбендә эшләнгән программаның нәтиҗәлелегенә ачык мисал – Гёте-институт белән хезмәттәшлектә оештырыла торган Fit in Deutsch халыкара имтиханында һәм, 4 нче сыйныфтан башлап, Инженерлык лицее укучылары ел саен тапшыра торган PTE (Person test of English of young learners) халыкара имтиханында бик шәп билгеләр. Имтиханнарны балалар үзләре тапшыра, остазлары сынауга кертелми.

БӨТЕН ДӨНЬЯ – ТЕАТР

– Бу көн ничек узачак? Язмыш миңа ни алып килгәнен кем белә? / Кем белә... / Ирекле булу бик кызыклы булса кирәк, бөтен дөнья синең алда* – дип җырлый сәхнәдә Бродвейның мәшһүр «Музыка авазлары» мюзиклы герое Мария.

Монастырьда тәрбияләнгән, тормышта үз урынын эзләгән Мария исемле кыз ролен Инженерлык лицееның 6 нчы сыйныф укучысы София Исмәгыйлова башкара. Лицейның «Арт Спирит» (Art Spirit – сәнгать рухы дигән сүз – ред. иск.) театр коллективы бу мюзиклны Санкт-Петербургка «Планетаның киләчәге» халыкара иҗади конкурсына алып барган. Жюри аңа зур бәя бирә – «Арт Спирит» I дәрәҗә лауреат дипломы белән бүләкләнә.

– Әлегә бу минем өчен төп роль, – ди София. – Театр белән уйнаган иң «өлкәннәр» пьесасы ул, һәм гомумән, беренче пьеса, моңа кадәр спектакльләрдә бары тик экиятләр генә булды. Без күп репетицияләр үткәрдек һәм жюри алдында әллә ни каушамадык. Гастрольләрдә безнең кебек үк балалар алдында чыгыш ясау күбрәк дулкынландырды. Тамашадан соң яшьтәшләребезнең автограф алырга килүе бик күңелле.

«Арт Спирит» тьюторлар алып барган лингвистик театрларның һәм башлангыч мәктәптәге «Пиноккио» музыкаль театрының дәвамчысы булып тора. Ә бу театрлар – ILS мәктәбендә балаларны чит тел мохитенә чумдыру һәм ата-аналар белән ныклы элемтә урнаштыру чарасы.

** Ричард Роджерс һәм Оскар Хаммерстайнның Ховард Линдси һәм Рассел Крауз либреттосына язылган «Звуки музыки» мюзиклы, 1959 ел; М. Парыгин тәрҗемәсе, 2005 ел.*

БЕРЛӘШТЕРӘ ТОРГАН ИҖАТ

– Укытучыларның, спектакльләрне оештыручыларның дәртләнеп, илһамланып эшләве – балаларның яңа җиңүләре дигән сүз. Ике ел элек «Пиноккио» музыкаль театры коллективының 60 тан артык катнашучы теркәлгән халыкара конкурска гариза бирүен ишеткәч, анда җиңү мөмкин түгел дип уйлаган идек. Ләкин «Пиноккио» сайлап алу турын узды, чит илләргә гастрольләргә китте һәм җиңүче дипломы белән кайтты. Шул рәвешле без педагогларга, балаларга ышанырга өйрәнәбез. Моның өчен рәхмәт! – ди Софиянең әнисе Анна Исмәгыйлова.

– Чирек саен башлангыч мәктәпнең һәр сыйныфы инглиз телендә спектакль әзерли һәм аны әкиятләр фестивалендә күрсәтә. Бу чын бәйрәм. Балаларның янып торган күзләрен, тамашачылар алдында чыгыш ясауның аларга нинди рәхәтлек китерүен күрү бик сөендерә. Без тамашаларга да киләбез, костюмнар, декорацияләр белән дә ярдәм итәбез. Спектакль куйган чакта педагоглар фикеребез белән кызыксына, безне мәктәпнең иҗади тормышына җәлеп итәләр. Инженерлык лицеенда театр студияләре – суперидея, ул бик нык берләштерә, – ди 6 нчы сыйныф укучысы Камилә Нәбиуллинаның әнисе Айгөл Нәбиуллина. София кебек үк, Камилә дә театрдагы карьерасын «Пиноккио»дан башлый, ә хәзер ике кыз да «Арт Спирит» студиясендә чыгыш ясый.

Лицей өчен театр – тел күнекмәләрен үзләштерү һәм үз-үзеңне иҗади тормышка ашыру ысулы гына түгел, ә уңышларга илтә торган бер юл да. Репетицияләр балаларга үз тавышлары, аудитория игътибары белән идарә итә белергә, үзләрен ишетергә һәм тыңларга телләрлек итеп сөйләргә өйрәнергә булыша.

ҮЗ-ҮЗЕҢӘ АЧКЫЧ

Микропластик – бик вак (биш миллиметрдан кечерәк) пластик кисәкчекләре ул. Кайбер белгечләр әйтүенчә, кеше организмына атнага якынча 5 грамм, ә елына 250 грамм чамасы микроплас-

тик әләгә. Бу массаның бер өлеше эчке органнарга утыра, һәм ул утырымнарның организмга тәэсирен әле өйрәнә генә башладылар. Әйләнә-тирә мохит белән дә шул ук хәл. Өстәвенә, микропластик өчен матдә концентрациянең рөхсәт ителгән чик күрсәткечләре әле дә билгеләнмәгән. ILS мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы Михаил Никулов С.П.Королев исемендәге төбәкара проект конференциясенә тәкъдим ителгән эшен шул проблемага багышлый.

– Бәлки, безгә пластик куллануны чикләргә, аны башка, экологик яктан чистарак материаллар белән алыштыру турында уйларга кирәктер, – ди Михаил. – Үзем ясаган нәтиҗәләр турында проект конференцияләрендә сөйлим. Конференцияләргә әзерләнергә һәм аларда катнашырга яратам, чөнки шул рәвешле идеяләремне үстерергә, аларны таратырга һәм башкалар белән тәҗрибә уртаклашырга мөмкин.

Укучыларның проект эше – Инженерлык лицее традициясе. Балалар бакчасында, башлангыч мәктәптә, урта һәм югары сыйныфларда балалар үз дәрәҗәләренә туры килгән проектлар белән шөгыльләнә. Темаларны алар һәрвакыт үзләре сайлый.

– Бездә һәр бала талантлы дип саныйбыз. Бу талантны ачарга булышу – безнең бурычыбыз, – ди беренче квалификацион категорияле башлангыч мәктәп укытучысы, башлангыч сыйныфлар методик берләшмәсе җитәкчесе, «Сәләтле бала» программасының кураторы Татьяна Майорова. – Үсә барган саен, балаларның кызыксынулары үзгәрә. Еш кына шулай да булырга мөмкин: икенче сыйныфта математикадан уңышларга ирешкән балага өченчедә тарих кызыклы тоела, ул бу фән белән җитди мавыгып китә. Без бөтен нәрсәне бергә эшләргә тырышабыз – Яңа елга төрле уенчыклар ясыйбыз, милли курчаклар тегәбез, робот техникасын өйрәнәбез. Кызлар математикада йолдыз булырга мөмкин, ә малайлар халык гамәли сәнгатендә осталыгын күрсәтә ала. Үзләренең барлык сәләтләрен күрсеннәр һәм алар белән идарә итәргә өйрәнсеннәр өчен, балаларга мөмкинлек тудырырга кирәк.

ҖИҢЕЛӘ БЕЛҮ ДӘ – СӘНГАТЬ

«Сәләтле бала» программасы – мәктәпнең үз проекты. Аның максаты – баланың шәхси сәләтләрен ачыклау һәм аларны үстерү өчен тиешле мохит булдыру. ILS мәктәбенең өстенлеге шунда: биредә мондый индивидуаль эшне оештыру мөмкинлеге бар, чөнки сыйныфта укучылар саны 23 тән артмый. Программаның нәтиҗәсе – башлангыч мәктәп командалары катнашкан муниципаль, төбәк, федераль дәрәҗәдәге конкурс һәм олимпиадаларда катнашучылар һәм җиңүчеләр санының елданел арта бара. Бер ел эчендә 180 укучыга бу бәйгеләрдә катнашкан, призлы урын алган һәм чемпион булган өчен бирелә торган 246 грамота туры килә.

Мәктәптә проект һәм олимпиадаларда катнашуны балаларның үзмаксаты итеп түгел, ә чираттагы белем баскычына һәм гомумән җәмгыятьтә яшәүгә әзерлекнең бер өлеше итеп карыйлар.

– Конкурслар һәм олимпиадалар, шул исәптән сыйныф дәрәҗәсендәгеләре дә – балалар арасында тискәре күренешләргә каршы көрәшер өчен бик шәп корал. Әгәр сыйныф тату бер команда булса, балалар бер-берсе өчен утка керергә әзер. Әгәр сыйныфта берничә команда икән, алар бер-берсе белән гадел интеллектуаль көрәштә көч сынаша. Шул рәвешле алар бергәләп эшләргә, җиңәргә һәм тагын бер мөһим сыйфат – җиңелергә өйрәнә, – ди Эльмира Митрофанова. – Моннан тыш, дәртләнеп эшләү һәм үз-үзеңә ышаныч өчен балага үзенең кайсыдыр өлкәдә иң алдынгы, иң оста булуын аңлау мөһим. Кемдер казанышларының гавам алдында танылуын ярата, кемгәдер укытучыдан берничә мактау сүзе дә җитә. Ләкин алар, һичшиксез, ихлас булырга тиеш. Һәр-

кемнең җиңү мөмкинлеге булсын өчен, без бик күп ситуацияләр булдырырга тырышабыз.

ОЧКЫННАР ЧӘЧРӘП ТОРГАНДА

«Йөрәгемне балаларга бирәм», – совет чорының күренекле педагогы Василий Сухомлинскийның 1970 нче елларда чыккан китабы әнә шулай дип атала. Ул вакыттан соң тормышыбыз бик нык үзгәрде, әмма хәтта цифрлашу һәм зур тизлекләр чорында (бәлки, нәкъ менә шушы чордадыр) мәгариф системасында укытучының роле бик мөһим. Элеккечә үк, мәктәп – бала – ата-ана триадасының уңышы педагогның намуслы, әдәпле, фидакяр булуына, үз-үзен аямыйча эшләргә әзерлегенә, яңалыкка омтылуына һәм үз һөнәрен яратуына бәйле. ILS мәктәбендә бу процессларны бик яхшы аңлап эш йөртәләр, шуңа күрә биредә укытучылар балалар кебек үк үсеш, иҗат, һөнәри камиллеккә омтылу мөмкинлекләренә ия.

– Мин балачактан ук укытучы булырга хыялландым. Хәзер 30 елдан артык педагогик стажым бар, ләкин бу мәктәптә генә мин үз-үземне камилләштерүнең үзем теләгән дәрәҗәсенә ирешә алдым. Моңа мәктәпнең эш системасы, аның атмосферасы ярдәм итә, – дип сөйли башлангыч сыйныфлар укытучысы, Михаил Никулов һәм башка балаларның проект эшләре җитәкчесе Инна Скрыпник. – Монда барысы да күз алдында. Без һәр баланың уңышын бәяли һәм авыр урыннарда аңа ярдәм итә алабыз. Нинди дә булса яңалык ачканда балалардан сирпелгән нур миңа көч бирә, уңышсызлыкка юлыкканда, аларның күңел төшенкелегенә бирелмәве, максатка ахыргача барырга әзерлеге сокландыра. Аларга булышасы, җавап итеп үзләренә дә көч бирәсе килә.

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК – УҢЫШ ДИГӘН СҮЗ

ILS мәктәбендә зур эш тәҗрибәсе булган педагоглар өчен дә, күптән түгел югары уку йортын тәмамлап килгән белгечләр өчен дә уңайлы мохит тудырганнар.

– Иң башта мин балаларның эти-әниләре өчен борчылдым. Алар миннән өлкәнрәк. Күпчелек гаиләләрдә укучыларым – икенче, өченче, кайвакыт дүртенче бала. Һәм менә мин, яшь педагог. Мин гел берәр нәрсәне дөрес эшләмәүдән курка идем. Ләкин соңыннан эти-әниләр – мине, мин аларны белә-таный башладым, һәм барысы да җайланып китте. Ата-аналарның ышанычы минем өчен мөһим, чөнки бу – балаларның миңа карата ышанычына төп нигез, – ди Елизавета Романова. Ул ILS мәктәбендә укытучы булып өч ел эшли, бергә университетны тәмамлауга ук килгән.

Балаларныкы кебек үк, мәктәптә һәр укытучының үз таланты бар. Елизаветаның андый сәләте – шаулап торган сыйныфны мизгел эчендә тынычландыруга ия тылсымлы карашы һәм математика укытуы. Ел ахырында аның сыйныфында математик уеннар уза. Алар һәрвакыт бик кызык уза, уен дәрте һәм энтузиазм хөкем сөрә. Тактада мисаллар күрсәтелә һәм балалар аларны тизлеккә чишүдә ярыша. «Биш! Юк, ике! Юк, дүрт!» – дип кычкырып җибәрә малайлар, дулкынланудан сикергәли-сикергәли. Математика авыррак бирелгән укучыларга эти-әнисе белән бергә ярдәм кулы сузып, Елизавета Валерьевна бу ярышларга ел буе әзерләнә. Тырышлык җимешен бирә. Әйтик, узган бәйгедә җиңгән кыз өчен математика элек иң авыр фән булган.

ДӘВАМЫ БАР

Бу уку елында ILS лингвистика мәктәбенә 10 яшь тула. Бу истәлекле датага мөгаллимнәр һәм аларның шәкертләре бик шәп нәтиҗәләр – фәннәр буенча олимпиадаларда, иҗади конкурсларда, төрле дәрәҗәдәге фәнни конференцияләрдә күпсанлы җиңүләр белән килә. Балалар үз мәктәпләрен яраталар, ә мәктәп аларны ярата. Чын мәхәббәт карашларның бер-беренә түгел, ә бер тарафка юнәлүендә ул, диләр. ILS мәктәбендә укытучылар, балалар һәм ата-аналар бер якка – киләчәккә карый.



Венера Хәйретдинова,
Лицей – инженерлык үзәге директоры:

– ILS – хыялның тормышка ашуы ул. Укытучыларның, ата-аналарның, балаларның яхшы, кызыклы, үсештәге мәктәп турында хыялларының чынга әверелүе. Һәр педагог һәм, гомумән, бөтен коллектив бүген һәм шушы ун ел дәвамында, һәр бала бүген кичәгедән яхшырак булсын өчен, хәленнән килгәннең барысын да эшлиләр. Бу үсеш сизелмичә бара, ләкин колачлы уртак хезмәтнең нәтиҗәләре күзгә бәрелеп тора. Кечкенә лингвистика мәктәп бүген югары уку йортына кадрге инженерлык программасы буенча белем бирә торган лицейның нәтиҗәле нигезен тәшкил итә. Мин, җитәкче буларак, моны бик югары бәялим. Кадерлеләрем, бәйрәм белән сезне! Шулай дәвам итегез! Бары тик алга гына!

Сезнең ВК.

ФАЙДАЛЫ ЭНЕРГИЯ

«Татэнергосбыт» АҖ директоры Рифнур Хәйдәр улы Сөләйманов – хезмәтне яратучы һәм кадерен белүче, аңа үз гомеренең күбрәк өлешен бик теләп багышлаучы затлардан берсе. Үзенең кабинетына ул эш көне башланыр вакыттан күпкә иртәрәк килә. Бөтен эшкә өлгерер өчен таңнан тору гадәте үсмер чагыннан, Яңа Чишмә районы Акъяр авылында яшәгән чордан ук калган. Анда ул табигать матурлыгына сокланырга һәм җирдә эшләүче крестьяннарның авыр хезмәтен хөрмәт итәргә өйрәнгән. Һәм бөтен киләчәк тормышына хәтеренә сеңдергән: һәркайда һәм һәрвакыт иң зур байлык – кешеләр ул.

Финанслар белән идарә итү системасында чирек гасыр эшләгәннән соң республиканың энергетика тармагына күчкәч тә, Сөләйманов үзенең төп принципларына хыянәт итмәгән. «Әгәр кеше файда китерергә тели икән, эштән качмый, киресенчә, аны эзли. Мин хезмәт биографиямне чор һәм эпохаларга бүлмим – һәр заманның үз матавыклары була. Теләсә кайсы рангтагы җитәкченең эше – һәрвакыт әхлакый вә физик көч киеренкелеге һәм зур җаваплылык ул», – дип саный Рифнур Хәйдәр улы.

«Татэнергосбыт» белән җитәкчелек иткән дистәдән артык ел эчендә Сөләйманов энергия белән тәэмин итүчеләрнең төрле буыннары казанышларын саклап һәм арттырып кына калмыйча, югары дәрәҗәле белгечләрдән көчле коллектив формалаштыра, бизнес-процессларны нәтиҗәле көйли, исәп-хисап тәртибе сыйфатын заманчалаштыра, клиентлар белән үзара мөнәсәбәтләрне җайлый һәм компаниянең технологик җиһазландыруын яхшырта алган.

Инновацияләргә һәм цифрлаштыруга йөз тоту үзенең нәтиҗәләрен бирә, аларны беренче чиратта компаниянең клиентлары сизә. Бүген «Татэнергосбыт» 100%ка дистанцион хезмәт күрсәтүгә әзер, 120 меңнән артык кулланучы түләү документларын электрон формада ала, һәм әлеге сан бик тиз арта бара. Йөзгә-йөз һәм читтән торып хезмәт күрсәтүнең барлык ысуллары республика халкының компания белән хезмәттәшлек итүен гадиләштерү һәм уңайлаштыруга юнәлтелгән.

Бүген «Татэнергосбыт» – Татарстан территориясен электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүче статусындагы тиз үсә торган компания ул, соңгы биш елда Россиянең электр энергиясе сатучы ышанычлы 100дән артык компаниясе арасында лидерлар өчлегенә керә. Ә «Татэнергосбыт» АҖ базасында бердәм республика исәп-хисап үзәген төзү Татарстан халкына хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яңа дәрәҗәгә күтәрде, шулай ук ресурслар белән тәэмин итүче һәм идарәче оешмалардан алып ахыр кулланучыга кадәр чылбырда үзара мөнәсәбәтләрнең тагын да ышанычлырак булуына китерде.

Үзенең 60 яшьлек юбилеена Рифнур Хәйдәр улы фикердәшләре иңенә таянып якынлаша, алар белән теләсә нинди авыр бурычларны да җиңеп чыгасына аның иманы камил. Яхшы башкарылган эш өчен горурлык хисе тоюны, коллектив, дуслар һәм гаиләсе ихтирамын казануны исә Рифнур Сөләйманов иң зур бүләккә саный.

«Бәхет – үткәннәрне канәгатьләнеп искә алу, бүгенге көнгә сөенү һәм киләчәккә оптимизм белән карау ул» – энергия бирү үзенең һөнәри бурычы булган кешенең төп тормыш кредосы менә шундый.

Фото «Татэнергосбыт» компаниясеннән алынды

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Паласны **ничек** тукыйлар

Агач йортлы Казан **кайда** сакланып калган

Китап киштәсендә **ниләр** бар

«Чаян»га **ничә** яшь

Татар Танаенда дамба **кайчан** төзеләчәк

PRESSA

КЕЛӘМ – ЗАТЛЫЛЫК БИЛГЕСЕ

Руфия Фазылова

«Татарстан» журналы көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрне барлауны дәвам итә. Бу юлы без Балтач районының Чутай авылына юл тоттык. Биредә танылган палас туку остасы Гөлзифа апа Нәҗипова яши. Танылган дим, чөнки Гөлзифа апа соңгы өч айда социаль челтәрләрдә йолдызга әйләнде. Үзе суккан паласларны халыкка күрсәтеп, күпме кайтавазлар ала.

Оста безгә дә бу шөгыль турында бик рәхәтләнеп сөйләде.

КАДЕРЛЕ БҮЛӘК

Гөлзифа Нәҗипова әлеге эшкә дүрт ай элек кенә алынган. Моңа кадәр палас сугып караганы булмаган. Киров өлкәсендә узган бер ярминкәдән аңа кызы белән кияве яңа туку машинасы алып кайта. Менә шуннан Гөлзифа апа палас туку серләре белән кызыксына башлый.

– Балалар станокны җәй алып кайтты, тик ул чакта кул эшләре белән утырырга җай булмады, – дип сөйләде Гөлзифа апа. – Җәен без күп итеп төрле үләннәр җыябыз, аны киптерәбез. Кыз белән кияү шуның белән шөгыльләнә. Аннары, бакча эшләре дә күп бит, малларга печәнен әзерлисең, йөзәр баш кош-корт. Кыскасы, җәен өйгә йокларга гына керәбез.

Фото: Илнар Өметбаев

Әнә шулай эштән бушагач, Гөлзифа апаның җәмәгате Рәис абый туку станогын җыеп бирә. Һәм хуҗабикә өйдә булган иске киемнәрдән тасмалар кисә дә кечкенә генә тастымал ясап карый.

– Менә ул тастымал, – дип күрсәтте Гөлзифа апа. – Тукымалар төрле булганга күрә, төсле килеп чыкты. Ләкин беренче эш өчен начар булды дип әйтә алмыйм.

– Ә сезнең моңа кадәр палас сукканыгыз бар идеме? – дим.

– Җиде-сигез яшьләремдә дәү әнигә чүпрәкләр ертып биргәнем истә. Ә болай яхшылап палас тукымадым кебек. Тик ул станок авыр, бик зур иде. Болар бит җайлы, җиңел.

– Алайса палас тукырга ничек өйрәндегез? – дим.

– Интернеттан карап. Хәзер бит бик рәхәт: онлайн дәресләр әллә никадәр. Барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп аңлаталар. Аннары, бер күргән эш булгач, барысы да искә төште. Әлбәттә, эшли-эшли остарасың. Минем дә шулайрак булды: беренче паласларның кайбер җирендә җепләре тоташкан урыннары күренеп тора. Хәзер инде андый ялгышлыклар җибәрмим. Тизлек тә артты. Бер паласны ике-өч көндә тукып чыгам. Элек бер атна вакыт кирәк иде. Балалар махсус җепләр сатып алып кайта, тукыманы кисеп тә эшлим. Мәш киләбез инде.

«НӘСЕЛДӘН КИЛӘ...»

Гөлзифа апа Зәйнәп әбисе суккан паласны әле дә кадерләп саклый. Алай гына да түгел, ул аны бүген дә көндәлек тормышта куллана. Иң гаҗәбе – җитмеш ел элек сугылган паласның сыйфаты һаман бер дигән! Юасың да, янә кулланасың!

– Без гаиләдә ике кыз үстек, – ди Гөлзифа апа. – Сеңлем Чепья авылы китапханәсендә эшли. Ул бик матур чигә. Кечкенәдән кул эшләрен яратып, белеп үстек. Кияүгә килгәндә, бирнәмдә чигелгән бик күп матур әйберләр бар иде. Аннары чикмәдем инде, колхоз эшендә булдым. Балалар үстердек. Менә лаеклы ялга чыккач кына кул эшләренә вакыт тиде.

Бирнә дигәннән, XX йөз башында яшь кәләшләр кияү йортына яңа палас алып килгән. Бирнәдә палас булу затлылык билгесе саналган. Шуның өчен дә үсмер кызлары булган әниләр ничек тә кызына бер матур палас сугу ягын караган.

– Хәтерлим, туку станогы авылда бер-ике генә иде, – диде Гөлзифа апа. – Аңа чират зур була, алдан әйтеп куеп алып кайтасың. Өйдәге караватны чыгарып торып, туку станогын кертәсең. Берәр атна басылып эшләгәч, станокны икенче кешегә илтәсең. Ә җепләрен алдан әзерләп куясың. Ул чагында әле аның чүпрәк-чапрагы да юк диярлек.

– Авылда туку станогы ясаучы бар идеме? – дим.

– Бар иде. Менә аның кемнәр икәне хәзер истә калмаган, без кечкенә идек бит әле. Аннары инде тормышлар яхшыра башлагач, палас туку бетте. Кибетләргә келәмнәр кайта башлады, мода керде.

Эшкә керешкәнче, станокта иң беренче киндер җепләрне сузасың. Бу эш өч-дүрт сәгать вакытны ала икән. Шуның өчен дә Гөлзифа апа җепне сузып куйган иде. Аннан исә сосага тукымадан ясалган җепне эләктереп, киндер җепләр аша чыгарды. Шуннан сузылган тукыма җепне кылыч белән бастырып, махсус тарак белән тыгызлап чыкты. Чынлап та, әллә ни катлаулы эш түгел икән. Кызлар да станок артына утырып, тукып карады. Бик мавыктыргыч шөгыль икән дигән нәтиҗәгә килдек.

Гөлзифа апаның бүтән кул эшләрен дә күреп таң калдык. Шәлләр дә бәйләгән, пәрдәләр дә чиккән ул. Соңгы елларда бисер, фоамиран, кәгазьне бөтереп төрле чәчәкләр, кәрҗиннәр ясаган. Өе тулы үзе ясаган кул эшләре. Кыскасы, булганнан бар да була.

– Көн саен төрле районнардан хәбәргә чыгалар, – диде оста. – Әллә кайлардан килеп киттеләр инде, палас туку серләре белән кызыксыналар. Барысына да бик теләп аңлатам, күрсәтәм. Аллаһы Тәгалә миңа шундый сәләт биргән икән, ни өчен әле аны башкалар белән дә бүлешмәскә?! Т

Элек-электән келәм-паласлар йон, ефәк һәм киҗе-мамык җептән, күн һәм ясалма материаллардан әзерләнгән. Паласлар төрле булган: тукылганы, чигелгәне, бәйләнгәне, киездән басылганы...
Келәмчелек — борынгы нәфис сәнгать төрләренең берсе. Аның үсешенә көнкүреш гореф-гадәтләре дә йогынты ясый.
Татарларда келәмчелек белән башлыча хатын-кызлар шөгыльләнгән. Ул йорт һөнәрчелегенең бер формасы булган. XIX йөзнең икенче яртысыннан XX йөз башына кадәр Казан губернасындагы татар авылларында тукылган келәмнәр, идән паласлары һәм утыргыч өчен мендәрләр әзерләү җәйгә салынган. Татар корама келәмнәре бизәкләрен әзерләү өчен тукыма кисәкләрен аппликация ысулы белән күпкатлы итеп тә текәннәр. Татар келәмчелегенең һәр төре гамәли һәм эстетик әһәмияткә ия булган. Бизәкле — «асалы» паласларны сәкедәге бертөсле киезләр өстенә япсалар, буйлы келәмнәрне идәнгә җәйгәннәр.
(Татарча онлайн энциклопедиядән кыскартып алынды)

Язманың видеоварианты да бар.

PRESSA

Акварельдә сакланган кала

Әскар Сабиров

Агач йортлы Казан. Узган гасырның 80 нче еллар азагы–90 нчы еллары башында шәһәрнең һәркайсы җәүһәргә тиң агач өйләренә урамы-урамы белән эзсез юкка чыгу куркынычы яный. Бу хәл архитектор Равил Айдаровны әлеге мирасыбызны үзенчә саклап калуга этәрә.

Равил Сәйяр улы Айдаров. РФ Архитекторлар берлеге әгъзасы, ТРның атказанган архитекторы, КДАТУ профессоры. 1973–1986 елларда – Казанның Вахитов районы баш архитекторы. «Казанский деревянный дом XIX – начала XX веков в акварели и графике», «Деревянные общественные здания Казани XIX–начала XX веков в акварели и графике», «Деревянная архитектура малых городов и сел Татарстана в акварели и графике. Актанышский и Муслюмовский районы», «Деревянная архитектура малых городов и сел Татарстана. Рыбно-Слободский и Сабинский районы» тарих-архитектура монографияләре авторы.

Фотолар: Равил Айдаровның шәхси архивы, tatar.inform

– Минә бу кызыклы бина – трамвай маршрутының диспетчерлык павильоны гына, югыйсә, – дип сүзен башлый Равил Сәйяр улы. – Әле күптән түгел генә ул Волков урамында тора иде. Карагыз әле, архитектурасы нинди үзенчәлекле аның: тар такта белән тышланган дивар, аттик һәм фронтоннар стильләштерелгән барокко элементлары белән ничек шәп яраша. Сүтеп ташладылар шуны. Ә бит бу Казанда агачтан салынган соңгы җәмәгать бинасы иде, башка юк...

Бәхеткә, җимереп ташлаганчы әлеге корылманы Айдаров мәңгеләштерергә өлгереп кала. Аның акварель рәсеме иң вак детальләргә кадәр – бөтенесен дә искиткеч төгәл саклаган, архитекторның ниндидер уйдырма сурәтләргә хакы юк бит. Әйе, безнең каршыда искиткеч оста башкарылган акварель генә түгел, бәлки, узып киткән чорның ышанычлы дәлиле булган чын документ та.

Акварель һәм детальләрдәге төгәллек

1980 нче елларда Равил Сәйяр улы Казанның Вахитов районы архитекторы була. Мөгаен, ул чакта бу районда агач йортлар ташларыннан күбрәк булгандыр. Свердлов (хәзерге Санкт-Петербург), Волков, Тихомирнов, Тельман, Ульяновлар... – бу урамнар тулысы белән диярлек агач йортлардан торган, кирпеч биналар берән-сәрән генә очраган. Гади йортлар арасында еш кына сырлап ясалган нәфис бизәк беркетелгән үзенчәлекле фасадлы чын архитектура җәүһәрләрен дә күрергә мөмкин булган. Әчке якта революциягә кадәрге байларның чынаяк кирпеч белән тышланган мичләре, имән паркет идәннәре һәм башка зиннәтлелек элементлары сакланып калган. Йортларның кайберләре XIX гасыр – XX гасыр башы агач төзелеш сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре булып саналырга лаеклы. Казанда гына түгел, бөтен Идел буенда да...

Шунлыктан әлеге гүзәллекнең искерүен һәм җимерелүен күзәтү аерата аянычлы була. Заманы да агач архитектура мирасын саклау өчен көрәшү файдасыз булган вакыт. «Алты йөз тарихи һәм мәдәни ядкәрнең елына бер дистәсен торгызуга гына акча бүленде, нигездә бу Кремль объектлары һәм берничә җәмәгать бинасы белән дини корылмалар була торган иде», – дип искә

Трамвай маршрутының диспетчер павильоны (хәзерге Волков ур.).

Тельман урамы. Кирпечтән салынган ярымподвал каты булган агач торак йорт.

ала соңрак шәһәрдәге һәйкәлләрне саклау идарәсенең ул чордагы башлыгы Фәридә Зәбирова.

Һәм нәкъ менә шул вакытта Айдаров эшкә керешә. Йортларны, ишегалларын, детальләрне, декор элементларын фотога төшерә. Әгәр сурәткә генә төшерсә, күп нәрсәгә өлгерә алмас иде: агач Казан искиткеч тизлектә җуела бара. Аннары инде шул фотоларга карап, акварель рәсемнәрен ясый: детальләр төгәллек таләп иткәндә, үз хәтереңә генә ышанырга ярамый.

ИСКЕРМИ ТОРГАН НАТУРА

Тельман урамындагы, вакытлар үтү белән искереп каралса да, зиннәтле нәфислеген җуймаган агач йортлар. Юкка чыккан урамнардан яңа йортларга күчерелгән казанлылар бирегә әле еш килеп йөриләр – гомерләре монда узган чорның һавасын булса да сулап калырга телиләр. Ничек кенә сакларга тырышсалар да, бу йортлар барыбер ишелә. Хәзер бу купшы йортлар Айдаров акварельләрендә генә сакланып калган. Менә алар, карап хозурланыгыз. Сергеевның табышлы йорты – төбәктә эклектика элементлары кергән классицизмның соңгы үрнәге. XIX гасырның икенче яртысына караган, терраса һәм эркерлары бизәкле шкатулканы хәтерләткән ике катлы йорт. XIX гасырның тагын бер йорты – бусының кирпечтән салынган ярымподвал каты булган.

Рәсемнәрне җентекләп карагыз әле: боларның барысы да чын. Пропорцияләр, фасад элементлары, хәтта тәрәзә йөзлекләрендәге бизәкләр – барысы да математик төгәллек белән сурәтләнгән. Шул ук вакытта Айдаров үзенә генә мәгълүм ниндидер ысуллар ярдәмендә рәсемнәренә шул заманнарның сулышын өрә алган – ул дәвердә әлеге йортлар искергән натура түгел, бәлки шәһәр урам-мәйданнарының төп бизәге булган бит.

ЮККА ЧЫККАН ТАНЫШ МАНЗАРА…

Бервакыт Равил Айдаровның агач Казанны сурәтләгән йөз акварелен сыйдырган «Казанский деревянный дом XIX – начала

XX века в акварели и графике» дигән альбомын актарганда, йөрәгемне ешрак тибәргә мәҗбүр иткән бер рәсемгә юлыктым. Күз алдына китерә аласызмы, үземнең тәрәзәмнән ике дистә ел буе күзәткән һәм берничек тә сакланып кала алмастай тоелган картина иде бу. Инде күптән әлеге тәрәзә дә, каршыдагы йорт та, хәтта урамның үзе дә юк бит...

Әмма «Свердлов урамы фрагменты» дигән акварельдә – башка бер генә бина белән дә бутап булмаслык нәкъ шул йорт иде. Мезонины өстендәге Эрмитаждагыдай үтә зиннәтле вазон шәһәрдә башка юк. Мондый мезонин да, беренче, таш кат аша узган арка да бердәнбер... Һәм болары да искиткеч төгәллек белән сурәтләнгән. XIX гасыр уртасында салынган бу истәлекле йорт урынында хәзер – метро станциясе...

Үзләренең юкка чыккан йортларын Айдаров акварельләрендә табучы казанлылар шактый – алда атап кителгән альбомда гына да алар йөзгә якын бит. Равил Сәйяр улы исә үз рәсемнәрендә барлыгы ике йөзгә якын агач йортны сурәтләргә өлгергән. Әлеге акварельләр куелган күргәзмәләргә һәрвакыт кеше күп килә. Халык рәсемнәрне озаклап карый, узып киткән чор детальләре – балкон, терраса, эркер, сырлы йөзлекләр, капкаларны күреп ләззәтләнә. Юкка чыккан Казан – сагыну-сагыш кына түгел, тарихыбызның тулы бер катламы да ул.

ТОРГЫЗУ ЗАРУР

– Әле XIX гасыр азагында да Казандагы биналарның җитмеш проценты агачтан булган, – дип сөйли Равил Айдаров. – Агач җәмәгать биналары, агач табышлы йортлар, шәһәр читләрендә ярлыларның агач өйләре – боларның барысы бергә каланың ул вакыттагы йөзен тәшкил иткән. Һәм, боларны юкка чыгарып, без тиңдәшсез шәһәр мохитеннән мәхрүм ителәбез.

Автор рәсемнәрендә сурәтләнгән йортларның һәркайсы турында яхшы белә. Стиль, конструкция үзенчәлекләре, үлчәме, төзү материаллары. Акварельләр – аның Казан альбомының бер өлеше генә. Биредә исә – моннан 100–150 еллар элек төзелгән биналарның архитектура проектлары, план-схемалары, төгәл пропорцияләре, эчке планы. Һәм һәр рәсем астында – тикшерелгән мәгълүмат: йорт кайсы чорда, нинди стильдә төзелгән, аеруча үзенчәлекле элементлары нинди...

Рәсемнәр – сәнгатьнең үре, аеруча күренеп торган өлеше. Иске йортларның проектларын, шәһәр төзелеше нормаларын һәм кагыйдәләрен өйрәнеп, архивларда никадәр вакыт үткәрүен Айдаров үзе генә белә. Өлкәннәр белән аралашып, агач биналарны сүткәнне күзәтеп, төзелешкә кагылышлы никадәр сер ача!

– Минем яхшы бер танышым, агач йортларның чарлакларында элек махсус тузан үстергәннәр, дип сөйли иде, – дип сүзен дәвам итә Айдаров көтелмәгән «табылдыкларының» берсе турында. – Яңгыр тамчысы, тузанга эләккәч, шуңа сеңә һәм аска агып төшми икән...

Хәзер исә аның бәһасез мәгълүматларыннан һәркем файдалана ала. Ә иң мөһиме – аларга ихтыяҗ зур икән.

Бәхеткә, бөтен агач биналар тузып юкка чыгарылган вакытлар инде артта калды. Киресенчә, без хәзер калган мирасны ничек тә сакларга, торгызырга тырышабыз. Һәм бу юнәлештә Айдаров туплаган мәгълүмат алтынга тиң. Бигрәк тә реставраторлар яки «Том Сойер Фест» хәрәкәте энтузиастлары моңа шат һәм рәхмәтле. Алар өчен Равил Сәйяр улының акварельләре еш кына теге яки бу йортның тышкы кыяфәтен ачыклауда бердәнбер мөмкинлек булып тора. Иске Татар бистәсендәге биналарны торгызганда әлеге акварельләрнең ничек булышуы хакында исә күп

Свердлов урамы (хәзерге Петербург ур.) фрагменты.

Тельман урамының сул ягы фрагменты.



1890 елгы Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсенә төп керү урыны. Күргәзмә Николай мәйданында урнашкан була.

Казан. Идел пристане. Сыра лавкасы.





сөйләп булыр иде, хәзер бу йортлар үзләренә туристларны магнит кебек тартып тора.

ЙӨЗ ЕЛ ЭЛЕКТӘГЕ КЕБЕК

Моннан ике ел элек Айдаровның тагын бер тиңсез альбомы дөнья күргән – «Деревянные общественные здания Казани XIX – начала XX века в акварели и графике». Анда Казанның агач җәмәгать биналары рәсемнәре. Бөтенләй юкка чыкканнары. Алдарак Равил Сәйяр улы сөйләп үткән Волков урамындагы тукталыш павильонын ул үзе дә, без дә күреп белсә һәм хәтерләсә, калганнарының бөтенесе диярлек күптән җуелган. Казанда 1909 елда үткән Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсенә атап төзелгән гаять зур агач павильоннар хакында бүген кем белә? Замандашларын мәһабәтлеге белән таң калдырган агач театр турында кем хәбәрдар? Ә Панаев бакчасындагы Панаев рестораны хакында белүче бармы? Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белсә генә.

– Һәм шундый данлыклы биналар Казанда берән-сәрән генә түгел, дистәләрчә булган, – дип сөйли Айдаров. – Алар сакланган очракта ачык һавада агач архитектура күргәзмәләре оештырып булыр иде.

Равил Айдаров күптән юкка чыккан корылмаларны акварельләрендә ни рәвешле сурәтли алган соң? Биредә дә архивлар, сакланып калган иске фотографияләр, хәтта революциягә кадәр чыккан открыткалар булышкан.

– Рәсемнәрендә абсолют төгәллеккә ирешү өчен, ул фотографияләрне кулына лупа тотып өйрәнде, – дип, рәссамның иҗат лабораториясе серләрен бераз ача безгә архитектура докторы, Равил Сәйяр улының хезмәттәше һәм хәләл җефете Галина Айдарова-Волкова. – Сурәтләрне чагыштыра, исәпли, төсләрен сайлый...

Казанның Иделнең иске үзәнендәге агач пристаньнары, Дары бистәсендәге агач мәчет яки «Рус Швейцариясе»ндәге ачык эстрада. Әлеге корылмаларны Айдаров акварельләрендә беренче тапкыр күрсәгез, бер дә шикләнмәгез: моннан йөз ел элек алар нәкъ шундый булган.

Швециядәге «Скансен» кебекме? Шәбрәк!

Айдаров акварельләре – борынгы шәһәр рәсемнәре ул. Аларга карагач, башта үзеннән-үзе әллә нинди зур планнар туа. Шулардан берсе – агач Казанның бер өлешен торгызу. Аерым йортларны гына түгел – тулы бер тарихи мохитне. Җәмәгать биналары, бай табышлы йортлары һәм гадирәк йортлары, сәүдә мәйданы һәм хәтта театры белән.

Ихтимал, бу бүген бөтенләй юкка чыккан Тельман урамы сыман бер урам яки берничә урам булыр... Моның өчен сакланып калган раритетларның барысын бер җиргә тупларга, кайбер корылмаларны исә иске сызым һәм документлар буенча яңадан төзергә кирәк. Булмаслык хәлме бу? Бүген – әйе, утопия генә. Әмма әле егерме ел элек кенә безгә берәр агач йортны реставрацияләү утопия булып тоела иде түгелме. Хәзер исә дөньяда тарихи мохитне торгызу һәм аны туристлар өчен Мәккәгә әйләндерүнең җитди тәҗрибәсе тупланган – шведларның атаклы «Скансен»нары гына да ни тора.

Иманым камил, кайчан да булса без моны һичшиксез тормышка ашырачакбыз. Һәм шул чакта Равил Айдаров акварельләре үзләренең төп миссиясен тулысынча үтәр – безгә җуелган мирасны кире кайтарырга булышыр иде.

Панаев бакчасында Панаев рестораны («Динамо» стадионы территориясе).



Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы, элекке «Рус Швейцариясе». Җәйге театр.

«Казан» гаилә үзәге,
Казан

«АКЛЫ-КАРАЛЫ ТАТАРСТАН» КҮРГӘЗМӘСЕ

Андрей Артисның «Аклы-каралы Татарстан» дип аталган беренче шәхси күргәзмәсе шушы көннәрдә Санкт-Петербургта, «Точка» архитектура фотогалереясында уза.

«Аклы-каралы Татарстан» - Татарстанның истәлекле урыннарына багышланган фотосурәтләр сериясе. Күргәзмәдәге кадрларда Казанда һәм республиканың Иннополис, Болгар шәһәрләре, Алабуга, Биектау, Лаеш районнары кебек җирлекләрендәге күркәм архитектура үрнәкләре чагылыш тапкан… Андрей Артис архитектурага монохром фильтр аша карарга тәкъдим итә. Мондый алым төс акцентларын булдырмаска һәм беренче чиратта бина фасадларының силуэтына, формасына һәм пластикасына игътибар итәргә мөмкинлек бирә. Аклы-каралы «портретлар»да яктылык һәм күләгә архитектураның байлыгын һәм төрлелеген күрсәтүче үтемле чара буларак кулланыла.

Андрей Артис Татарстан Республикасы Фотографлар берлеге һәм Россия Фоторәссамнары берлеге әгъзасы, бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты. Аның «Аклы-каралы Казан» фотосурәтләре сериясе MonoVisions Photography Awards 2021 халыкара конкурсының «Архитектура» категориясендә бронза медальгә лаек булган.

Балконнар, Казан, Татарстан, Россия, 2020.

PRESSA

Төнге Казан шәһәре.

PRESSA

Татарстан Республикасы Милли музее, Казан.

Европа торак комплексы, Казан.

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ РӘХМӘТЛЕМЕН!

Руфия Фазылова

Иске Чәчкабка көннең икенче яртысында гына барып чыктык, чөнки Кайбыч районында бүтән эшләребез бар иде. Бу якларга сәфәр кылгач, 102 яшен тутырган сугыш ветераны Зиннәтулла Заһидуллин белән танышмасак, зур хата булыр дип уйлаштык. «Сәгать бергә киләбез дип әйттегез, ник һаман юк?» – дип, бабайның туганы, күршесе Фәридә апа ике тапкыр шалтыратты. Гомер буе җаваплы хезмәттә булган, һәрвакыт әйткән сүзендә торган Зиннәтулла бабай өчен бер сәгатькә соңга калу гаҗәп хәл шул...

ДӨНЬЯ БИТ УЛ ТҮГӘРӘК...

Бабай белән исәнләшергә дип кул сузам... Ул елмаеп җилкәдән үк сөеп ала.

– Кайсы яктан син?

– Әнием Кайбыч районыннан, – дим.

– Кайсы авылдан, җәле?

Озын сүзнең кыскасы, Зиннәтулла бабай әнинең этисен яхшы белә булып чыкты. Хәтта бергә эшләгәннәр, дөньяның түгәрәклеге...

– Бабаң Гата белән дуслар булдык. Бик туры сүзле иде, шуңа атып та үтерделәр аны. Япь-яшь килеш җир куенына кереп ятты мәрхүмкәй. 1954 елда җирләнде бит ул?..

Зиннәтулла бабай белән бер мизгел эчендә әнә шулай «туганлаштык». «Кара әле, Гата кызы бит!» – диеп, әллә ничә тапкыр кочаклап алды. Миңа, гомеремдә бер тапкыр дәү этисен

Фото: Александр Ефремов

күрмәгән кыз бала өчен, Зиннәтулла бабай бигрәк тә газиз тоелды: Гата бабам чалымнарын таптым...

Зиннәтулла бабай лаеклы тормыш юлы үткән. Ир-ат эшләргә тиеш барлык бурычларны да үтәгән, Бөек Ватан сугышыннан исән-сау кайткан кеше. Аңлашыла ки, 102 ел дөньялыкта яшәп, бабакай нинди генә хәлләр кичермәгән, фаҗигаләр, югалтулары да шактый булган. Шуның өчен дә Зиннәтулла бабай сөйләгәннәрдән аеруча күңелгә тигән вакыйгаларны теркәп бардым. Ә ул күп белә, барысын да хәтерли!

КАЗАН КАЙМАСЫН КАЗУ

Зиннәтулла Заһидуллин Иске Чәчкабта туа. Җиде классны туган авылында укый. Шуннан үсмер малай Казан мехчылар техникумына укырга керә. 1940 елда уку йортын тәмамлап, туган авылына кайта. Колхозда эшли башлый. Сугыш башлангач та, аны авыл советы рәисе итеп куялар. Бу вакытта егеткә 21 яшь була. 1941 елның көзендә СССР Дәүләт оборона комитеты әмере буенча дошман танкларыннан саклану өчен тиз арада окоплар казырга карар кылалар.

– Окоплар казырга әмер чыккач та, беренчеләрдән булып штабны безнең Иске Чәчкаб мәктәбендә оештырдылар, – дип хәтерен яңартты Зиннәтулла бабай. – Авылга Казаннан, бүтән ерак районнардан көн дә фәлән кадәр халык агылды. Кайчакта икешәр йөз кеше килә иде. Мин аларның һәркайсын фатирга урнаштырып йөрдем. Һәр өйдә күпме кеше яшәвен санап, капкаларына саннар язып чыктым.

– Ә авылдашларыгыз шулай әллә ничә чит кешене өйләренә кертергә ризалык бирделәрме? – дим.

– И, кызым, кем алардан сорап торган. Каршы килергә дә куркыныч бит, әмер бирелде – бетте-китте. Окоп казучыларны клубка, китапханәгә дә кертеп тутырдык. Күбесен күрше авылларга да озатып, таратып йөрдек. Килүчеләр арасында исемнәре телгә кергән кешеләр дә бар иде – Гадел Кутуй, Гомәр Бәширов, тагын ике язучы барлыгы истә калган. Ләкин аларның хәзер исемнәрен әйтә алмыйм. Мин ул язучыларны фәкыйрь генә йортка урнаштырдым. Сукыр лампа кертеп бирдем. Менә шунда Гадел Кутуй «Сукыр лампа» исемле шигырен язган. Окоп казучылар өчен пекарня ачылды, эш кораллары кайтардылар, табиблар китерелде, авырып китүчеләрне кире өйләренә озаттык, – дип сөйләде бабай.

Сугыш чоры балаларыннан күп тапкырлар ишеткән бар – кичен халыкка ут яндырырга ярамаган. Дошман авыллар барлыгын белмәсен өчен эшләнгән ул. Иске Чәчкабта да шулай төнлә кизү торганнар. «Уты булган кешеләргә кереп кисәтү ясый идек», – диде Зиннәтулла бабай.

«ХУШЫГЫЗ, ТУГАННАР...»

Тарихтан беләбез: Казан каймасын төзү, төзелеш эшләре, планда каралганча, тулысынча үтәлә. Һәм 1942 елның мартында окоп казучыларны кире өйләренә озаталар.

Авылда тормыш үз көенә барган бер мәлдә, Зиннәтулла Заһидуллинны военкоматка чакыртып, сугышка повестка бирәләр. Һәм яшь егет 1942 елның октябрендә туган авылыннан чыгып китә.

– Безне башта Казанда, махсус курсларда укыттылар, медбрат эшенә өйрәттеләр, – диде Зиннәтулла бабай. – 1943 елның гыйнвар аенда Мәскәүгә җибәрделәр. Шуннан исә төрле җирләргә тараттылар. Безнең төркемне Ржев шәһәренә алып киттеләр. Без килгән вакытта шәһәр җимерелеп беткән иде. Комлы карны казып окоп ясадык та, шунда урнаштык. Өч көннән соң гына тамакка ризык каптык. Бер атнадан соң безне йөк машиналарына төяп Елецк шәһәренә алып киттеләр. 371 нче дивизия, 1243 нче полкның икенче минбатальонында идем.

Бөек Ватан сугышы тарихында хәлиткеч вакыйгалар бар, шуларның берсе – Курск дугасы сугышы. 1943 елның 5 июлендә башланган махсус операция 23 августка кадәр дәвам итә. Максат: башта дошманнан Курск шәһәрен саклап калу, аннан Орел шәһәрен коткару, шуннан соң Белгород белән Харьковны немецлардан азат итү... Совет армиясенең бик зур җиңүе була ул. Дөнья тарихында иң зур танк сугышы びуларак та билгеле.

Зиннәтулла бабай нәкъ менә шунда эләгә.

– Бишенче июльдән башлап немецлар иртәнге сәгать өчтән кичке сәгать сигезгә кадәр Белгород белән Харьков арасын бер-

туктаусыз утка тотты, – диде йөзьяшәр бабай. – Шәһәрләрне тоташтырырга мөмкинлек юк иде. 12 июльдә безнең эшелон контрһөҗүмгә күчте. Нәтиҗәдә, немецлар чигенергә мәҗбүр булды. Харьковны туктаусыз җиде сәгать бомбага тоту вакытында янәшәмдә генә күпме солдат һәлак булды. Һич онытмыйм: карасам, снарядлар миңа таба очып килә. «Гомерем булса, исән калам», – дидем дә, минометны калдырып, икенче якка сикердем. Һәм санаулы секундлардан нәкъ минем миномет өстенә бомба төшеп шартлады...

МОГҖИЗА!

Зиннәтулла бабайның шул вакытта сул кулы һәм уң як кабыргасы каты җәрәхәтләнә. Аның кебек дистәләгән яраланучыны Харьков госпиталенә салалар. Аз гына тернәкләнгәч, аларны Мәскәүгә озаталар. Ләкин поездда Зиннәтулланың температурасы күтәрелә, аяклары йөрмәс була. Нәтиҗәдә, яшь солдатны командир приказы белән Воронеж өлкәсенең Хреновая станциясендә дәваланырга калдыралар.

– 1943 елның 20 декабрендә Уфага кайтардылар, – диде Зиннәтулла бабай. – Әле йөри алмый идем. Мине караучы табиб якташым булып чыкты, ул нервларга салкын тиюен, шуның аркасында йөри алмавымны әйтте. Туган якка кайту теләге бик зур булганга, башта бик озаклап карават кырыена тотынып басып тора башладым. Аннары таяклар ярдәмендә йөрергә тырыштым. Рәхмәт яугыры, госпиталь хезмәткәрләре бик ярдәм итте. Яңадан йөрергә өйрәнү гаҗәп авыр икән ул...

Могҗиза белән исән калган солдатны 1944 елның гыйнварында вакытлыча хәрби хезмәттән азат итәләр һәм алты айга туган ягына озаталар. Таяк белән туган нигезенә кайткан Зиннәтулла алты ай эчендә, йөгереп булмаса да, нык итеп аягында йөри башлый. Сөйләшенгәнчә, алты айдан хәрби комиссариатка бара. Усанов фамилияле хирург, солдатның яралары төзәлеп бетмәгәнен күреп, ялын янә бер айга озынайта. «Үзебез чакыру җибәрербез», – диләр.

– Бер айдан, ике айдан да сугышка чакыру килмәде, – ди бабакай. – Мин инде моның өчен борчылып та йөрдем, ләкин үзем хәрби комиссариатка барырга җөрьәт итмәдем. Сугышның ни икәнен беләм бит... Аллаһы Тәгалә кушып, сугыш бетте, дигән хәбәр килде. Инде мин документларны тәртипкә китерергә дип, район комиссары янына киттем. Башта мине сүгә башлады бу, янәсе, качып йөргәнмен. «Азагын уйладыңмы?» – ди. Документларымны эзлиләр, юк. Бөтен хәрби комиссариатны аякка бастыргач кына табылды – мине караган хирург Усановның эш шкафында яткан икән алар!

Могҗиза, тәкъдир дияргәме моны?! Әгәр табиб шул вакытта яралы солдатның документларын онытмаган булса, Зиннәтулла янә фронтка китәсе булган бит. Ә анда кем белгән...

«ҮЗ ӨЕМДӘ РӘХӘТ»

Зиннәтулла бабай бүген ялгызы яши. Хәер, алай дип әйтү бик үк дөрес тә булмас – күршедә генә караучысы, туганы Фәридә апа бар. Көненә әллә ничә тапкыр кереп бабайның хәлен белә, ризыгын пешерә. Җәмәгате Асия апа вафат булганга унсигез елдан артып киткән. Ир белән хатын биш бала тәрбияләп үстергән. Ни кызганыч, бабакайның ике улы да мәрхүм инде.

– Шәһәрдә, балалары янында да яшәп карады, – диде Фәридә апа. – Икенче кышны менә үз өендә чыкты. Шәһәрдә яшисе килми аның. Балалары да чакыра үзен, юк бит, гомер иткән йорты кадерле.

– Мин анда картаям, – дип көлде Зиннәтулла бабай. – Әле аякта йөреп торам, кызым кебек Фәридә бар. Хәлемне белергә район администрациясеннән дә гел килеп торалар, балалар кайтып йөри. Шәһәрегездә бер генә дә рәхәт түгел. Бөтен кеше телефонга текәлгән. Берберсе белән аралашмыйлар. Авылда ичмаса бөтенесе сине белә, хәлеңне сораштыра.

Алда әйткәнемчә, Зиннәтулла бабай җаваплы урыннарда – районның финанс бүлегендә эшләгән, аннан күп еллар военкоматта хезмәт куйган. Лаеклы ялга чыккач исә, дин юлына баскан – дистә еллар дәвамында мәчеттә мулла вазыйфасын башкарган. Нәселләрендә болай озын гомерле кеше юк икән. «Аллаһ шулай озын, матур гомер биргән миңа, шуның өчен мин Аңа бик рәхмәтлемен», – ди бабакай.

Зиннәтулла бабайны районда «Кайбыч Әлмәндәре» дип йөртәләр. Чынлап та, Туфан Миңнуллин герое кебек җор телле, сөйкемле ул. Картлык чибәрлеген дә, зиһенен дә алмаган. Аның тормышы, үткәне белән танышканнан соң, бер уй туды: фәрештәләр саклап, көч биреп торадыр аңа. Башкача мөмкин түгел... Т

1941 елның көзендә немецлар зур көч белән Мәскәүгә таба хәрәкәт итә. Фашистларны Казанга, Идел елгасына якын җибәрмәү максатыннан, 13 октябрьдә СССР Дәүләт оборона комитеты дошман танкларыннан саклану өчен тиз арада окоплар казырга карар кыла. Казанда махсус Саклану комитеты төзелә. Аңа Казанны ярымбоҗра белән әйләндереп алу, окоплар казу, саклану чаралары күрү бурычы куела.
Идел аръягында окоп казуда республикабызның 28 районыннан, Казан шәһәренең югары һәм махсус урта уку йортларыннан берничә йөз мең кеше катнаша. Нәтиҗәдә, танкларга каршы тору өчен 331 чакрым озынлыкта окоп казыла, 392 күзәтү пункты, 98 ешерен ут ноктасы, 56 еракка ату зенит ноктасы, 419 землянка корыла.
Окоп казуда Тәтеш, Кама Тамагы, Апас, Буа, Кайбыч районнары халкы аеруча күп катнаша. Эшләүчеләргә көненә 600 грамм икмәк, аш пешерерлек он, ярма бирелә. Окопчыларның 70–75 проценты хатын-кызлар була.

ДӨРЕСЛЕК ТАРАФДАРЫ ГАЛИМҖАН ШӘРӘФ

Илдус Заһидуллин

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы фондында күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Шәрәфетдин улы Шәрәфнең берничә васыятьнамәсе саклана. Шуларның 1948 елда язылганында иллеләп фәнни хезмәт, байтак шигырьләр авторы үзенең кабер ташына гарәп хәрефләре белән түбәндәге сүзләрне уярга васыять итә: «Татарстан җөмһүрияте проектын башлап төзүче, тел галиме, профессор, шагыйрь Галимҗан Шәрәф».

ШӘКЕРТЛЕК ҺӘМ СТУДЕНТ ЕЛЛАРЫ

Галимҗан Шәрәф 1896 елның 29 декабрендә Казан губернасы Тәтеш өязе Кыр Аксуы авылында таза тормышлы игенче Шәрәфетдин һәм Гайнелнәвал гаиләсендә төпчек малай булып дөньяга килә.

Туган авылы мәктәбен тәмамлагач, ир туганнары укыган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә китә. Яшүсмер чагында ук абыйларына нәширлек эшендә булыша. Шул исәптән Габдулла Тукайның 1912 елда дөнья күргән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле хрестоматиясен бастыруга хәзерләүне үз җаваплылыгына ала, шагыйрь белән якыннан аралаша. Бу хезмәттәшлек аның хәтеренә якты хатирә булып кереп кала.

Галимҗанның бөек татар шагыйренә ихтирамы 1912 елда «Мөхәммәдия»нең икенче баскычын тәмамлап, Казанның 2 нче реаль училищесына укырга кергәч, укытучысы Павел Радимов белән бергә Тукай шигырьләрен русчага тәрҗемә итеп бастыруда катнашуында да ачык чагыла. Ул шулай ук 1913 елда шагыйрьнең канатлы сүзләрен – афоризмнарын туплап җыентык бастыра. «Тукай сүзләре» җыентыгы 1914, 1916, 1920 елларда кабат дөнья күрә.

1915 елда Галимҗан Санкт-Петербург элемтә юллары инженерлары институтына укырга керә. Актив студент тормышы Галимҗанның шәхес булып үсешендә мөһим роль уйный. Институтка дәрескә йөрүдән тыш, башкала университетының Шәрык телләре факультетына ирекле тыңлаучы булып урнаша. Күренекле галимнәрнең лекцияләрен тыңлый, семинарларда катнаша. Шулай ук Самойлович җитәкчелегендә борынгы төрки язмаларны өйрәнә. Башкала китапханәләрендә көнчыгыш һәм көнбатыш телләрендәге китапларны укып, «Чыңгызхан дәверендә татар һәм башка төрки халыкларның тарихы» исемле хезмәт язарга алына. Кызганыч, 300 битлек кульъязма хезмәт тәмамланмый кала.

Шәрәф 1919 елда, үзе русчага тәрҗемә иткән Тукай шигырьләрен туплап, «Разбитая надежда» исемендә китап бастыра.

Актив иҗтимагый эшчәнлек алып барып, «Татар учагы» исемле укучы яшьләр оешмасы төзи. Оешмага Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Солтанбәк Мәмлиев, Кәрим Сәгыйтов, Габдулла һәм Гани Абызовлар керә. Яшьләр утырышларда татар тарихы, мөселман халыкларының мәдәнияте, хәзерге иҗтимагый тормыш турында фикер алыша. Чынлыкта «Татар учагы»ның эшчәнлеге күпкә киңрәк була. Ул башка шәһәрләрдә укучы татар яшьләре һәм аларның оешмалары белән элемтәләр урнаштыра.

Фотолар автордан алынды

Галимҗан Шәрәф остазы Василий Богородицкий белән.

МИЛЛИ ҖӨМҺҮРИЯТ ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

Галимҗан Шәрәф «Татар учагы» оешмасының вәкиле сыйфатында 1917 елның 1–11 май көннәрендә Мәскәүдә узган Бөтенроссия мөселманнарының I съездында катнаша. «Туфраклы мөхтәрият» төзүне яклап доклад сөйли.

Илдә революция башлангач, Казанга кайта.

1917 елның 22 июлендә Казанда үткән Бөтенроссия мөселманнарының II съезды эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясен игълан итә. Галимҗан Шәрәф «туфраклы мөхтәрият» яклы булса да, милли-мәдәни мөхтәрият оештыру комиссиясенә сайлана.

1917 елның 22 ноябрендә Садри Максуди рәислегендә Уфада Милләт мәҗлесе ачыла. Аның 29 ноябрендәге утырышында Шәрәф тәкъдиме белән «Идел-Урал штаты» дип аталган «төрки-татар» милләте җөмһүриятен төзү турында карар кабул итә. Галимҗан Шәрәф рәислегендәге комиссия Идел-Урал штаты өч кагыйдә буенча төзелергә тиеш дип билгели: 1) төрки-татарлар күпчелекне тәшкил итәргә; 2) гомум, бүленмәгән территорияне биләргә 3) икътисады һәм мәдәнияте бердәм булырга. Нәтиҗәдә Идел-Урал штатына тулысы белән Казан һәм Уфа губерналары, шулай ук Оренбург губернасының көнбатыш өлеше, Пермь, Вятка, Сембер, Самара губерналарының мөселманнар яши торган өлешләре кертелә. Галимҗан Шәрәф булачак җөмһүриятнең чикләрен билгели, аларны картага төшерә. Тәкъдимнәр Милләт мәҗлесе тарафыннан раслана.

Милләт мәҗлесенең 1918 елның 7-8 гыйнвар карары белән җөмһүриятне төзү эше Казанда оешырга тиешле Идел-Урал штатын гамәлгә кертү комиссиясенә тапшырыла. Галимҗан Шәрәф комиссия рәисе урынбасары була. Шәрәфкә Идел-Урал штатының картасын эшләү йөкләнә. Бу эш күп көч сорый: төрки-татарлар таралып яшәгәнлектән, җөмһүрияткә аларны күбрәк итеп кертеп, күпчелеккә ирешү өчен урыннарда этник состав һәм яшәүчеләр санын исәпкә алырга туры килә.

Комиссиянең Казан эшче, солдат һәм крестьян Советы белән Штат оештыру турында сөйләшүләре уңышсыз була. Бер үк вакытта Хәрби шура рәисе вазифасын башкарган Ильяс Алкин 1 март көнне Казанда эшләүче II Бөтенроссия мөселман хәрби съезды оештырган митингта РСФСР составында Идел-Урал штаты турында резолюциянең тантаналы рәвештә игълан ителәчәген хәбәр итә. Документ текстын алар икәү яза.

Моңа каршы Казан Советы 26 февральдә Казан Совет Эшче-Крестьян республикасын оештыра, шәһәрдә хәрби хәл игълан итә. Большевиклар 27 февральдән 28 февральгә каршы төндә съезд җитәкчеләрен кулга ала. Съезд делегатлары Болак артында, Татар бистәләрендә Идел-Урал штатын игълан итә. Март азагында Татар бистәләрендә урнашкан милли гаскәрләр тар-мар ителә. Бу шартларда Галимҗан Шәрәф большевиклар ягында милләтчеләр белән килешү һәм кан коймау турында сөйләшүләр алып бара.

Идел-Урал штатына каршы Совет дәүләте шул ук чикләрдә Татар-Башкорт совет республикасын төзү инициативасы белән чыга. Милли эшләр буенча халык комиссариаты рәисе Иосиф Сталин Шәрәфне Мәскәүгә аның чикләрен ачыклау һәм нигезләмәсен төзү өчен чакыртып ала. 1918 елның апрель-май айларында Шәрәф Эчке Россия мөселманнары эшләре буенча комиссариатта консультант булып тора. 1919-1920 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә картограф-статист булып эшли. Картасы һәм нигезләмәсе әзерләнсә дә, Милли эшләр буенча халык комиссариаты 1918 елның 22 мартында Татар-Башкорт совет республикасы оештыру турында бер ел элек кабул иткән декретын юкка чыгара.

ТАТАРСТАН ҖӨМҺҮРИЯТЕ ХӨКҮМӘТЕНӘ ЯРДӘМЕ

Галимҗан Шәрәф карталарны этнографик статистика өйрәтмәләренә таянып әзерли, бу өлкәдә зур уңышларга ирешә. Булачак Автоном Татарстан Совет Социалистик Республикасы нигезләмәсен һәм аның чикләре проектын эшләүдә актив катнаша. Бу уңайдан, хәзерге Татарстан Республикасы Галимҗан Шәрәф төгәлләштергән чикләрдә яши, дип әйтү урынлы булыр.

Галимнең киң эрудициясе, энциклопедик белеме, киң колачлы фикерләү сәләте Татарстан җөмһүриятенә күп генә реформалар үткәрүдә мөһим фәнни терәк була.

1920–1924 елларда Галимҗан Шәрәф ТАССР Мәгариф комиссариатының Фәнни секторында Шәрыкны өйрәнү бүлеген җитәкли, шулай ук 1920–1924 елларда АТССРның Эчке эшләр халык комиссариаты каршында, 1924-1927 елларда АТССРның Үзәк башкарма комитеты каршында Административ бүлемлекләр буенча комиссиядә эксперт-консультант булып хезмәт куя. Бу елларда ул республика халыкларының этник составын өйрәнә, җөмһүриятнең беренче административ һәм этнографик карталары эшли.

1923 елны Шәрәф әзерләгән Татарстан җөмһүрияте турында картограммалар, диаграммалар Бөтенроссия авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең дипломы белән бүләкләнә.

1924-1927 елларда ул ТАССР Дәүләт планлаштыру идарәсенең икътисади статистика бүлеге әгъзасы булып тора, ә 1925 елны СССР Фәннәр

академиясе каршында ил халкының һәм күрше дәүләтләрдә яшәүчеләрнең этник составын өйрәнү комиссиясенә мөхбир-әгъза итеп сайлана.

Шул рәвешле, 1920 нче елларда – кантоннарга бүлү, волостьларны эреләндерү, 1927–1930 нчы елларда кантоннарны районнар итеп үзгәртү эшләре, моңа бәйле ТАССРның административ карталарын төзү 1933 елгача турыдан-туры Галимҗан Шәрәф катнашында башкарыла.

ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ ГАЛИМЕ

Галимҗан Шәрәфнең фәнни уңышлары тел гыйлеме өлкәсенә карый. 1918–1919 елларда Мөселман эшләре буенча үзәк комиссариатның фәнни коллегиясендә эшләгәндә татар орфографиясен реформалау өлкәсендә эзләнүләр алып бара, соңрак бу фәнни юнәлешне Казанда дәвам итә. Ул тәкъдим иткән язу кагыйдәләре, бердәм татар орфографиясе буларак Яңалифкә күчкәнче, татар вакытлы матбугатында, милли мәктәпләрдә кулланыла.

1918–1921 елларда Шәрәф Казан университетының тарих-филология факультетында укый, профессор Василий Богородицкий җитәкчелегендә экспериментал фонетика кабинетында татар теленең аваз составы өйрәнә.

Галим 1921–1923 елларда Татар шрифтын реформалаштыру өчлегенең гыйльми сәркатибе буларак теоретик эзләнүләр алып бара, шулай ук татар телендә фәнни терминология эшләүдә катнаша.

1924 елда аның һәм Павел Радимов фәнни мөхәррирлегендә Мәскәүдә Җамал Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» исемле хезмәте, татар әдипләренең русчага тәрҗемә ителгән сайланма әсәрләре дөнья күрә.

Галимҗан Шәрәф 1926 елда Бакуда үткән I Бөтенсоюз тюркология съездында катнаша һәм чыгыш ясый. Докладында гарәп шрифтына өстенлек бирә, шрифт алышынса, элекке мәдәни мирастан аерылачакбыз, дип белдерә. Фикер алышуларда латин шрифтына кучүгә караганда, гарәп шрифты белән язу кагыйдәләрен камилләштерүне өстенлекле күрүен әйтә. II Тюркология корылтаенда төрки халыклар өчен бертөрле гарәп шрифтын эшләү мәсьәләсен тикшерергә тәкъдим итә. Аның тәкъдиме кабул ителми. Бу вакытта республика җитәкчелеге дә шушы позициядә тора, шул сәбәпле Шәрәфкә карата чаралар күрелми.

1927 елны ВКП (б) өлкә комитеты, карашын үзгәртеп, Яңалифкә күчүне 3 май көнне күтәреп чыга. Галим, протест йөзеннән, 17 май көнне Сталинга хат юллый. Хаты белән бергә, «Төрки халыкларның латин шрифтын кабул итү мәсьәләсенә карата» исемле мәкаләсен дә теркәп җибәрә.

1922–1937 елларда Шәрәф Шәрык педагогика институтында тел белеме һәм татар теле буенча курслар укый, республика мәгариф системасы өчен югары белемле кадрлар әзерләүгә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Институтта эксперименталь фонетика лабораториясенә җитәкчелек итә. Тиз арада доцент гыйльми дәрәҗәсен ала. Галим фәнни даирәдә танылa. 1926 елда дәрәҗәле СССР төбәкчелек белеме Үзәк бюросының мөхбир-әгъзасы һәм 1929 елда Вена каласында Халыкара эксперименталь фонетика ассоциациясенең хокукый әгъзасы итеп сайлана.

Татар сүзләрен язу кагыйдәләре хакында бәхәстә катнашып, Шәрәф остазы Богородицкий белән барлык 10 сузык аваз да хәреф белән бирелергә тиеш дигән фикер яклы була. Беренче булып татар телендә катылык-йомшаклык күренеше җәһәтеннән сузыкларны гына түгел, тартыкларны да чагыштыру кирәклеген әйтә, төрки телләрдә сингармонизм законының яңа сыйфатламасын ача, бу телләрдә тартыклар «гармониясе» барлыгын дәлилли. Шулай ук беренчеләрдән булып төрки-татар фонетикасы мәсьәләләрен морфологиягә бәйләп тикшерә башлый.

1934–1935 елларда профессор Василий Богородицкий, академик Александр Самойлович Шәрәфне, күренекле совет лингвисты, татар тел белеме буенча зур белгеч дип бәяләп, галимгә профессор дәрәҗәсен бирү мәсьәләсен күтәрәләр. Тик Мәскәүдән җавап килми. Сәбәбе – сәяси момент була.

ТОРМЫШЫНЫҢ СОҢГЫ ЕЛЛАРЫ

1937 елның мартында Галимҗан Шәрәф кулга алына. Мөстәкыйль буржуаз демократик төрки-татар дәүләте – Идел-Урал штатын төзүдә гаепләнеп, 27 февральдә 8 елга лагерьга җибәрүгә хөкем ителә. 1945 елның 23 мартында Төньяк тимер юл төзәтү-хезмәт лагереннан инвалидлык буенча иреккә чыгарыла. Аңа хатыны Әсма, гаиләсе янына Казанга кайту тыела. Шиһабетдин абыйсының кызы янына Апас авылына кайтып урнаша, эштән куылганчы, татар теле укытучысы булып эшли.

Шәрәф, гаделлек эзләп, гаиләсе янына Казанга кайтару һәм суд карарын юкка чыгаруны сорап – ТАССР прокурорына, ярдәм сорап, СССР ФАнең Казан филиалында эшләүче коллегаларына – телче галимнәргә мөрәҗәгать итеп карый. Ахыр чиктә хакимият гаделлек эзләүчене Казанга китереп, республика психбольницасына ябып куя.

Галимҗан Шәрәф 1950 елның 13 гыйнварында 53 яшендә вафат була.

Галимнең намуслы исеме җәмгыятькә 1958 елда кайтарыла.

Галимҗан Шәрәф хатыны Әсма белән. 1936 ел.

PRESSA



ХӘТЕР БОҖРАЛАРЫ, ЯКИ ҮЗЕБЕЗГӘ КАЙТУ ТРАЕКТОРИЯСЕ

Луиза Янсуар

Хәтер темасына мөрәҗәгать итмәгән язучы юктыр ул. Кайсы гына чорда, гасырда, системада һәм координаталарда яшәсә дә. Рус теленә тәрҗемәдә дөнья күргән ике үзенчәлекле романга игътибар итеп узасы килә. Икесендә дә вакыйгалар дөньядан аерып алынган утрауда, йомык пространствода бара. Икесендә дә кешенең эчке дөньяларына сәяхәте белән очрашабыз. Һәм аларда күтәрелгән темаларның яшәешебезгә бик тә аваздаш булуын аңлыйбыз.

Рәсемнәр: labirint.ru, snob.ru



СИСКӘНЕРГӘМЕ, ЮКМЫ?

Ёко Огава, «Полиция памяти»
«Поляндрия» нәшрияты, 2020
Тәрҗемәче: Дмитрий Коваленин

Роман япон телендә беренче тапкыр 1994 елда басылып чыга, әмма аның танылуга кадәр үткән юлы шактый озын була. Яңа гына ул Халыкара Букер премиясе исемлегенә керде, димәк ки, инглиз, рус телләрендә укучылар өчен дә тәкъдим ителде.

Аны нигездә роман-притча, ягъни «кыйсса» буларак билгелиләр, Герман Гессеның «Игра в бисер», Франц Кафканың «Процесс»ы белән янәшә куялар. Әлбәттә, бу исемлеккә Джордж Оруэлл, Рэй Брэдбери, Жозе Сарамаго, Кобо Абэ, Кадзуо Исигуро белән Харуки Мураками да өстәргә булыр иде.

Инглиз теленә тәрҗемәдә, әйтергә кирәк, роман шактый зур үзгәреш кичерә, исеме белән үк «ялганлый». Оригиналда ул «Заветный кристалл» дип аталса, инглиз һәм рус телендә укучыны бу исем белән җәлеп итеп булмас, дип карар кылалар. Шул рәвешле, әсәр фэнтези рухындагы китаплар белән бер киштәгә эләкмичә, детективлар тирәсенәрәк кереп оялый. Әмма эчтәлеге һәм өслүбе буенча ул бөтенләе белән аларга туры килми. Асылда, бу заманча проза үрнәгенең иң матур вәкилләре белән янәшә йөрергә хокуклы, искиткеч поэтик теле, зәвыгы белән аерылып тора торган китап.

> «ҮЗ ХӘТЕРЕБЕЗ ЭЧЕНДӘ БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА ТУЛАЕМ ИРЕКЛЕ».

Төп героиня – язучы, ул дөньядан аерып алынган бер утрауда яши. Бу гадәти генә утрау дип тәкъдим ителсә дә, андагы хәлләр киресен уйларга мәҗбүр итә. Биредә көн дә ни дә булса югала: кошлар, тасмалар, чәчәкләр, фотографияләр, ислемайлар... Беркем дә нәрсәнең югаласын алдан белми, әмма, югалгач, тоемлыйлар – башка бу нәрсә белән бернинди дә бәйләнеш калмаячак, исеме дә хәтердән сөртеләчәк.

Дөрес, бу югалулар тикторганнан гына килеп чыкмый. Киресенчә, кешеләр күпчелек предметлардан үзләре үк котыла. Кинәт кенә уяналар да нәрсәнең җуелачагын беләләр. Әйтик, бер иртәдә җыйнаулашып ислемайлардан котылырга кирәк икәнлеген тоялар – утрауда булган барлык ислемайларны да янәшәдә агып яткан елгага китереп түгәләр. Аннан – онытылалар. Әмма алар арасында хәтерен җуймаучылар да барлыгы ачыклана...

Хәтерен җуймаучылар предметларны яшереп саклый. Ирексездән, «Эквилибриум» фильмындагы «Джоконда» картинасын утка яккан мизгелләр искә килеп төшә... Әмма бу «хәтерләүче»ләрне Яшерен полиция эзәрлекли, төннәрен алып китә, һәм җәза алымнары коточкыч дип сөйлиләр. Тора-бара полиция инде, яшеренеп тормыйча, кешеләрне көпә-көндез үк кулга алырга керешә.

Героиня үзе «хәтерләүче»ләрдән түгел. Аның әнисе – шулардан. Көннәрдән бер көнне аларның өйләренә бәреп кереп, инде күптән кулга

алынган һәм вафат булган эти-әнисенең әйберләрен актарып чыгалар. Ә ул үзе алмашка калган бушлык белән ничек эш итәргә икәнлеге турында уйлана. Ул дүртенче китабын яза. Бу китап – тавышын югалткан машинистка турында. Кинәт героинябыз аңлап ала – бу китап ул уйлап чыгарган каһарман турында гына түгел, һәм андагы вакыйгалар белән тормыштагы хәлләр хәвефле булырга мөмкин.

Әсәр турыдан-туры антиутопия жанрына карамый, биредә Яшерен полициянең роле дә сер булып кала бирә. Бу – җансыз бюрократик машина, әмма без аның иттарткычы аша ничек узганнары белән турыдан-туры очрашмыйбыз. Ёко Огава игътибарны, киресенчә, башка детальләргә юнәлтә – минуты-секунды белән җуелырга мөмкин нәрсәләргә. Мин моны, чынлап та, күбрәк фәлсәфи-шигъри кыйсса дияр идем. Иҗтимагый-сәяси яссылык монда – икенче планда. Романнан экзистенциаль ялгызлык рухы бөркелеп тора.

2018 ЕЛДА «ЗАВЕТНЫЙ КРИСТАЛЛ» РОМАНЫ БУЕНЧА МЮЗИКЛ КУЕЛА. Ул Токионың иң яхшы театр сәхнәләрендә аншлаг белән уза. Әсәрләре экраннар өчен сайлап алына башлагач та, Ёко Огава бу популярлыкка әллә ни игътибар итми. Ул телетапшыруларга йөрүне дә, интервьюлар бирүне дә, блог алып баруны да кирәк тапмый. Киресенчә, йомык тормышны кулайрак күрә. Моннан тыш, Огава, рухани тәрбия алып үскән кеше буларак, гаиләсе гасырлар буе саклап килгән дини традицияләргә һәм гыйбадәтханәгә дә тугры кала.

Детальләргә карата булган сак һәм җентекле мөнәсәбәт – болар язучының визит карточкасы. Шулай ук психологизм да. Көнчыгыш стилендәге «тартмалы композиция» бик тә урынлы – машинистка турындагы тарих аша без героиня язмышын параллель яссылыкта чагыштырып кабул итә алабыз.

Менә язучы романындагы язучы тудырган машинистка кыз үзенең кешелек сыйфатларын һәм асылын җуя бара. Әйтерсең, күз алдыбызда кеше гомере, чәчәктәй, сула, үлемгә таба бара. Ә Огава героинясы үзе тудырган каһарманның халәтен теркәп, үз-үзен, әйтерсең, саклап кала. Әверелешләр – япон прозасы өчен чит нәрсә түгел, кирсенчә, Юкио Мисима, Харуки Мураками романнары аша без моның магиясен һәм көчен яхшы хәтерлибез. Битлекләр белән уен да – шушы традициянең бер өлеше.

90 нчы еллар уртасында язылган романның пандемия дәверендә яңа сулыш алуы һәм Япониядән читтә дә популярлык казануы – бу, әлбәттә, күпмедер дәрәҗәдә ирония дисәң дә була. Без бу героиняда үзебезне күрә, таный һәм шул танудан сискәнә дә алабыз. Сискәнмәскә дә мөмкин. Онытулар дөньясында – монысы, бәлки, кулайрак та булыр.

ЧЫН ИКӘНЕҢНЕ ОНЫТСАҢ...

Бенджамин Вуд, «Эклиптика»
«Фантом Пресс» нәшрияты, 2022
Тәрҗемәче: Светлана Арестова

42 яшьлек Бенджамин Вуд бүгенге яшь прозаиклар арасында уңышлары белән дә, темалары, тел-өслүбе белән дә аерылып тора. Аны тәнкыйтьчеләр дә ярата, укучылар да һәр яңа әсәрен көтеп ала. «Эклиптика» романы сәнгать дөньясына һәм бу дөньяда кайнаучы затларга багышланган. Бу, асылда, интеллектуаль роман, әмма язучы аны триллер һәм детектив кәгазенә төреп бирә.

«Эклиптика» – катлаулы, мавыктыргыч әсәр, ул буталчык сюжет линиясенә һәм мәдәни аллюзияләргә корылган. Биредә без үзебезне грек мифологиясенә килеп эләккәндәй дә хис итәбез, Томас Манн тудырган «Волшебная гора» коридорларын да урыйбыз, буйлыйбыз, Джон Фаулзның «Волхв» романына да ишарә тоеп алабыз. Әмма бу – контекст белән күләгәләр генә. Әдәби, мәдәни өрәкләр дияргә дә буладыр.

МИН РӘССАМ ТҮГЕЛ, ӘММА АВТОРНЫҢ ҮЗ-ҮЗЕ БЕЛӘН ГАРМОНИЯДӘМЕ, ТҮГЕЛМЕ ИКӘНЕН КҮРӘ БЕЛӘМ. КАЙЧАКТА ГАРМОНИЯ БАРЫ ТИК КҮРГӘЗМӘ ӨЧЕН ГЕНӘ УЙЛАП ЧЫГАРЫЛА. ЗАМАН СӘНГАТЕНДӘ КҮП НӘРСӘЛӘРНЕ ЯСАЛМА РӘВЕШТӘ КҮРСӘТЕРГӘ МӨМКИН, ӘММА ЭМОЦИЯГӘ ГЕНӘ ИМИТАЦИЯ ЯСАП БУЛМЫЙ.

Без Төркиягә, Истанбулдан ерак түгел генә урнашкан Принц утраулары чылбырындагы берсенә – Хейбелиадуга килеп эләгәбез. Биредә иҗат кешеләре өчен махсус резиденция урнашкан. Тәгаен генә аңлап булмый: бу кризис чорын кичерә торган сәнгатькәрләр өчен махсус санаториймы, психиатрия учреждениесеме, әллә лепрозориймы? Һәм менә көннәрдән бер көнне мондагы инде җайга салынган тормышның астын-өскә китереп, яшерен резиденциядә яңа бер зат – Фуллертон исемле яшь-яшь егет пәйда була. Безнең героинябыз аны нигәдер үткән тормыштан белгәндәй хис итә...

Шул рәвешле, без сәнгатьне тудыручы затларның, ягъни даһиларның эчке дөньяларына юл алабыз. Әйе, бу – «супергеройлар» мохите, аларның барысы да, кризисмы-түгелме, рухи көйләнешләре белән көндәлек мәшәкатьләр белән яшәүчеләрдән аерылып тора. Ә Вуд әйткәнчә, «супергеройлар мохитенә килеп эләксәң, чынбарлык һәрчак күңелсез һәм эчпошыргыч булып тоелачак».

Әсәрне без нигездә яшь шотланд рәссамы Элспет Конрой күзлегеннән кабул итәбез. Кайчандыр искиткеч шәп, сискәндергеч итеп карьерасын башлаган бу рәссам ханым сәнгать дөньясында «яңа исем» буларак кабул ителә, – аны күкләргә чөеп мактыйлар, үстерәләр, үсендерәләр... Ләкин ул, дан белән сынауны уза алмыйча, утрауга килеп эләгә. Әйтергә кирәк, бу урамнан гына кергән иҗатчылар түгел, аларның һәрберсенең үз бай серле меценаты, учреждение директоры белән махсус килешүе бар. Утраудан кире кешелек дөньясына, чын тормышка кайтып китүнең шарты бер генә – иҗатчының үзен дә, аның меценатларын да канәгатьләндерә алырдай әсәр тудыру, ягъни кризисны җиңү. Әмма бу мөмкин түгел диярлек. Биредә без иҗат дөньясының чире дә, фаҗигасе дә, югары үлчәме дә – перфекционизм белән күзгә-күз очрашабыз.

Әсәрнең тагын бер уникаль тикшеренү яссылыгы – рәссам тудырган дөнья, аның үз-үзен ваемлавы белән чынбарлык арасындагы тәңгәллек яки аерма. Тора-бара без «утрау тоткыннары»ның бөтенләй дә чынбарлыкта түгел, ә үз уйдырма галәмнәрендә яшәвен аңлап алабыз. Тормыш белән иҗат арасындагы гына түгел, ә кешенең иллюзияләре белән яшәү рәвеше арасындагы чикләр дә юыла, җуела.

Әсәрнең исеменә үк чыгарылган төшенчә – эклиптика. Героиня нәкъ менә шуның белән эш итә, баш вата, ниндидер бик гади хакыйкатькә ирешергә омтыла.

Ә үз күзлегебездән генә караганда, без ялгышмыйбызмы? Әнә шул сорау романның буеннан-буена бораулап тора. Геройларны да, безне, укучыларны да. Чынлап та, үз күзлегеннән объектив карый аламы иҗатчы үзенә? Ә кеше буларак? Буталып һәм адашып бетмиме ул үзе тудырган иҗади пространстволарда? Тормыштан бөтенләй аерылмыймы?

Хейбелиаду утравын үзенә күрә Переделкино дип тә атап булыр иде – көнгә өч мәртәбә ашап-эчеп, калган вакытларын бары тик иҗатка гына багышлаган рәссамнар, язучылар, архитекторлар чынбарлыктан шулкадәр ерак ки, кайсыдыр бер мизгелдә аларның язучы ирониясе генә түгелме икәнлегенә дә шикләнә башлыйсың. Бенджамин Вуд күтәргән бу проблема искиткеч актуаль һәм таныш: кайсыдыр бер мизгелдә, фәлсәфи категорияләргә бирелеп, без чынлап та тормыштан ваз кичәбез түгелме? Ә аннан тупикка барып төртеләбез. Үзебезне югалтабыз. Тапмыйча тилмерәбез...

Тик Вуд моның белән генә дә канәгатьләнми. Ул безгә вакыт буенча күчешләр тәкъдим итә, алар белән виртуозларча уйный. Һәм безне тагын бер темага – курку темасына алып чыга. Бу – талантыңны югалтудан курку да, башка кешеләр белән якынаюдан курку да, ялгызлыктан курку да... Ә иң аянычы – яшәүдән курку. Шул куркуны танымас өчен, уйдырма яссылыкларга китеп адашу...

ГАДИ ГЕНӘ ИТЕП ӘЙТКӘНДӘ, ЭКЛИПТИКА УЛ – ҖИР ОРБИТАСЫ ЯССЫЛЫГЫ. ӘММА БЕЗ ҖИРНЕҢ ҮЗЕНДӘ ЯШӘГӘНГӘ КҮРӘ, АНЫҢ БУЕНЧА КОЯШ ЙӨРИ ИТЕП ТОЯБЫЗ. НИ ӨЧЕН ШУЛАЙМЫ? Ә ҖАВАП БИК ГАДИ. ЧӨНКИ БЕЗ КОЯШ КҮЗЛЕГЕННӘН КАРЫЙ АЛМЫЙБЫЗ. АНЫҢ МӘГЪНӘСЕ ДӘ БУЛМАС ИДЕ.

Без омтылган һәм сусап эзләгән ирекнең чынбарлыкта оҗмах кына түгел, ә төрмә булып әверелү ихтималы да бар, ди автор.

Ахыр чиктә, эклиптика ул – астрономик һәм иҗади яссылык, төшенчә генә түгел икән, ә үз-үзеңә һәм чынбарлыкка кайту траекториясе дә.

2023 елда республикабызның иң өлкән басмаларыннан берсе – «Чаян» журналы оешуга 100 ел тула. Сокланырлык яшь! Бу санныбызда, каләмдәшләребезне юбилейлары белән котлап, журналның үткәненә, бүгенгесенә сәяхәт кылырга булдык.

«ЧАЯН»ГА – 100 ЕЛ!

Алмаз Хәмзин, «Чаян « журналының бүлек мөхәррире

1923 ел. Казанда шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнаш берничә иптәше белән журналның беренче санын чыгаралар – гарәп шрифтында, гади генә, аклы-каралы кәгазьдә, карикатуралар бөтенләй юк диярлек. Журналга исем сайлаганда, алар революциягә кадәр Төркестанда чыгарылган «Чаян» исемле татар газетасын искә төшергән.

30 нчы еллар. Илдә күрелмәгән үзгәрешләр: күмәкләштерү, индустрияләштерү, культура революциясе, халык дошманнарына каршы көрәш... Басмада Һади Такташ, Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир кебек исемнәре билгеле авторлар эшли. Алар кулакларны, нэпманнарны, җиңелеп бетмәгән буржуйларны һәм мил-

Иллюстрацияләр «Чаян» журналы редакциясеннән алынды

ләтчеләрне аяусыз рәвештә хурлык баганасына тери, совет иленең казанышларына дан җырлый.

40 нчы еллар. Авыр чор – шаян-көлкегә урын калмаган вакыт. Журнал хезмәткәрләре һәм авторлары ватанны сакларга фронтка китә. Алар татар телендә чыга торган фронт газеталарында эшли, каләм тотып та, кулларына мылтык алып та фашистларга каршы көрәшә. Журнал басылудан тукталып тора.

1951 елда «Чаян» яңадан укучыларына кайта. Дөньяда салкын сугыш чоры башлана. Журнал колонизаторлар, империалистлар, сионистлар һәм башка сугыш чукмарларын фаш итә. Илдәшләре – бюрократ, спекулянт, әчкече, ялкауларны һәм башка юньсезләрне дә онытмый, әлбәттә. Бу эштә аңа Гамил Афзал, Салих Баттал, Әмирхан Еники, Зыя Мансур, Габдрахман Минский, Газиз Мөхәммәтшин һәм башка чаянчылар ярдәм итә. 1956 елда журнал тарихында зур вакыйга була – ул рус телендә дә чыга башлый. Аның Советлар Союзында яңа дуслары барлыкка килә.

60 нчы еллар. Тарихка җепшеклек чоры дип кереп калган вакыт. Ил төрле өлкәләрдә гаять зур уңышларга ирешә – беренче мәртәбә галәмгә очу, чирәм җирләрне күтәрү, гөрләп торган төзелешләр. Максат зур – коммунизм төзү! Ә журналныкы – алтын каләм һәм пумалага ия иң шәп рәссамнарны үз канаты астына җыю. Һәм бу эшне Казан карикатура мәктәбенә нигез салучылар – Петр Новичков белән Борис Старчиков башкарып чыга.

70 нче еллар. Соңрак бу чорны торгынлык еллары дип атаячаклар. Их, хәзер шундый торгынлык булса иде! Икътисад үсә, чикнең буеннан-буена союздашлар, халык алдагы көнгә ышаныч белән карый, ә басманы олуг мөхәррир Альберт Яхин җитәкли. Язучы, журналист, шагыйрьләрне туплаган «йолдызлы команда» әрәмтамаклар, ришвәтчеләр һәм бюрократларга каршы аяусыз көрәш алып бара. Кыскасы, җәмгыятьнең әхлагын яхшырта.

80 нче, 90 нчы еллар, 2000 нче еллар башы. Җәмгыятьтә, икътисадта үзгәртеп корулар, уйланылып бетмәгән реформалар, илне таркату, күрелмәгән талау һәм халыкның хәерчеләнүе. «Кыргый базар» мөнәсәбәтләренә чыдый алмыйча, бер-бер артлы тугандашларыбыз – юмористик журналлар ябыла. Шушы шаулы диңгез дулкыннары аша редакция корабын баш мөхәррир Рәшит Зәкиев алып бара.

Бүгенге цифр заманында редакция шат күңелле һәм акыллы кешеләр өчен юмористик журнал чыгарып килә. Ул басманың юмор-сатира, халыкчанлык, тормыштагы ахмаклыклардан көлү кебек иң шәп традицияләрен сакларга тырыша.

Менә шулай, уйнап-көлеп, икенче гасырны башлап җибәрде журналыбыз! Тышлыгының кашында да: «Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!» дип юкка язылмаган бит!

Шул җәһәттән еллар дәвамында басылып килгән кайбер шаян шигырь-эпиграммаларны тәкъдим итәбез.









Гөлбикә

ГАМИР НАСРЫЙ.

Туган чакта матур, таза булып,
Кояшсыман балкып туды ул;
Әнисе: «Гөлкаем!» диде,
Әтисе күкләргә чөйде,
Әбисе: «Бәбкәем!» диде,
Бабасы кочаклап сөйде,
Менә шулай иркә булды ул.

Укыганда, күз-яшь белән генә,
Җиденчегә көчкә күчте ул;
Әнисе сөртте күз яшен,
Әтисе бакты дәресен,
Әбисе салдырды тунын,
Бабасы юдырды кулын,
Менә шулай иркә үсте ул.

Ә бер көнне, артык укымыйм, дип,
Елап кайтты өйгә Гөлбикә;
Әтисе дә, әнисе дә,
Бабай белән әбисе дә,
Чөеп кенә, сөеп кенә:
«Гөлем! Бәбкәм!» диеп кенә,
Боздылар шул аны бик иртә!

Куян, каушап, куркуыннан
Куйган Арысланга, ялгышып, мат.
Һәм иткән ант –
Шахмат уйнамаска икенче кат. («Куян белән Арыслан», Әхмәт Исхак)

«Аш тәмсез», дип гауга башлана да,
– Мөдир килсен, – диләр, әлбәттә.
– Мөдир юк шул, бүтән ашханәгә
Киткән иде мөдир әбәткә... («Чәнечкеле шигырь», Зәки Нури)

Ачыдан-ачы ни ачы?
Туры әйткән тел ачы.
Шундый туры әйтә торган
Телләр күбрәк булсачы. («Ачыдан-ачы», Нури Арсланов)

Басманың иң беренче җаваплы сәркатибе, бөек шагыйребез Такташның күпсанлы сатирик, юмористик шигырьләре, чәчмә фельетоннары тәүге мәртәбә «Чаян» битләрендә дөнья күрә. Ул наданлыкны, бюрократлыкны, җәнҗалчыны, прогулчыны сатира утына тота һәм тәнкыйтенең нәтиҗәсен дә белеп бара. Мәсәлән, Мөхәммәт Садриның бер истәлегендә мондый вакыйга телгә алына: Вахитов исемендәге сабын заводында цех җилләтелми, һавасы бик начар. Бу турыда заводта чыга торган күп тиражлы газетага да язып карыйлар. Ләкин чара күрелми: вентилятор-җилләткеч куелмый. Шуннан эшчеләр бу турыда Такташка барып сөйлиләр. Бераздан цехка Такташның «Сабын һәм головотяплар» исемле шигыре басылган «Чаян» килә. Бу хәл җыелышта тикшерелә һәм, күп тә үтми, җилләткечләр эшли дә башлый. «Менә – Такташ! Кечкенә шигыре белән калын таш стенаны тиштерде бит!» – ди эшчеләр. Менә ул «Сабын һәм головотяплар» шигыре:

Головотяплык үзе коньяк түгел,
Ә кешене шундый исертә;
Завкомчының җиңсез күлмәген дә
Чалбар итеп үзенә киертә.
Головотяплык тулган завком башын
Сабын белән юу файдасыз,
Бер җыелышта парлап чыгармыйча,
Вентилятор куйдыра алмассыз.

Шундыйрак тәнкыйди фикерләр дә «Чаян» битләрендә бик күп чыга:

– Хәзер, – ди ул, – шигъриятгә
Фикер дә юк, яңгырау да.
Чөнки үзе шигърияткә
Сукыр да ул, саңгырау да. (Гали Хуҗиев, 1960 ел, сентябрь)

Ришвәтне дә алды кул,
Ришвәтне дә бирде кул.

Кайчагында капчык тотты,
Кайчагында – ридикюль. («Кул», Галимҗан Насыйров, 1970 ел, июль)

Талантлыга рәхәт: утыра, яза,
Көч кирәкми аңа уйлар өчен.
Ә без күпме китап актарабыз,
Бер кечкенә фикер урлар өчен. («Плагиатор зары», Фәнис Яруллин, 1988 ел, апрель)

Киләчәк матур күренде,
Ал яңаклар янды.
Ялкынлы дәртләр сүрелде,
Коры исәп калды. (Гамил Афзал, 1988 ел, октябрь)

Үзебездә сулар юк мәллә?
Һаман Кара диңгезгә бара.
Кара диңгездән кимме Зәй, ә?
Үзе шыр тозлы, үзе кап-кара... («Ким түгел», Әзһәр Зәйни, 1988 ел, декабрь)

Бер түрә күләгәсенә
Ялгыш баскан, ди Фәхретдин.
– Ни булыр? – дип хәсрәтләнеп,
Вафат булган инфаркттан. («Чиновникның үлеме», Гарифҗан Мөхәммәтшин, 1989 ел, февраль)

Хәзерге көндә дә җәмгыятьтә кайбер «головотяплык» чагылышы күренгәләп ала. Дөресрәге – адым саен! Шаһиты – үзем. Күрә белгән түрәгә әйтәсе юк – үзе төзәтә. Аллага шөкер, җитәкчебездән уңдык. Ләкин шундый вакыт та бар иде: оешмабыз зур, вак-төяк түрәләр дә байтак. Һәрберсендә – машина. Рулендә – шофер. Бинабызга килеп керүгә – фойе. Кыш көннәрендә җылыныр, күп вакытта җитәкчене көтеп тору өчен шоферлар шунда бутала торган иде. Диваны да бар, гел машинада көне буе утырып, каядыр барып кайтуны көтеп, кәкрәеп бетәсең. Бүлмәләре юк шул аларның. Кызганыч. Моны күреп, Такташчарак әчтәлекле итеп, шоферларга теләктәшлек белдереп, мин дә шигырь яздым:

Шоферлардан күп кеше юк
Безнең оешмабызда.
Шау-гөр килеп кәрт сугалар,
Гел «мат» тавышларында.

«Чаян»да басылып күп тә үтмәде, махсус бүлмәле булды бит шоферлар. Шәп бит! Миңа да рәхәт, шоферларга да, җитәкчеләргә дә, дип беләм...

МӘКТӘПТӘН КАЙТКАЧ



— Нинди сорауга җавап бирә алмадың соң?
— «Әтиең ни эшли?» дигән сорауга...

ТАТАР ТАНАЕ: ЕЛ САЕН СУ БАСА...

ТАТАР ТАНАЕ

Фото: Александр Ефремов

Яшел Үзәннең Татар Танае авылының кайбер урамнарын ел саен су баса. Татар Танае Шналы (Шеланда) һәм Гөбенә елгалары арасында утыра. Гөбенә ярларыннан ташып чыгып, суы авылга кадәр керә икән. Март уртасында биредә булып, авыл халкының сөенүен күрдек: «Быел кар аз булды, йортларга су кермәс ахры», – диде алар. Ләкин ике көннән Рәшит абый Габдерәхимов видео җибәрде – бөтен ихаталары су эчендә калган. «Бүген төнлә авылга таба су килә башлады. Иртәнге сәгать дүрттә күршеләр белән умарталарны күчердек. Аллага тапшырган инде...», – дип язды.

Руфия Фазылова

«ТӨН ЙОКЫЛАРЫ КАЧТЫ!»

Рәшит абый җәмәгате Асия апа белән гомер итә. Йортлары авыл башында – Гөбенә елгасыннан ерак түгел. Ир белән хатын язгы ташу чорына март башыннан ук әзерләнә башлый – беренче эш итеп баздагы бәрәңгене сарайга чыгаралар, идән астындагы банкалар да түргә «менеп утыра». Аннан исә каралтыдагы бозауларны каршыдагы сарайга куып кертәләр. Шуннан Габдерәхимовлар могҗиза көтә башлый: су басмаса гына ярар иде...

Без килгәндә хуҗаларның идән асты коры иде. Арт яктагы бакчада умарта оялары да елдагыча суда түгел, җирдә утыра.

Һәм менә ике көннән алар барысы да су астында калган. Дөрес, узган ел белән чагыштырганда, быел су азрак булган. (Идән өстенә чыгарга егерме сантиметрлап ара калган). Ә менә 2018 елда су идән өстенә кадәр менгән. Хуҗалар өйдә резина итек киеп

1

– Иң беренче су басу 1969 елда булды. Без шул елны өйләнештек, шуның өчен дә яхшы истә калган, – ди Рәшит абый Габдерәхимов.

2

Арт яктагы бакчада умарта оялары да елдагыча суда түгел, җирдә утыра иде.

йөргән. Быел да капка төбе, ишек алды, бакчалар су эчендә утыра.

– Рәшит абый, ни өчен су баса торган җирдә йорт салдыгыз? – дим.

– Шушы нигездә әтием гомере буе яшәде. Ул 1904 елгы иде. Элек су басу дигән әйбер бөтенләй булмаган. Бәрәңге утырта торган бакчада эллә ничә төп алмагач үскән. Иң беренче су басу 1969 елда булды. Без шул елны өйләнештек, шуның өчен дә яхшы истә калган. Ул елны сарыклар су эчендә калды. Ишек алдына көймә белән кереп, сарыкларны төяп чыктылар. Ә йортны без 1968 елда салдык.

Авыл башына 1968 елда дамба салганнар. Күрәсең, дамба, су юлын томалап, язгыташуны авылга керә торган иткән. Әнә шуннан соң Гөбенә елгасының агышы да үзгәргән.

– Ул чагындагы колхоз рәисе Рус Танае белән Татар Танае арасын якынайтырга теләп шулай дамба өйдерде, – диде Рәшит абый. – Авылны болай су басар дип берәү дә уйламады. Менә шуннан бирле өч-биш елга бер су басып торды. Соңгы елларда бигрәк тә ешайды.

Габдерәхимовлар җәй буе идән астын ачык тота, тәрәзә, ишекләр дә ачык – дымлылык югары, ис тә була. Идән асты күзгә генә кипшенеп бетә икән. Өйне генә түгел, мунчаны да су баса. Кайбер елларны ләүкә биеклеге су була.

– Су басу проблемасына игътибар итүче беренче җитәкче – Яшел Үзән районының элеккеге район башлыгы Василий Тыгин булды, – дип дәвам итте Рәшит абый. – Ул, авылга килеп, проблеманы үз күзләре белән күрде. Шул вакытта яңа дамба ясарга дигән карарга килделәр. Проектны ул эшләтте. Ләкин Тыгин китеп барды, эш туктап калды. Аннары республика җитәкчесе Рөстәм Миңнехановка хат яздым. Күрәсең, хатны районга җибәргәннәр. Шулай итеп боз кузгалды, дамба ясаганнарын көтәбез.

Чынлап та, авылны су басу быел соңгысы булыр дип ышана җирле халык. Хәзерге район башлыгы Михаил Афанасьев бу проблеманы үз контроленә алган:

– Кулда килешү бар, төзелеш оешмасы белән контракт төзелгән, – диде Татар Танае авыл җирлеге башлыгы Фәнис Мирхатуллин. – Дамба ясау 90 миллионга төшә. Техникалары белән эшчеләр килеп урнашты инде. Азрак җир кипкәннe һәм карьер ачылганны көтәбез. Дамба булгач, су икенче юлдан китәргә тиеш. Авылларны бөтен яклап таулар чолгап алган. Тау битләрендә су эри дә авылга таба агып килә. Шуның өчен дә безне ел саен диярлек су баса.

...Рәшит Габдерәхимовка 75 яшь тулган. Берәү булса, шулай су эчендә яшәүләренә зар елап, кемнедер сүгеп утырыр иде. Ә ул, оптимистларча карап, проблемадан чыгу юлын эзләгән. Башта егерме ел механизатор,

аннан соң лаеклы ялга чыкканчы газ хезмәтендә эшләгән киң күңелле Рәшит абыйга сокланып кайттык.

ТЕХНИКА ҖЕНЕ КАГЫЛГАН...

Габдерәхимовларга барганда, урамда торган бик үзенчәлекле ике техникага игътибар иттек. Берсе – трактор башмакларына утыртылган «Ока», икенчесе – зур трактор көпчәкләренә беркетелгән «Жигули» машинасы. Читтән карап торганда кызык та, сәер дә. Бу техникаларның барысын да Татар Танаенда яшәүче Илдар Уразов ясаган. Шундый үзенчәлекле машиналар бишәү аңарда!

– Болар белән трассага чыкмыйсыздыр инде? – дидем Илдар абыйга.

– Юк, техосмотр-фәлән узмаган алар. Җәмәгатем күрше Кайбыч районы Багай авылына йөреп эшли, фельдшер. Ике район арасында юл юк. Язын, көзен – «Жигули» машинасы, кышын исә «Ока» белән алып барам. Хатынны җәяү йөртеп булмый бит, ә мин ясаган машиналар карда да, пычракта да йөри.

– Шундый биш техника нәрсәгә сезгә? Аның барысы белән дә йөрисезме? – дим.

– Алар барысы да йөри. Нәрсәгә дип... Кыш көне эш юк бит, буш торганчы дип ясыйм. Ике ай эчендә бер техниканы җыеп куям. Бер машинаны сатып та җибәрдем. Әле менә тагын сораучы бар. Бу башмаклы «Ока» машинасы 200 мең сум тора. Техника җыю бик ошый миңа. Беренче машинамны 2002 елда ясадым.

– Иске машиналарны сатып аласызмы?

– Әйе, сатып алам. Кузовын, аерым детальләрне берәм-берәм җыям.

Илдар абый Танайда туып үскән ир-ат. Әтисе күп еллар колхоз гаражы җитәкчесе булган. Малай еш кына әтисенә ияреп гаражга йөргән, техникага мәхәббәт шул чагында уянган. Аннан үзе колхоз техникасында эшләп алган. Газ эшендә дә хезмәт куйган.

– Бүгенге көндә өйдә генә эшлим, күп итеп мал-туар тотабыз, – диде Илдар абый. – Сыерлар, сарыклар асрыйбыз. Икенче улыбызның сәламәтлеге белән проблемалары бар. Шуның өчен дә өйдә торырга туры килә.

Илдар абый үзе ясаган «Ока»га утыртып урам да әйләндереп килде. Бик кызык тәэсирләр калды: үзе «Ока», үзе биек. Башмакларда йөргәнгә күрә, йомшак кына, җай белән генә бара. Сәгатенә илле-алтмыш километр тизлек белән йөри икән.

Бу кешенең уйлап табучанлыгына бер шаккатсам, хәләл җефетенә булган мөнәсәбәтенә тагын да сөендем. Ике улының әнисен, яраткан кешесен җил-яңгырда, буранда йөртмәс өчен, әнә нәрсәләр уйлап тапкан бит. Ярату-хөрмәт менә шушыдыр инде...

3
Техникаларның барысын да Илдар Уразов үзе ясаган. Шундый үзенчәлекле машиналар бишәү аңарда!

ЯҢГЫННАН СОҢ ТОРГЫЗЫЛГАН АВЫЛ

Татар Танаенда бүген 201 хуҗалык бар, 430 кеше яши. Авылда урта мәктәп, балалар бакчасы эшли. Китапханә, мәдәният йорты, ФАП – барысы да халыкка хезмәт күрсәтә. Кызганыч ки, авылда балалар саны елдан-ел кими икән. Дөрес, Татар Танае урта мәктәбен быелгы уку елында 78 укучы тәмамлый. Ләкин әле дистә ел элек кенә дә балалар саны бермә-бер артык булган.

Бик үзенчәлекле тарихлы авыллар бар, Татар Танаен шундыйлар рәтенә кертергә мөмкиндер. 1843 елда бирдә көчле янгын чыга, авыл тулысынча янып бетә. Җирле халык сүзенә караганда, бары тик каравылчы йорты гына исән кала. Һәм шундый зур фаҗигадән соң да авыл яңадан торгызыла! Алай гына түгел, ул үсә. Нәтиҗәдә XX йөз башына авылда ике мәчет ачыла. Дүрт йөзгә якын йорты, меңнән артык кешесе була. Мәчет каршысында мәдрәсә эшли, һәм аны тәмамлаган кайбер шәкертләр Казан, Бохара мәдрәсәләренә барып белем ала.

Авылда барлыгы дүрт урам бар, һәм аның һәркайсына халык аерым исем кушкан. Беренче урам, элек руслар яшәгәнгә, – Рус урамы, икенчесе – Үзәк урам, өченчесе – Ындырчы урамы, дүртенчесе Тегәрҗеп урамы дип аталган. Иң кызыгы, заманнар үзгәрү сәбәпле, ул урамнарның рәсми атамалары барлыкка килгән. Ә менә Рус урамы элеккеге исемен югалтмаган. Рәсми исеме бүген бүтән булса да, халык аны элеккечә атый.

Татар Танае урта мәктәбенең элеккеге тарих укытучысы Фәрит абый Мирхатуллин җыйган мәгълүматлар белән танышып чыктым. Барысын да бәйнә-бәйнә язган ул. Аксакал туган авылында кеше саны кимүне менә ничек аңлаткан:

«Беренче. 1921 елгы ачлык.

Икенче. Колхозга керергә теләмичә, авылдан китәргә мәҗбүр булучылар.

Өченче. Бөек Ватан сугышы.

Дүртенче. Кызлар күп туу.

Бишенче. Егетләрнең аракы белән дуслашуы.

Алтынчы. Колхозлар таркалып, авылга инвестор килү».

Чынлап та, уйлап карасың, бу фикердә дөреслек бар. Иң аянычы – Татар Танаена гына түгел, бик күп башка авылларга да туры килә торган сәбәпләр бу.

«САГЫНАМ...»

Яшел Үзән халкы җыр-биюгә хирыслыгы белән аерылып тора. Бу якларны якыннан белгәнгә, моңа инанып әйтәм. Татар Танаенда да шулай – концерт, спектакльләр куярга дигәндә, ялындырып тормыйлар икән. Халык кына азая, бердәнбер проблема шул.

– Мәдәният йортында эшләгәндә өйгә йокларга гына кайта идек, – ди Фәния апа Хуҗина. – Егерме тугыз ел мәдәният йортында директор вазыйфасын башкардым. Лаеклы ялга чыккач, эштән киттем инде. Дин юлына бастык, Аллага шөкер.

Фәния апаның «ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исеме бар. Җәмәгате Наил абый белән ике ул, бер кыз үстергәннәр. Балалар үз гаиләләре белән яши, өлкәннәр исә яшьлектә салган йортларында гомер итә.

– 1969 елда өйләнештек, шуннан бирле тату гына гомер итәбез, – дип дәвам итте Фәния апа. – Башта Кемерово өлкәсендә яшәдек. Тугыз ел гомер иткәч, кире туган якка кайттык. Наилнең әтисе вафат булгач, нигез ят кешеләргә калмасын, диде ирем. Авылга кайткач, колхоз ашханәсенә пешекче итеп куйдылар. Ләкин минем мәдәният өлкәсендә эшлисем килде. Кечкенәдән җырладым, сәхнәдә буласым килде. Мин бик бәхетле – хыялым тормышка ашты. Өч дистә ел мәдәният йортында эшләдем. Шул чаклар хәзер дә бик сагындыра. Яратып кына түгел, бөтен барлыгымны биреп хезмәт куйдым.

Фәния апа көр күңелле кеше. Аяклары авыртуга карамастан, ник бер зарланып карасын. Өендәге һәр почмагын күрсәтеп, атлап түгел, очып кына йөрде. Хәләл җефетеннән аермалы буларак, Наил абый тыйнак кеше. Хатыны сөйләгәннәрен тыйнак гына елмаеп тыңлап утырды. «Ярар инде, анысы кирәк түгел», – дип тә куйгалады. Ә Фәния апа хәләл җефете турында да сөйләде:

– Наил үзе сөйли белмәс, әйтим әле – кулы алтын аның. Өйдәге ике шкаф, кием элгечләре – барысын да үзе ясады. Әле хәзер дә тик тормый, үзенә кул эше табып кына тора.

4

– Шырпы өйләрне ясарга интернеттан карап өйрәндем, – диде Наил абый. – Кыш көне эш юк бит, ә тик утырасы килми.

5

– 1969 елда өйләнештек, шуннан бирле тату гына гомер итәбез, – диде Фәния апа Хуҗина.

4

Чынлап та, Наил абыйның куллары алтын икән, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра. Быел кыш шырпыдан йорт, башка предметлар ясарга өйрәнгән. Алар тулы бер композиция: йортның баскычлары, рәшәткә-коймалары, барысы да чынбарлыктагы кебек.

– Интернеттан карап өйрәндем, – диде Наил абый. – Кыш көне эш юк бит, ә тик утырасы килми. Язга чыккач андый эшләргә вакыт калмый, кара көзгә кадәр бакчада мин. Әле менә йөз төп помидор утырттым. Фәниянең аяклары авырткач, бакча эшләренә бик катнашмый, ә мин яратам. Балаларга күп итеп төяп җибәрәм. Рәхмәт әйтеп алалар, шуңа күңел була.

Шырпы өйләрне Наил абый берничәне ясаган. Аларны ул балаларына, күршеләренә биргән. Әле менә авылдагы балалар бакчасы җитәкчесе килгән. Аңа да бүләк итеп җибәргән.

– Исән булсам, киләсе кышка үземә яңа бер шөгыль табып куйдым инде, – диде Наил абый. – Ни икәнен әлегә берәүгә дә әйтмим, башта өйрәнергә кирәк. Гел бер төрле эш кенә туйдыра, төрле юнәлешне үзләштерәсем килә. Кызык бит.

...Татар Танаеның төп байлыгы - киң күңелле, ачык йөзле, тырыш халкы. Алар уздырыштан мал җыймый, булганына канәгать итеп, күңелле яши белә. Шуның өчен дә биредә халык бәхетле гомер итә кебек тоелды безгә.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Авылыбызның беренче исеме – Мамадыш-Тәүгилде. 1843 елгы көчле янгыннан соң авыл Танай дип атала башлый.
Танай атамасы хакында төрле фикерләр йөри. Кайберәүләр аны кеше исеме, ә икенчеләр «яңа ай» дигән мәгънәне белдерә диләр. Минемчә, соңгысы дөреслеккә якынрак. 1873 елда безнең якларга энесе Габделкави белән Каюм Насыйри килә. Алар авылыбызның этник шәҗәрәсе белән таныша. Бу шәҗәрәне XV йөздән башлап авыл имамнары алып барган. Шулай булгач, авылыбыз бик борынгы.

Фәрит Мирхатуллин, Татар Танае урта мәктәбенең элеккеге тарих укытучысы

Ай кәефе: берләшү

БЕРЕНЧЕ ИФТАР

Рамазан аенда беренче күмәк авыз ачу – ифтар мәҗлесе кичке намаздан соң «Туган авылым» ресторан комплексында узды. Ифтарга Төркия, Франция, Казахстан, Иран консуллары килгән иде. Ифтар Төркиядәге коточкыч фаҗига – җир тетрәүләрдә һәлак булган кешеләрне искә алуга багышланды.

– 50 меңгә якын ватандашыбыз һәлак булды, – дип мөрәҗәгать итте Төркия Республикасының Казандагы Генераль консулы Исмәт Эрикан. – Күп кенә илләр һәм төбәкләр, шул исәптән Татарстан да зур ярдәм күрсәтте. Россия халкы тарафыннан җыелган 400 тоннага якын гуманитар ярдәмнең 100 тоннасы Татарстанга туры килә.

Төркия дөньядагы иң зур фаҗигаләрнең берсенә дучар булды. Рамазан аенда догаларыгызда һәлак булган ватандашларымны искә алуыгызны сорыйм, алар безнең догага мохтаҗ – диде консул.

– Рамазан аенда оҗмах капкалары ачыла, тәмуг капкалары ябыла. Барыбызга да Рамазан аен лаеклы уздыруыбызны телим, Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны кабуллардан кылсын, – диде Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ифтарга килгәннәргә мөрәҗәгать итеп.

Ә «Туган авылым» милли комплексын гамәлгә куючыларның берсе Радик Абдрахманов, «Туган авылым»да ифтарлар үткәрү яхшы традициягә әйләнеп бара, дип өстәде. «Эшчәнлегебезнең төп фәлсәфәсе – берләштерү: бизнес белән хакимиятне, төрле конфессияләрне, фикер лидерларын, бизнес-берләшмәләрне, безне чолгап алган бөтен нәрсәне».

Фото: Салават Камалетдинов / «Татар-информ», dumrt.ru, «Туган авылым» милли комплексы

«ТАТМЕДИА» БАСМАЛАРЫ МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

ТАТ МЕДИА

БЕЗНЕ НИЧЕК ТАБАРГА?

ТАТМЕДИА →

КИТАПЛАР

ЖУРНАЛЛАР

ТӘБРИКЛӘМӘЛӘР

OZON

Я Маркет

WILDBERRIES

KazanExpress

БЕЗНЕҢ ИНТЕРНЕТ-КИБЕТ

SHOP.TATMEDIA.RU

Реклама. 16+. АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 Г.Казань, ул.Декабристов, 2 ГРН 1071690057834